Яр Чаллы шәһәре үзәкләштерелгән китапханәләр челтәренең
Муса Җәлил исемендәге шәһәр Үзәк китапханәсе
Әдәбият тарихы музее

*Чаллы язучылары иҗаты*

# РӘКИТ АЛЛАБИРДЕ

Рәкит Яүдәт улы Әбделманов

*(Биобиблиографик күрсәткеч)*

Яр Чаллы
2019

**ББК 91.9: 83 + 83.3 Тат 6**
**А 52**

**Төзүче**: Роза ХӘМИДУЛЛИНА,
Муса Җәлил исемендәге шәһәр үзәк китапханәсенең бүлек мөдире.

**Оригинал-макетны эшләүче**: Амур ФӘЛӘХОВ.

**Составитель**: Роза ХАМИДУЛЛИНА,
Заведующая отделом центральной городской библиотеки имени Мусы Джалиля.

**Составитель оригинал-макета**: Амур ФАЛЯХОВ.

Р 52 Ракит Аллабирде: Биобиблиографик күрсәткеч / Яр Чаллы шәһәре М. Җәлил исемендәге шәһәр үзәк китапханәсе. Әдәбият тарихы музее; Төзүче Р.Г. Хәмидуллина. – “Взаимная помощь” ҖЧҖ социаль типографиясе, 2019. – 150 бит.

Р 52 Ракит Аллабирде: Биобиблиографический указатель / Центральная городская библиотека имени М. Джалиля г. Набережные Челны; Литературно-краеведческий музей; Составитель Р.Г. Хамидуллина. – Социальная типография ООО «Взаимная помощь» 2019. – 150 стр.

МБУ «Централизованная библиотечная система»
г. Набережные Челны
Центральная городская библиотека имени Мусы Джалиля
Литературно-краеведческий музей

*Творчество*
*Набережночелнинских писателей*

# РАКИТ АЛЛАБИРДЕ

Ракит Явдатович Абдульманов

*(Биобиблиографический указатель)*

Набережные Челны
2019



***Рәкит Аллабирде (Әбделманов)***



## УКУЧЫГА:

Кулыгыздагы «РӘКИТ АЛЛАБИРДЕ» – биобиблиографик күрсәткече Муса Җәлил исемендәге шәһәр үзәк китапханәсенең «ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАРЫ» дип аталган биобиблиографик басмалары сериясен дәвам итә. Сериянең төп максаты – Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат иткән язучыларның тормышы һәм иҗаты турында тулы библиографик мәгълүматлар туплау.

Әлеге күрсәткечкә материаллар басылып чыгу хронологиясе тәртибендә урнаштырылды. Күрсәткеч Рәкит Аллабирденең 2019 нче елның 1 маена кадәр дөнья күргән басмаларын һәм аның хакындагы әдәбиятны үз эченә ала. Биобиблиографик күрсәткеч Яр Чаллы шәһәре үзәкләштерелгән китапханәләр системасы мәгълүмат базалары һәм Рәкит Аллабирденең шәхси архивы нигезендә эшләнде.

Биобиблиографик күрсәткечнең «Кушымта» өлешендә Рәкит Аллабирденең матбугатта күренгән кайбер фотосурәтләре турында мәгълүмат бирелә һәм шәхси архивында сакланган кайбер фотосурәтләре урнаштырылды.

## К ЧИТАТЕЛЮ:

Биобиблиографический указатель «РАКИТ АЛЛАБИРДЕ» является очередным изданием серии биобиблиографических указателей «ЧЕЛНИНСКИЕ ПИСАТЕЛИ», подготовленной сотрудниками Центральной городской библиотеки имени Мусы Джалиля. Основная цель этой серии дать наиболее полные сведения о творчестве и библиографии известных писателей г. Набережные Челны.

В данном указателе материалы расположены по разделам в хронологическом порядке. Произведения Ракита Аллабирде охватывают период до 1 мая 2019 года. Биобиблиографический указатель составлен на основе информационных материалов МБУ «Централизованная библиотечная система» города Набережные Челны и личного архива Ракита Аллабирде.

В приложении указателя помещены фотографии из личного архива.

## УҢЫШЛАР ЮЛДАШ БУЛСЫН!

Бар әле бар, күңелләрдә безнең җегәр,
Бу җегәрлек әле безгә күпкә җитәр,
Җырлы-моңлы юлга сезне ияртәбез,
Кемнәр хисле, әйдә атлар иярләгез!

*Р. Әбделманов*

Бу биобиблиографик күрсәткеч шигырьләрен вакытлы матбугат битләрендә Рәкит Аллабирде тәхәллүсе белән бастырып килгән иҗади дустыбыз Рәкит Әбделмановның иҗатын үз эченә ала. Тәхәллүсе әдипнең туган авылы исеменнән алынган. Чөнки бу шәхесне безгә Башкортстан республикасының Күмертау районы Яңа Аллабирде авылы биргән. Әлеге исем белән татар җәмәгатьчелеге 1980 елларның икенче яртысыннан ук таныш.

Рәкит Җәүдәт улы Әбделманов 1960 елның 22 мартында дөньяга килә. Башлангыч белемне туган авылында ала, аннан Яңа Мораптал урта мәктәбен тәмамлый. 1978 - 1981 елларда Балтыйк буе хәрби диңгез флотында хезмәт итә, 1986 елда Кама Автомеханика техникумының кичке бүлегендә укып, технолог һөнәре ала. 1983 елдан бирле Чаллы шәһәрендә яши.

1988 елларда шәһәребездә язучылар оешмасы каршында эшләп килгән «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөргән Рәкитнең шигырь, хикәяләре шәһәребездә, республикада чыгып килүче вакытлы матбугат битләрендә күренә башлый.

Яшьли иҗади калага килгән Рәкитне язмыш, талантлы яшь каләм тибрәтүче иҗат кешеләрен вакытында күреп алып, үз фатихаларын биргән, аларга туры юл күрсәткән Фаяз Дунай, Кадыйр Сибгатуллин, Хәниф Хөснуллин кебек күренекле әдипләр белән очраштыра.

Язучы, талантлы публицист, тәнкыйтьче Фаяз Дунай, – яшь, талантлы егетнең уңышларына сөенеп аның турында болай дип яза: «...чын-чыннан сәнгать әсәрләре булган язмалар укыйм. Чаллы язучыларына күптән таныш булган, һәрдаим

аларга булышып торучы миһербанлы ир-егет Рәкитнең әсәрләре алар. Язмаларда реаль тормышчан-табигый персонажлар – кешелекле, тере, үзенчәлекле, уйчан, хисле, кайгылы-хәсрәтле һәм шатлыклы...» Соңрак, (1996) елда, язучы Ф. Дунай Рәкитнең хикәяләр һәм тарихи эссе тупланган беренче «Аллабирде» җыентыгының кереш сүз авторы да була.

Шулай ук Татарстанның халык язучысы, күренекле драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллин да каләм чарлаган егеткә 2001 елда үз бәһасен биреп: «Син, энекәш, шәп язасың! Язуыңны берүк ташлама...», – ди.

Әллә остаз каләмдәшләренең сүзен тоткан, әллә инде язмыйча булдыра алмаган, Рәкит Аллабирде бүгенге көндә повесть, хикәяләр, шигырьләр тупланган тугыз җыентык авторы: «Аллабирде» (1996), «Хыял атым» (2011), «Влюбленные души» (2012), «Сулыш» (2016), «Җаным тама» (2016), «Әтәч елы» (2017), «Яшьлегем тугае» (2018), «Алиһә» (2018), «Гашыйклар халәте» (2019). Иҗат дөньясында ул бигрәк тә шигырьләре белән танылa. Авторның «Фанида» дип исемләнгән шигырендә мондый юллар бар:

*Туктагач йөрәгем, һаман да,*
*Җаннарның гозерен үтәрлек*
*Вакыт бир калырга заманда,*
*Аһ-зарлар йомгагын сүтәрлек.*

Нәкъ менә шигырендәге кебек, заман балаларының аһ-зарларын ишетеп, аларны күңеле аша үткәреп, бик күпләргә ярдәм итеп, һәрберсенең дөньяларын төрледән-төрле кызыклы гамәлләр белән тутырырга теләп яши, эшли ул.

Рәкит Әбделманов 1996 елдан шәһәребездә «Идел-Урал» хәйрия фондын оештыручы һәм җитәкчесе булып хезмәт куя. Менә инде егерме елдан артык, физик мөмкинлекләре чикләнгән актив кешеләрне туплаган фонд Рәсәй төбәкләренә һәм БДБ илләренә сәяхәтләр оештыра, спорт, мәдәни, хәйрия чаралары үткәрә. Рәкит Җәүдәт улы кешелекле, мәрхәмәтле

шәхес. Һәр фонд әгъзасы аның игътибар үзәгендә. Кешеләрне аңламасаң, кайгыларын уртаклашып булмыйдыр ул. Кешеләргә авыр чакларда ярдәмгә килү − һәркемгә дә кирәк сыйфаттыр. Ә Рәкит Әбделманов шундыйлардан.

Үз эшенең остасы, ул күңеле кушканча, яраткан эше белән шөгыльләнә. «Гаярьләр» шигырендә үзенең күңел халәтен болайрак итеп тасвирлый:

*Ишетәм мин аваз: «Кавемем*
*Үз эзен сакласа һавада,*
*Җанымны һәркемгә бүлгәләп,*
*Яшәрмен гел сезнең арада».*

Рәкит Аллабирденең 2017 елны Татарстан китап нәшриятында «Сулыш» китабы дөнья күрде. Җиде бүлектән торган бу әсәре белән Рәкит авыл халкына һәйкәл куя, аңлавымча бу бәяндә исемнәре искә алынган авыл кешеләренең инде күбесе исән дә түгел. Авыл халкы бу китапны күз яшьләреннән башка укый да алмыйдыр. Рәкит бәянында авыл хезмәтендә төрле өлкәләрдә хезмәт куйган кешеләрне искә ала: тракторчылар, тимерче, печәнче, укытучы, тәрбияче, мәктәп директоры, җиңги-җиңгәчәләр, туган тумача – барысы да, биш тиен торган кино да, киномеханик, билет сатучылар да аның каләменнән читтә калмый. Автор мәктәп елларын, армияга алынган егетләр язмышын тасвирлый. Аны бәян герое Рәкыйп язмышы итеп кенә карарга ярамый, монда – ил язмышы, татар егетләре язмышы. Әлеге әсәр турында язучы Рафаил Газизов: «Әсәрнең «Сулыш» дип исемләнүе дә уңышлы. Җандагы, тәндәге һәр күзәнәкне туендыручы туган җир һавасы җитми авылыннан киткәннәргә. Чөнки туган җирнең бар байлыгы, хозурлыгы белән тудырылган иҗат җимеше шул – адәм баласы. Туган җир сулышыннан киселдеңме, дөньяда торуың – инде тоташ йокы исереклеге, сырхаулык», – дип, үз бәясен бирә.

Рәкит Аллабирде 2019 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Авторның күп кенә шигырьләре композиторларыбыз:

Ринат Гобәйдуллин, Зөлфия Җиһан, Рубис Зарипов, Нәгыйм Шәйхиләр тарафыннан көйгә салынган. Бүгенге көндә популяр җырларга («Эх, Мораптал», «Яшьлек моңы», «Җыр-Аргамак») әйләнеп баралар.

Ике бүлектән торган бу биобиблиографик күрсәткеч язучы Рәкит Аллабирденең иҗади эшчәнлеген тулысы белән үз эченә ала. Биредә язучының кыскача биографиясе, басылып чыккан китаплары һәм вакытлы матбугат битләрендә урын алган әсәрләре, мәкаләләренең исемлеге тупланып бирелгән. Монда шулай ук аның турындагы кичә-сценарий күчермәсе белән дә танышырга мөмкин. Күрсәткеч гаилә архивында сакланган төрле еллардагы фотосурәтләр белән дә баетылган.

Әлеге китап язучының тормышы, иҗаты белән кызыксынган укучылар өчен билгеләп бетергесез байлык булыр дип ышанам.

Рәкит Әбделманов: «...Кулыма каләмне сирәк алам. Шигырьләремне яттан сөйләргә яратам. Шулай миңа күңеллерәк, җайлырак», – ди һәм, кулына гармун алып, күңелендә туган хисләре белән дусларын алга әйди:

*Көтеп алган язлар тагын килеп җиткән,*
*Күңел җырлар аргамагын юлга җиккән.*
*Әйдә, дустым, гармуныңны тартып җибәр –*
*Бар әле бар, күңелләрдә безнең җегәр!*

«Җыр - Аргамак»

Шулай булсын, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Рәкит Аллабирденең күңел җегәре һәрдаим иҗатка өндәп торсын, сүнмәсен, бары тик уңышлар гына юлдаш булсын!

**Роза ХӘМИДУЛЛИНА,**
*Муса Җәлил исемендәге шәһәр үзәк китапханәсенең*
*әдәбият тарихы музее җитәкчесе,*
*Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре*.

## РӘКИТ АЛЛАБИРДЕНЕҢ КЫСКАЧА БИОГРАФИЯСЕ

Рәкит Яүдәт улы Әбделманов (Рәкит АЛЛАБИРДЕ) 1960 елның 22 мартында Башкортстанның Күмертау районы Яңа Аллабирде авылында дөньяга килә. Башлангыч белемне туган авылында ала аннан Яңа Мораптал урта мәктәбен тәмамлый.

1978-1981 елларда Балтыйк диңгезендә хәрби диңгез флотында хезмәт итә. 1982 елда Татарстанның Зәй шәһәренә, “КАМАЗ” оешмасына эшкә килә. 1983 елда Тәгәрмәчләр заводының оештыру бүлегендә эшли. Кичке сменада эшләгәндә фаҗигагә эләгеп, аягын югалта... 1984 елдан “Камгэсэнергострой” төзелеш берләшмәсендә өлкән мастер һәм 1985 елдан спорт биналары һәм корылмаларның баш инженеры вазифаларын башкара. 1986 елда Кама Автомеханика техникумының кичке бүлеген тәмамлый.

1996 елдан “Идел-Урал” хәйрия фондын оештыручы һәм җитәкчесе. Физик мөмкинлекләре чикләнгән актив кешеләрне туплаган фонд Рәсәй төбәкләренә һәм БДБ илләренә сәяхәтләр оештыра, спорт, мәдәни, хәйрия чаралары үткәрә. Рәкит Әбделманов – 2009 елда “Алтын йөрәкле кеше” һәм “Татарстан Республикасының ел хәйриячесе”, 2010 елда Россия федерациясе “Благотворительность” сертификаты иясе, 2013 елда “Зур йөрәкле кеше” исемнәренә лаек була. Фонд, Россия федерациясе президенты указы нигезендә Хәйрия эшчәнлеге буенча ачык конкурста җиңүче дип бәяләнә. Хәйрия һәм халыклар дуслыгы эшчәнлеге өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан хөкүмәте тарафыннан рәхмәт хатлары, “Яр Чаллы шәһәре каршында казанышлары өчен” билгесенә лаек була, җиде ел рәттән фонд җитәкчесе Татарстан президенты киңәшчесе М.Ш.Шәймиев тарафыннан, Татарстанның “Яңарыш” фонды исеменнән рәхмәт хатлары һәм хәйрия китабы белән бүләкләнә.

Рәкит Яүдәт улының эшчәнлеге Яр Чаллы шәһәре хакименнән рәхмәт хаты, хакимиятнең бүлекләре, шәһәр берләшмәләре һәм иҗтимагый оешмаларның, спорт, социаль, мәдәни, яшьләр идарәсе мактау кәгазьләре һәм кыйммәтле

бүләкләр белән бәяләнә.

Спорт юнәлешендә һәм иҗтимагый тормышта эшчәнлеге зур. Ул шашка уены буенча Спорт мастерлыгына кандидат, Яр Чаллы шәһәре шашка Федерация президенты, халыкара шашка уены буенча Татарстан чемпионы. Армрестлинг буенча Спорт мастерлыгына кандидат. Армрестлинг көрәше буенча халыкара турнирда көмеш призеры. Юртаклар чабышында күп тапкырлар Сабантуй җиңүчесе. Яр Чаллы шәһәре Ветераннар советы президиумы әгъзасы.

Сугыш-патриотик тәрбия эшчәнлеге өчен тәбрикнамә һәм рәхмәт хатлары, хәйрия һәм иҗтимагый эшмәкәрлеге өчен орден һәм медальләр белән бүләкләнә. Шулар арасында – “За гуманизм и милосердие”, “Адмирал Кузнецов”, “Почетный орден комсомола”, “За мужество и гуманность”, “Возрождение”, хәрби диңгез флоты юбилей медальләре, ветераннар хәрәкәте һәм Бөтенсоюз инвалидлар җәмгыяте исеменнән юбилей медальләре һәм мактау кәгазьләре бар.

Шагыйрь-прозаик Рәкит Аллабирденең иҗатында ямьлебай табигатькә, эчкерсез-тырыш кешеләрнең бәйләнеше киң чагылдырыла. Иҗатында тормыш юлдашы Гөлчирәнең ярдәме зур. Сөю-мәхәббәт, гаиләгә кагылышлы әсәрләрендә – Гөлчирә образы. Хатын-кызның тырыш-уңганлыгы, сабырлыгы, эчке матурлык белән чибәрлекнең тәңгәллеге аңа багышланган “Алиһә” китабында ачык курсәтелә.

Рәкит Аллабирде 1988 елдан Яр Чаллы шәһәре төбәк язучылары белән тыгыз элемтәдә. “Ләйсән” әдәби-иҗат берләшмәсе бюро әгъзасы буларак, тәү каләм тибрәтүчеләргә ярдәме зур. Рәкитнең тормыш агышындагы хәйрия игелекләре әдәби-сәнгать эшчәнлегенә үрелеп бара. Талантлы шагыйрьнең әсәрләре шәһәр һәм Республика вакытлы матбугатында “Аргамак”, “Мәйдан”, “Казан утлары”, “Идел” журналларында даими басыла. Туган ягына багышланган әсәрләре Башкортостан матбугатында да урын ала. “Аллабирде” (1996), “Хыял атым” (2011), “Влюбленные души” (2012), “Җаным тама” (2016), “Сулыш” (2017), “Әтәч елы” (2017), “Яшьлегем тугае” (2018), “Алиһә” (2018), “Гашыйклар халәте” (2019) дип исемләнгән бәян, хикәяләр, шигырьләр җыентыклары авторы. Татарстан

язучылар берлеге әгъзасы.

Шагыйрь туган ягы – Мораптал төбәге белән тыгыз элемтәдә. Хәйрия фонды җитәкчесе буларак балалар Сабан туе үткәрүдә ярдәме өчен, "Киров" исемендәге авыл үзидарәсе рәисе Тукаев Рәмил Гыйләҗ улы исеменнән мактау грамотасы белән бүләкләнә. Язучы туган ягына багышланган "Сулыш" бәяне аерым китап булып дөнья күрү уңаеннан авыл клубында "Морапталда шигърият бәйрәме" дигән иҗади-сәнгати кичә үткәрә. Кичә барышында шагыйрьнең туган якка багышланган шигырьләре укыла, җырлары башкарыла. Кичәдә язучыга авылдашлары исеменнән җылы сүзләр әйтелә. Көергәзе районы төбәк гәҗите – "Юшатыр"да бу күркәм чара турында бик тәэсирле мәкалә басыла. Рәкит Аллабирде ярдәмендә Мораптал урта мәктәбе укучылары һәм укытучылары иҗатын туплаган "Ургып ага Юшатыр" исеме астында китап дөнья күрә. Бүгенге көндә Мораптал төбәгендә беренче мәктәп ачылуга 100 ел тулу уңаеннан җыентыкның тулыландырылган варианты әзерләнде.

Язучы Яр Чаллы шәһәренең "Чишмә" халыклар дуслыгы йорты белән тыгыз бәйләнештә. Монда үткәрелгән чараларда актив катнаша. "Идел-Урал" хәйрия фонды җитәкчесе буларак, "Шоңкар" башкорт оешмасы каршында эшләгән "Гөлнәзирә" халык ансамбленә ярдәме зур. Башкорт иҗатчыларының "Аманат" әдәби берләшмәсенең әдәби консультанты. Бу көннәрдә берләшмә әгъзаларының Башкортостанның 100 еллыгына багышланган "Аманат" исемле дөем җыентыгы дөнья күрде. Рәкит Яүдәт улы – китапның хәйриячесе һәм мөхәррире.

Язучының туган ягына багышланган "Аллабирде", "Сазанлым", "Юшатыр" әсәрләре иҗатына ямь биреп, туган ягына мәдхия булып тора. Рәкит Аллабирденең сүзләренә язылган җырлары татар һәм башкорт телләрендә башкарыла. Шулар арасында "Эх, Мораптал!", "Кош", "Кичерә күр мәхәббәтем", "Авыл моңы", "Җыр аргамак", "Минем таңнар әле үтмәгән" – бүгенге көндә популяр җырлар.

Язучы бүгенге көндә "Сулыш" әсәренең икенче китабы өстендә эшли.

## КРАТКАЯ АВТОБИОГРАФИЯ РАКИТА АЛЛАБИРДЕ

Поэт и прозаик Ракит Явдатович Абдульманов (Ракит Аллабирде) родился 22 марта 1960 года в деревне Новое Аллабердино Кумертауского района Башкортостана. Первые четыре класса обучался в родной деревне, аттестат о среднем образовании получил в средней школе Новое Мурапталово.

В 1978-1981 годах прошёл срочную воинскую службу в Военно-Морском флоте. В 1982 году приезжает в город Заинск и поступает на работу на колёсный завод «КамАЗа». Во время работы в вечернюю смену получают травму и ему ампутируют ногу... С 1984 года переводится старшим мастером в производственное объединение «Камгэсэнергострой», где вскоре назначается главным инженером спортивных зданий и сооружений. В 1986 году поступает на заочное отделение Камского автомеханического техникума.

Ракит Явдатович с 1996 года является организатором и руководителем Благотворительного фонда инвалидов-спортсменов «Идель-Урал». Он, во главе этого фонда организует путешествия в страны СНГ, многочисленные спортивные и культурные благотворительные мероприятия. Ракит Абдульманов в 2009 году стал победителем конкурсов «Человек золотое сердце» и «Благотворитель года», в 2010 году получил сертификат Российской Федерации «Благотворительность» и в 2013 году в городе Казани удостоен звания «Человек большое сердца». Фонд «Идель-Урал» является обладателем свидетельства «Благотворительность» НБФ Президента Российской Федерации. Также этот Фонд неоднократно награждён Благодарственными письмами Российской Федерации и Правительства Татарстана за укрепления дружбы между народами.

Р. Абдульманов за активную общественную деятельность награждён медалями «За гуманность и милосердие» (Москва, 2009), «За храбрость и гуманизм» (Москва, 2018), а также почётным знаком «За заслуги перед городом Набережные

Челны» (2009), ценными подарками, Почётными Грамотами управлений культуры, спорта, социального развития, управления по работе с молодежью мэрии города Набережные Челны, и другими.

Большую работу проводит он и в области спорта: Ракит Явдатович, будучи кандидатом в мастера спорта по шашкам, является Президентом федерации шашек города Набережные Челны и чемпионом Татарстана по международным шашкам среди инвалидов, а также, будучи кандидатом в мастера спорта по армрестлингу, является серебряным призёром Международного турнира по этому виду спорта. Он – и многократный победитель скачек на рысаках городском ипподроме и на Сабантуях.

Р. Абдудьманов является членом президиума городского Совета ветеранов и неоднократно награждался памятными и юбилейными медалями за активную военно-патриотическую работу.

В творчестве талантливого поэта и прозаика, члена Союза писателей Республики Татарстан Ракита Аллабирде (Абдульманов) нашли широкое отражение судьбы трудолюбивых и благородных современников, красивая и богатая природа родного края. Неоценимую помощь ему по жизни оказывает супруга Гульчира, которая заслуженно является прообразом любимой женщины и надёжной хранительницы очага во многих его произведениях, в том числе и в повести «Алиһә» («Богиня»).

На литературную стезю Ракит Явдатович ступил в 1988 году, когда начал заниматься в Набережночелнинском городском литературном объединении «Лейсян». В его биографии гармонично переплетаются литературно-художественная деятельность с благотворительной и культурно-просветительской деятельностю, поэтому повести, рассказы и стихотворения писателя охотно публикуются на страницах журналов «Майдан», «Казан утлары», «Идель», «Аргамак», республиканских и городских газет. Часто печатаются его произведения и в средствах массовой информации Башкортостана.

Ракит Аллабирде – автор книг «Аллабирде» (1996), «Хыял атым» (Конь мечты», 2011), «Влюблённые души» (2012), «Жаным тама» («Душа льется», 2016), «Сулыш» (Дыхание», 2017), «Әтәч елы» («Год петуха», 2017), «Яшьлегем тугае» («Поляна юности», 2018), Алиһә» («Богиня», 2018), «Гашыйклар халәте» («Судьба влюблённых», 2019).

Поэт находится в постоянной связи с малой родиной, с Мурапталовскими краями. Как руководитель Благотворительного фонда «Идель-Урал» награждён Почётной Грамотой Тукаева Рамиля Гилязовича – председателя самоправления сельского поселения имени Кирова за помощь в проведении детского Сабантуя. Ракит Аллабирде проводит свои творческие вечера в сельских клубах Мурапталовского региона, и заметным вкладом в литературную жизнь родного края стала выпущенная по его инициативе книга «Ургып ага Юшатыр» («Бурно течёт Юшатыр»), куда вошли плоды творчества учителей и учащихся Мурапталовской средней школы.

Ракит Явдатович поддерживает тесную творческую дружбу с культурно-досуговым центром «Родник», активно участвуя во многих проводимых там мероприятиях. Он, как руководитель Благотворительного фонда «Идель-Урал», оказывает большую помощь народному ансамблю «Гульназира», работающему при башкирской общественной организации «Шоңкар» и является консультантом башкирского литературного объединения «Аманат».

Многие песни, написанные на стихи Ракита Аллабирде, стали популярными и исполняются как на татарском, так и на башкирском языках. Среди них очень актуально звучат такие, как «Эх, Морапал!», «Кош» («Птица»), «Кичерә күр, мәхәббәтем» (Сумей простить, любовь моя»), «Авыл моңы» («Деревенская мелодия»), «Җыр – аргамак» (Песня – аргамак»), «Минем таңнар әле үтмәгән» («Зорьки мои пока не минули») и другие.

В настоящее время талантливый писатель работает над второй книгой повести «Сулыш» («Дыхание»).



***Татарстан президенты Р.Н.Миңнеханов «Идел-Урал» хәйрия фондының эшчәнлеге белән таныша***



***Татарстанның беренче президенты М.Ш.Шәймиев «Ел хәйриячесе» дипломын тапшыра***



***Изге Болгар тыюлыгында. Болгар шәһәре мэры Камил Нугаев, Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары Васыйл Шәйхразиев, «Яңарыш» фонды башкарма директоры Татьяна Ларионова, «Идел-Урал» хәйрия фонды җитәкчесе Рәкит Әбделманов***



***Болгар шәһәре инвалидлар җәмгыяте белән очрашуда***

## РАКИТ АЛЛАБИРДЕНЕҢ БАСЫЛЫП ЧЫККАН КИТАПЛАРЫ

## ИЗДАННЫЕ КНИГИ РАКИТА АЛЛАБИРДЕ

Рәкит Атлас. Аллабирде: хикәяләр һәм тарихи эссе: / кереш сүз авт. Ф.Дунай / Р. Аллабирде. – Яр Чаллы, 1996. – 98 б.

Аллабирде, Р. Влюбленные души: рассказы и стихи / перевод с татарского Мансура Сафина / Р. Аллабирде. – Набережные Челны, 2014. – 96 с.

Аллабирде, Р. Хыял атым / Конь-мечта: шигырьләр, поэмалар, җырлар / стихи, этюд, песни / перевод с татарского Мансура Сафина / Р. Аллабирде. – Яр Чаллы, 2014. – 96 б.

Аллабирде, Р. Сулыш: романтик повесть, кыйсса, шигырьләр, җырлар / кереш сүз авт. Равил Лотфуллин / Р. Аллабирде. – Яр Чаллы, 2015. – 348 б.

Аллабирде, Р. Җаным тама: шигырьләр, поэмалар, җырлар һәм кыска бәяннар / кереш сүз авт. Айрат Суфянов / Р. Аллабирде. – Яр Чаллы, 2016. – 122 б.

Аллабирде, Р. Әтәч елы: шигырьләр, җырлар / кереш сүз авт. Айрат Суфиянов / Р. Аллабирде. – Яр Чаллы, 2017. – 88 б.

Аллабирде, Р. Сулыш: бәян, шигырьләр / кереш сүз авт. Рафаил Газизов / Р. Аллабирде. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2017. – 191 б.

Аллабирде, Р. Яшьлегем тугае: шигъри бәян, шигырьләр / Р. Аллабирде. – Яр Чаллы, 2017. – 56 б.

Аллабирде, Р. Алиһә: шигырьләр, проза / кереш сүз авт. Әнвәр Шәрипов / Р. Аллабирде. – Яр Чаллы, 2018. – 112 б.

Аллабирде, Р. Гашыйклар хәләте: шигырьләр, проза / Р. Аллабирде. - Яр Чаллы, 2018. 60 б.

## ӘДӘБИ ҖЫЕНТЫКЛАРДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘРЕ
## ПРОИЗВЕДЕНИЯ, НАПЕЧАТАННЫЕ В СБОРНИКАХ

Аллабирде, Р. Алабирде:[эсседан өзек] / Р. Аллабирде // Ләйсән тамчылары: Яр Чаллы шәһәре Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче “Ләйсән” берләшмәсенең күмәк җыентыгы / төз.: Р.Г. Хәмидуллина. – Чаллы, 2007. – Б. 5-7.

Аллабирде, Р. Ярсып чабам...; Әнкәй; Улыма; Чәчкә; Эх, Мораптал; Кайтам әле дуслар янына; Кичерә күр мине, мәхәббәтем...; Кош җаны; Чаткы; Фанида; Кош: [шигырьләр], Алиһәмә:[нәсер] / Р. Аллабирде // Моң дулкынында: Яр Чаллы шәһәре Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче “Ләйсән” берләшмәсенең күмәк җыентыгы / төз.: Р.Г. Хәмидуллина. – Чаллы: “Ислам нуры” басмаханәсе, 2011. – Б. 7-17.

Әбделманов, Р. Этләр өрә, кәрван...: [шигырь] / Р. Әбделманов // “Ләйсән”– моңлы бишегебез”: Яр Чаллы шәһәре Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче “Ләйсән” әдәби иҗат берләшмәсенең 45 еллык юбилее уңаеннан төзелгән күмәк җыентыгы / төз.: Р.Г. Хәмидуллина, Ә.М. Ситдыйкова. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе. – 2009. – 150 б.

Әбделманов, Р. Чәчкә: [шигырь] / Р. Әбделманов // Әдәби Чаллы / [төз.: Р.Г. Хәмидуллина, Ә.М. Ситдыйкова]. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2014 – Б. 355-356 б.

Аллабирде, Р. Мои Сазанлы; Озеро большое; Птица; Думая о конях Прощание с деревней: [стихи] / перевод с татарского Мансур Сафин / Р.Аллабирде // Знай наших! «стихи членов литературного объединения «Золотые россыпи» / составитель Р.М. Ахметзянов. – Набережные Челны: ООО «Взаимная помощь», 2008. – С.13-21.

Аллабирҙе, Р. Мөхәррир һүҙе. Башҡорт дуҫыма; Батыр һыны; Бәхет; Минең таңдар...; Сәскә; Әнкәй [Шиғырҙар] “Аманат” / Төҙөүсеһе - Г.А.Буранбаева. - Яр Саллы: “Взаимная помощь” ЖЧЖ, 2019. – бб: 3-4, 16-21.

## ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘРЕ

## ПРОИЗВЕДЕНИЯ, ИЗДАННЫЕ НА СТРАНИЦАХ ГАЗЕТ И ЖУРНАЛОВ

Әбделманов, Р. Батыр сыны:[шигырь] / Р. Әбделмәнов // Якты юл. – 1985. – 4 октябрь.

Әбделманов, Р. Сөю:[шигырь] / Р. Әбделмәнов // Якты юл. – 1987.

Әбделманов, Р. Безнең шәһәр; Дәва:[шигырьләр] / Р. Әбделмәнов // Кама таңнары. – 1987. – 4 октябрь.

Әбделманов, Р. Зур өметләр баглап:[Тукай районы “Искра” колхозы рәисе Фирдәвес Гәрәев эшчәнлеге хакында] / Р. Әбделманов // Якты юл. – 1991. – 4 июнь.

Әбделманов, Р. Трамвайда: [чынбарлык сурәтләре] / Р. Әбделмәнов // Шәһри Чаллы. – 1994. – 2 август.

Әбделманов, Р. Аллабирде; Җир...;Әнкәй; Мәчет карты; Каргалган замана; Бәхилләнгән нәсел; Аръяк урысы; Сазанлы; Таркалмаган нигез; Хуш, авылым!: [нәсерләр] / Р. Әбделмәнов // Аргамак. – 1995. – № 4. – Б.182-195.

Әбделманов, Р. Трамвайда: [булган хәл] / Р. Әбделманов // Ватаным Татарстан. – 1995. – 14 декабрь.

Әбделманов, Р. Гашыйклар халәле; Аймылган яшен: [ике кыйсса] / Р. Әбделманов // Нур. – 1995. – 16 ноябрь.

Әбделманов, Р. Гашыйклар халәле: [ике кыйсса] / Р. Әбделманов // Нур. – 1995. – 18 ноябрь.

Әбделманов, Р. Силос исе: [ике кыйсса] / Р. Әбделманов // Нур. – 1995. – 23 ноябрь.

Әбделмәнов, Р. Аек тормыш: [хикәя] / Р. Әбделмәнов // Шәһри Чаллы. – 1995. – 23 нояб.

Әбделманов, Р. Силос исе: [ике кыйсса] / Р. Әбделманов // Нур. – 1995. – 25 ноябрь.

Әбделманов, Р. Силос исе: [ике кыйсса] / Р. Әбделманов // Нур. – 1995. – 30 ноябрь.

Әбделманов, Р. Динозаврчыкларым: [парча] / Р. Әбделмәнов // Шәһри Чаллы. – 1996. – 17 февраль.

Әбделманов, Р. Упкын чатында: [хикәя] / Р. Әбделмәнов // Шәһри Чаллы. – 1996. – 6 апрель.

Абрамишвили, Д. Бердәмлек ныгыр: [шигырь] / Д. Абрамашвили / Рәкит Әбделманов тәрҗемәсендә // Нур. – 1996. – 22 июнь.

Атлас, Р. Чиркәү нигезенә куелган кабер ташы: [шигырь] / Р. Атлас // Нур. – 1996. – 16 декабрь.

Атлас, Р. "Идел-Урал": [сәяхәт көндәлегеннән] / Р. Атлас // Аргамак. – 1997. – № 5-6. – Б.118-121.

Атлас, Р. Чиркәү нигезенә куелган кабер ташы авазы: [Гаяз Исхакый истәлегенә багышланган шигырь] / Р. Атлас // Аргамак. – 1997. – № 5-6. – Б.122-123.

Атлас, Р. Динозаврики мои: [аллегорический этюд] / Р. Атлас / перевод с татарского Мансура Сафина // Аргамак. – 1997. – № 12 – Б.176-179.

Рәкит, А. "Идел"дә рәхәт: ["Идел" реабилитацияләү үзәгендә ял итү хакында] / А. Рәкит // Яшел Үзән. – 2002. – 4 июнь.

Рәкит, А. Эх, язмышым..: [нәсер] / А. Рәкит // Яшел Үзән. – 2002. – 4 июнь.

Аллабирде, Р. Бер пар халык; Яшь әби: [шигырьләр] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2012. – 10 сентябрь.

Атлас, Р. Ярсып чабам...; Бәхет; Кайда төшим?; Хыял атым: [шигырьләр] / Р. Атлас // Безнең фикер. – 2014. – 25 март.

Аллабирде, Р. "Ургып ага Юшатыр":[истәлекләр белән урталашып] / Р. Аллабирде // Көмеш кыңгырау. – 2014. – 19 апрель.

Аллабирде, Р. Кайда төшим; Гаярьләр; Хыял атым; Лачын; Хәйрия; Бәхет: [шигырьләр] / Р. Аллабирде // Казан утлары. – 2016. – № 6. – Б.168-170.

Аллабирде, Р. Алиһәмә: [нәсер] Гаярьләр; Чәчкә; Бер пар халык; Кичерә күр мине, мәхәббәтем; Әнкәй; Кайтам әле дуслар янына; Яшь әби; Фанилыкта: [шигырьләр] / Р. Аллабирде // Мәйдан. – 2013. – № 8. – Б.105-108.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьтан өзек] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2014. – 15 август.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2014. – 26 август.

Аллабирде, Р. Юшатыр; Тирән җир; Әйләнмә; Кпыйл чыгышы; Сәкеле җир; Басма: [шигырьләр] / Р. Аллабирде // Шәһри Чаллы. – 2014. – 27 август.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2014. – 8 сент.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2014. – 23 сент.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2014. – 15 окт.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2014. – 23 окт.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2014. – 7 нояб.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2014. – 21 нояб.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2014. – 8 дек.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2014. – 22 дек.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 14 янв.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 26 янв.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 9 февр.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 24 февр.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 9 март.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 23 март.

Аллабирде, Р. Зур күл; Кош; Атлар янында; Хуш, авылым!: [шигырьләр] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 23 март.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 13 апрель.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде

// Безнең фикер. – 2015. – 23 апрель.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 13 май.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 23 май.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 25 июнь.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 15 июль.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 22 июль.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 25 июль.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 7 окт.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 18 окт.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 22 окт.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 9 нояб.

Аллабирде, Р. Сулыш: [повестьның дәвамы] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2015. – 17 нояб.

Аллабирде, Р. Ташу үтә; Минем таңнар; Көнләшү...; Адмирал; Онык: [шигырьләр] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2016. – 24 февраль.

Аллабирде, Р. Җаным тама; Бәхет; Хәйрия; Лачын; Хыял атым; Кайда төшим; Әнкәй; Көнләшү:[шигырьләр] / Р. Аллабирде // Кызыл Таң. – 2016. – 19 май.

Аллабирде, Р. Бәхет; Хыял атым; Кайда төшим: [шигырьләр] / Р. Аллабирде // Мәйдан. – 2016. – № 7. – Б.111-112.

Аллабирде. Р. Эх, Мораптал: [шигырь] / Р. Аллабирде // Юшатыр (Күмертау). – 2016. – 7 ноябрь.

Аллабирде, Р. Әтәч елы: [шигырь] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2017. – 12 янв.

Әбделманов, Р. Байлык җитә...;[шигырь] / Р. Әбделманов //

Шәһри Чаллы. – 2017. – 26 апрель.

Аллабирде, Р. Кпыйл чыгышы; Әти иңе; Әнкәй; Улыма; Юшатыр; Әйләнмә; Онык; Сәкеле җир; Басма::[шигырьләр] / Р. Аллабирде // Көмеш кыңгырау. – 2017. – 13 май.

Аллабирде, Р. Фән юлында; Адмирал; Кушагач; Онык; Балалар сабан туе; Улыма; Әти иңе: Яшәеш дәвамы:[шигырьләр] / Р. Аллабирде // Көмеш кыңгырау. – 2017. – 20 май.

Аллабирде, Р. Яшьлегем тугае; Соңлады: [шигырьләр] / Р. Аллабирде // Шәһри Чаллы. – 2017. – 9 июнь.

Аллабирде, Р. Оран-җил: [шигырь] / Р. Аллабирде // Шәһри Чаллы. – 2018. – 13 июнь.

Аллабирде, Р. "Гөр-гөр тавыш": [шигырь] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2017. – 22 июнь.

Аллабирде, Р. Эт елында; Оран-җил: [шигырьләр] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2017. – 29 дек.

Аллабирде, Р. Якты мизгел; Тәнәфес; Хәзинә; Ак алъяпкыч; Серле елга; Яшьлек моңы: [шигырьләр] / Р. Аллабирде // Безнең фикер. – 2018. – 12 май.

Әбделманов, Р. Җаным тама; Хәйрия; Чәчкә; Онык; Әти иңе; Хыял атым; Кайда төшим; Бәхет: [шигырьләр] / «Якты юл». - 2019. - 19 июль.



*Яр Чаллы шәһәренең каләм ияләре белән бөек шагыйрь Габдулла Тукайның туган авылы Кушлавычта*

## ИҖАТ ҺӘМ ТОРМЫШ БИОГРАФИЯСЕ ТУРЫНДА

Дунай, Ф. Сөенеч: [Рәкит Әбделманов иҗатын бәяләп] / Ф. Дунай // Нур. – 1995. – 16 ноябрь.

Рәкит Әбделманов: [биографиясе] / Р. Әбделманов // “Ләйсән”– моңлы бишегебез”: Яр Чаллы шәһәре Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче “Ләйсән” әдәби иҗат берләшмәсенең 45 еллык юбилее уңаеннан төзелгән күмәк җыентыгы / төз.: Р.Г. Хәмидуллина, Ә.М. Ситдыйкова. – Яр Чаллы: Яр Чаллы типографиясе. – 2009. – Б. 150.

Хуснулхак Мухаметкашифович...: [о древе жизни семьи Абдуль-мановых] // Баширов, Я. Сквозь толщу времен // Я. Баширов. – Уфа. – “Китап” изд., имени Зайнаб Биишевой. – 2010. – Б.256-259.

Рәхмәтуллина, Р. “Артка юл юк”: [Рәкит Әбделмановны юбилее белән котлап] / Р. Рәхмәтуллина // Шәһри Чаллы. – 2010. – 24 март.

Рәкит Аллабирде: [тормыш юлы, иҗади эшчәнлеге турында] / Р.Аллабирде // Моң дулкынында: Яр Чаллы шәһәре Язучылар оешмасы каршында эшләп килүче “Ләйсән” берләшмәсенең күмәк җыентыгы / төз.: Р.Г. Хәмидуллина. – Чаллы: “Ислам нуры” басма-ханәсе, 2011. – Б. 7-8.

Рәкит Аллабирде: [тормыш юлы, библиография] / Р. Аллабирде // Әдәби Чаллы / [төз.: Р.Г. Хәмидуллина, Ә.М. Ситдыйкова}. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2014. – Б. 355-356.

Кулыма каләмне сирәк алам: [Рәкит Атлас иҗатына бәяләмә] // Безнең фикер. – 2014. – 25 март.

Котлы булсын туган көнең!: [Рәкит Әбделмановны туган көне белән котлап] // Безнең фикер. – 2015. – 23 март.

Чираттагы изге гамәл: [шәһәр ипподромында үткән сабан туе хакында] // Безнең фикер. – 2015. – 25 июнь.

Туган көннәр:: [Рәкит Әбделмановка багышланган шигырь] // Шәйхетдинов, А. Җылы дулкын җанны били...: шигырьләр / А.Шәйхетдинов. – Казан: “Идел-Пресс” нәшр., 2015. – Б. 79.

Хәлимов. З. Күңелендә аның җылы кояш: [Р.Әбделмановка 55 яшь тулу уңае белән] / З.Хәлимов // Шәһри Чаллы. – 2015. – 27 март.

Торам яшьлек белән кочаклашып!: [биографиясе һәм иҗаты] // Кызыл Таң. – 2016. – 19 май.

Ахметзянов, Р. Знакомы мы с тобой немало лет: [стихи Ракиту Абдульманову, поэту, предпринимателю и общественному деятелю к 55-му юбилею] / Р. Ахметзянов // Ахметзянов, Р. Послесловие: стихи / Р. Ахметзянов. – Набережные Челны, 2015. – Б. 84.

Рәкит Аллабирде: [тормыш юлы, иҗат эшчәнлеге турында] / Р. Аллабирде // Мостафин, Р. Истәлекләр: / Р. Мостафин. – Яр Чаллы, 2016. – Б. 104-107.

“Очкын чәчеп үтү кирәк”: [Рәкит Әбделманов иҗатына багыш-ланган, өлкән сыйныф укучылары өчен, әдәби-музыкаль кичә сценариясе] // Хәмидуллина, Р. Китапханә сәхнәсе: китапханәчеләргә, балалар бакчалары тәрбиячеләренә, сыйныф җитәкчеләренә ярдәмлек. Знче чыгарылыш / Роза Хәмидуллина. – Казан: “Школа” редакция-үзәге, 2016. – Б. 144-150.

Гәлиева. Р. Мораптал илендә шигырь хаким булды:[Рәкит Әбделмановның туган авылында үткән кичә хакында] / Р. Гәлиева // Юшатыр (Күмертау). – 2016. – 07 ноябрь.

Мөбәрәкшина, З. “Әсәрләремдә татарларның башкортлар белән дус яшәгәннәрен чагылдырам”: [Рәкит Әбделмановның “Сулыш” дип исемләнгән китабы басылып чыгу уңае белән] / З. Мөбәрәкшина // Шәһри Чаллы. – 2017. – 4 окт.

Газизов, Р. Ышанам: [Рәкит Аллабирденең “Сулыш” китабын бәяләп] / Р. Газизов // Безнең фикер. – 2018. – 12 май.

«Шигъри гөләндәм» Рәкит Әбделманов// «Якты юл» - 2019. - 19 июль.

Рәкит Әбделманов: [язучы биографиясе] // Якты юл. – 2019. – 19 июль.



# I

***Җиһан киңлегенә сыймый шигырь –***
***Күкләр ташый, ургый, коела!***
***Тереклеккә үтеп, җанга сеңеп***
***Һәр күзәнәк саен уела.***

**“Замандаш”**

## РӘКИТ АЛЛАБИРДЕНЕҢ ИҖАТ ҮРНӘКЛӘРЕ

### *“ОЧЫГЫЗ ИРЕККӘ...”*

Шигърият дәрьясына чумганда кулыма каләмне сирәк алам...

Шигырьләремне яттан сөйләргә яратам. Шулай миңа да күңелле, аларга да рәхәт кебек. Җаным-тәнемнең һәрбер күзәнәгендә яралган шигырь юлларым күңелемдә җанлана-үсә баралар да, шигърият сахрасына талпыналар...

Каләмдәшләрем арасында, көненә берничә шигырь чыгарып, елына 2-3 китап бастырып алырга өлгерүчеләр дә бар. Мин алай булдыра алмыйм... Нәни генә шигырьне дә күңелем биләвендә тибрәндерә-тибрәндерә үстерәм, аннары сак кына, якты дөнья белән таныштырам.

Башкалардан: ”Ничек инде, барлык язганнарны да истә калдырып буламыни?” – дигән сүзләр ишеткәлим...

Ничек истә калмасын ди инде?

Күңелемнең иң нечкә кылларында яралган зиһен моңнарым ич алар...

Соңгы шигырь китабым дөнья күргәнгә шактый гомер узган икән... Инде күңел төпкелләрен барлап, яңа җыентык тупларга да вакыттыр, инде...

Кулыма каләм алам.

Әммә... Кайбер шаян хисләрем, матбугат-нәшрият кысаларының таләп-кагыйдәләргә буйсынырга теләмичә, карыша-киреләнә башлыйлар, аларны бернинди калыпларга да куып кертү мөмкин түгел кебек...

Мин, сөекле бунтарьларыма каршы бара алмыйм – каләмемне ташлыйм! Яңадан үз хәләтемә, эчке дөньяма, җан кисәкләрем – шигырь юлларыма әйләнеп кайтам...

Карасанә! Баксаң, йөрәк пәрәләрем күптән үк үз ишләрен табып, матур гына аралашып яшиләр икән бит! Әнә, калып-кысаларсыз да, тигез-көяз басып, “Менә без нинди!” – дигән кебек, шук елмаеп карап торалар.

И-и сөеклеләрем, ак юл сезгә! Мин, язмаларымны ничек бар, шул килеш таратып җибәрәм...

*Очыгыз ирекkә, шигърият күгендә*
*Якты эз калдырып үтегез!*
*Кем тели калыгыз, күңелем түрендә*
*Яңа җыр йомгагын сүтегез.*

## ***АЛИҺӘМӘ***

Эх, язмышым...

Хәрби диңгез флотында хезмәт итеп кайтып, зур өметләр белән язмышына ияреп КАМАЗ заводларына килгән һәм флоттагы һөнәре белән ашкынып эшли башлаган эчкерсез-хыялый Башкортостан егетен һәлакәткә тапшырып, аяксыз калдырдың...

Гомер буе нужа куган, фидакарь-эшче нәселне дәвам итүченең, кичке укуга кереп, аң-белемле зур тормышка таба ныклы адымнар белән юл аласы бар иде...

Тиз арада шәһәрнең жыелма командасына алынып, волейбол буенча үрләр яуларга омтылган типсә тимер өзәрдәй егетне, бер командада иңгә-иң терәп көрешкән хирург-дустының хафаланудан калтыранган скальпеле аша спорттан мәңгегә аерырга теләдең...

Моңга гашыйк, гармунчы, очып-очынып биергә яратучы егетнең күңелендә өерелгән ташкын-хисләрен томаларга, ихтыярын басарга булдың бугай...

Иптәшләре шау-гөр килеп эшкә жыенганда, тулай торак бүлмәсенең тынчу-кысан почмагында авыр уйлары белән ялгызы калдырдың. Эш-тияреннән мәхрүм итеп, мохтажлыкка дучар иттең...

Дус-ишләре шаярткалаган булсалар да, карашларында шөбһә-шик бар: “Үз-үзенә кул салмаса иде...”

Аһ, язмышым... Матур яз аенда, аяз-кояшлы иҗат күгеннән бөтереп, дөм-караңгы тормыш төбенә, гарип-горәбәләр

дөньясына ташладың. Аһ-зарлы голәмадә, тирә-юньгә моң чәчрәтеп бәреп торган дәрт чишмәсе кибәр, ихтыяр-кодрәте сүнәр, сиңа буйсыныр, дип инандың...

Тик син ялгыштың!

Минем янда тагын бер җан барын белмәдең.

Белә дә алмыйсың - аның үз язмышы. Мин аның тәкъдиренә кушылам.

*Әле минем*
*Тереклеккә юл-күперләр*
*саласым бар.*
*Кешелеккә шул юллардан*
*атлыйсым бар.*
*Мохтаҗларны үзем белән*
*әйдисем бар.*
*Изге жанлы мөхәббәтем*
*Аңлыйсым бар!*

Мин өр-яңадан аяз күккә үреләм...

Исәнме, Кояш!

## *АҺӘҢ*

(Сүз башы)

*...Ялгыз агач. Кайда шаулап торган*
*Күкрәп үскән горур тирәклек?*
*Җайлап кына үтә, йомарт җирне*
*Талый бара шәрә сирәклек...*

“Кош”

Көзнең соңгы гарасаты, бар гәйрәтен җигеп, авыл тирәләрен айкады-айкады да урам башындагы йөзьяшәр тирәкне, төбе-тамыры белән кубарып, юл читенә алып ташлады. Бу тирәк, ябалдашларын киң җәеп, бер урамлы авылны яшел төскә манып, җәйге челләләрдә тирә-якны күләгәсе белән саклап, кай-

нар һаваны җиллэтеп торса, кышкы зәмһәрир салкыннарга түзеп, әче җилләрне өй-каралтыларга үткәрми саклап-ышыклап торган агачсыз калгач, урам ялангачланды, авыл ятим калды, көз тагын да шыксыз тоелды...

Дөнья дарьяларын гизгән, ниһаять юл-тәкъдирләре туган якка кайтарган бәхет эзләүчеләрнең, авыл урамына кергәнче Зыялы чичән Аю бабай утырткан тирәк янында бераз хәл җыеп, өс-башларын рәтли-рәтли, очрашу мизгелләре алдыннан кичергән татлы сагыну хисләре, киткәннәрнең соңгы хушлашкандагы аерылышу сагышының аһәңе генә сыкрады...

Аяусыз ээәрлекләгән замана җилләреннән ышыклану эзләп, мәгърур Урал тау итәгендә ургып аккан әрсез Юшатыр елгасы буенда, күркәм-юмарт Сазанлы куенында яклау-иркәләү табып, Яңа Аллабирде авылына нигез салган татар мосафирларының арба тәгәрмәчләре шыгырдавыннан башланган борынгы аһәңдә халкымның моң-зары да, бәхет-кайгысы һәм кеше күңелен юаткан кошлар тавышлары, курай моңы гармуным чыңлавына кушылып, бердәнбер мәхәббәтем белән тәүге очрашуның кадерле мизгелләре чагыладыр кебек...

Кайчандыр тигез нигезләрне тутырып утырган өйләрне, бер-берсенә сыенган бакча-сарайларны уратып тезелгән горур тирәкләрнең әһәңе, ауган агачның ярдәм үтенгән кебек күккә таба тырпайган тамыр-бармакларын кочып-сыйпап үткәч, сирәкләнгән нигезләрне барлап, хушлаша-эзләнә урам өстендә бөтерелде-бөтерелде дә, бәхилләү табалмыйча, һавага таралып тоныкланды, сүнде...

Бу язмаларның дөнья күрүенә – тарих катламнарының тынычлыгын бозмый-кузгатмый гына, бары тик гаять дәрәҗәдә самими-ихлас, әмма кылган гамәлләрендә тәвәккәл, нинди генә авыр чорларда да киң күңеллелеген саклый алган кунакчыл, ихтыярлы, гадел авылдашларымны сагынып-барлап, яңа буын белән бергәләп ата-бабаларыбыз төбәген тагын бер кат (бәлки, соңгы тапкыр?..) әйләнеп килү ихтыяҗы әйдәгәндер...

Бәлки, шуңа да язмыш өермәсе, чалт аяз, кояшлы тормыш

күгеннән кубарып алып, кырыс чынбарлыкның төпкеленә томырганда да, хыял атының ялына чат ябышып, һаман максатына – илаһи яктылыкка таба омтылган шушы авылның бер баласы аша бәян ителгән хатирә-истәлекләр, һичшиксез, туган ягыма кагылышлыдыр.

Омтылышым – төрле якларга сибелгән авылдашларымның хозурына ирешеп, аларның хәтер төпкелләрендә сакланган истәлекләрен яңартып, күңелләре туган якка, туган туфракка тартылып, уңдырышлы җирдә яңа үсентеләр баш төртеп, агачлар шаулавы, кошлар тавышы, балалар чыр-чуы белән тулган авазларга төренгән авылга хис-кичерешләремнең кайтавазы – аһәңебез кайтканын күрү теләгедер...

Ә инде нәрсәнедер дәлилләү-исбатлау яисә инкяр итүне мәңгелек хакыйкать – галиҗәнап ВАКЫТ агышына тапшырыйк.

*07.06.2014 ел.*

## *КҮЧТӘНӘЧ*

Туган якның мәрхәбәт-игелекле табигатенә төренеп-иркәләнеп үсеп җиткәч, заясыз тормыш кичешен саклап торган авыл җирлеге ызаны аша гаярь ыргып-атлап, артабан гомер-ат дилбегәсен шәһәр эш-көнкүреш коймасына бәйләгән мосафир зат өчен, туган яктан килгән күчтәнәчләр – яшьлек хәтирәләре бигрәк тә кадерледер...

Кулымда Башкортстан иленең көньяк капкасы – Мораптал җирлегеннән җибәрелгән төенчектә сәләтле якташларымның иҗат җимешләре. Күзгә ятышлы, үзе генә дә мәктәп елларымның күпме истәлеген яңарткан, укучылар дәфтәренең тауша-ла төшкән тышлыгын каударланып ачып, шакмаклы битләргә тезелгән юл-җөмләләргә каләмемне сак кына тидергәләп, игътибар-кызыксыну илә укыганда, күңелемдә ихлас сөенү хисе тулыша бара.

Бигрәк тә балаларның әти-әниләргә ярату-рәхмәт белән сугарылган самими-садә шигырь тәлгәшләре, авыр сугыш михнәтләре кичкән әби-бабайларга (җирлектә – олатай,

әләсәйләргә) олы ихтирам-хөрмәт багышлаган, туган як күренешләренә чиксез соклану тасвирланган язмалар, балачагымның җылы җиле булып күңелне иркәли, җанымның һәр күзәнәге рәхәт-кадерле хатирәләрдә тибрәнә...

Һичшиксез, бу җыентык – гомер буе балалар укыткан әнием Гайшә Хөснулхак кызына, класс җитәкчем – Фирдәвес Шәфкәт кызына, әлбәттә, бүгенге көндә балалар белән шигърият дәрьясындә йөзүче – Эльфира Кәрим кызына һәм гомерләрен тәрбия эшенә багышлаган барлык изге җаннарга Ходай рәхмәте, балалар тергезгән иҗади учак – туган төбәгебезгә үзенчәкле һәйкәл-мәдхиядер...

Яшь талантларыбызга иҗат күгендә аяз-кояшлы көннәр теләп, сәнгати киңлекләрдә илһам канатлары талмыйча-талчыкмыйча очу, хыял-теләкләренә ирешү юрыйсы килә.

Газиз халкыбызга хезмәттә уңай җилләр насыйп булсын, кадерле якташларым!

*12. 07.2016 ел.*



***Рәкит Аллабирде каләм тибрәтүче яшь якташлары белән (Башкортостанның Мораптал авылы мәктәбендә)***



# II

***Каләм тотсам, халәтемдә сорау –***
***Хыялыймы шагыйрь, күрәзәме?***
***Акка тамган хиснең чынбарлыгы***
***Тик үземә генә сизеләме...***

**“Җавап”**

## ТОРМЫШ ҺӘМ ИҖАТ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТУРЫНДА

## ОТЗЫВЫ О ТВОРЧЕСТВЕ ПИСАТЕЛЯ

Рафаил ГАЗИЗОВ,
*шагыйрь, прозаик.*
*Шәйхи Маннур, Фатих Хөсни, Һанс Кристиан Андерсен исемендәге әдәби бүләкләр иясе.*

### ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕНӘ РЕКОМЕНДАЦИЯ

Мин, язучы Рафаил Газизов, Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче Рәкит Әбделмәновны, Рәкит Аллабирдене, бер ничә еллар дәвамында беләм  Кеше буларак та, иҗатын да. Башкортстанның Кумертау районы Яңа Аллабирде авылында туган егетне язмыш Чаллыга китергән. Ул Чаллыда мөмкинчелекләре чикле булган кешеләр оешмасы җитәкчесе, изге гамәлләр кыла. Балтик флотында хезмәт итеп кайтуга бәлага юлыккан яшь егет тормыш сынаулары алдында сынмый, аның гаиләсе, улы, оныгы бар.

Узган гасырның сиксәненче елларыннан вакытлы матбугатта әсәрләрен бастырган Рәкитнең “Аргамак”, “Мәйдан”, “Казан утлары” журналларында да бәян, хикәя, шигырь бәйләнешләре дөнья күргән.

Буген ул – “Аллабирде” – 1996, “Влюбленные души” – 2014, “Хыял атым” – 2014, “Җаным тама” – 2016, “Әтәч елы” – 2017, “Яшьлегем тугае” – 2017,  быел Татарстан китап нәшриятында басылган “Сулыш” исемле җиде китап авторы. Шигырьләре образлы, бәян, хикәяләрен укысаң, аерыла алмыйсың, эләктергеч кармагы бар.Теле үзенчәлекле бер урамлы, кырык йортлы Яңа Аллабирде авылы башкорт, казах, урыс авыллары белән янәшә. Үзенчәлек шуннан киләдер.

Язучы халкына, Туган җиренә бурычын түләү белән бәяләнә. Рәкиткә бу яктан да кызарырлык түгел. Бәян, хикәя, шигырьләр, җырларында да авылы, инде күбесе Ходай хозурына күчкән кешеләре яши. Чишмәләр челтери, Сазанлы инеше дулкын кага, Каркадил җире сулыш ала.

Аның тәхәллүсе дә Аллабирде. Яңа Аллабирде авылы

аның әсәрләрендә генә яшәргә хөкем ителгән...

Иҗаты турында Равил Лотфуллин “Корчагиннар токымыннан”, “Кама таңнары” газетасы, 1987 ел, “Сөенеч” Фаяз Дунай, 1996 ел, Туфан Миңнуллин, 2001 ел, күп сандагы Чаллы язучылары үз фикерләрен белдергән. Мин дә “Сулыш” 2017, ТКН, китабына кереш сүз язып уңай фикерләремне әйттем.

Рәкит Аллабирде бүгенгегә күләмле иҗат белән килде, тормыш тәҗрибәсе җитәрлек. Ул – Чаллы язучыларының дусты, ярдәмчесе.

Аның иҗаты миңа якын, аерма тик шунда әсәрләремдә туган ягым Мамадыш сулкылдый, Кирмән чишмәләре тибә.

Озын сүзнең кыскасы Рәкит Әбделмәновны Татарстан Язучылар берлегенә тәкъдим итәм, аңа ышанам.

*29 сентябрь, 2017 ел.*

## МИН АҢА ЫШАНАМ

(“Сулыш” бәянына бәяләмә)

Әсәр колачлаган чорны дөрес сурәтләве белән көчле. Ул халык тормышын тулы канлы тасвирлый. Кыз белән егет, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне тар кысаларда сурәтләп үз чирәмлегендә генә тырмаланучы тавыкны хәтерләтми. Халык язмышы, авыл язмышы, ил язмышы бар бит әле...

Инде колхозлар таралды. Шаулап иген үскән кырлар далага әверелде. Аллабирде авылының алдынгы комбайнчылары Рифкат, Чулпан, Карамат абыйлар исән микән? Бәлки, ярдәмчеләре Фирдәт, Рәүил, Салават исәндер. Бәян сурәтләгән чорда алар малай булган.

Авылның башлангыч мәктәбе ябылуга да инде дистә еллар узган. Ә аның алыштыргысыз мөдире Гайшә апа, укытучылары, укучылары – һәрберсе үз исеме белән әсәрдә яши. Мәктәп ябылгач, аны сүтәргә ирек бирмичә, мәчет ачарга йөргән усал апалар, авылны тотучы хатын-кызлар һаман да Аллабирде урамында...

Мораптал урта мәктәбенең һәр мөгаллименә юллаган рәхмәт. Сабакташлар. Тулай торак тормышы.

Болар бар да миңа якын, чөнки гомер буе авылда яшим. Мамадыш шәһәренең икенче мәктәбендә укыганда өч ел ту-

лай торакта тордым.

Авыл яшәеше, аның офыксыз мәшәкатьләре. Туган як табигатен тасвирлаганда чәчмә рәвештә язып шигъри дәрәҗәгә күтәрелү, соклану, матурлыкка табынып аңны югалту – барысы да бар “Сулыш” әсәрендә. Авыл тормышын, ишле гаиләләрен җигелеп тартучы Яүдәт, теләсә нинди тимерне суккалап төзәтеп бирүче Мәҗит абыйлар. Авылның маңгайдан тир агызучы тормышын ямьләп:

*Чәй гәрәчи, чәй густый,*
*Чәй густый, корсак пустый...*

– дип такмаклаучы кызык Ишбулды. Андыйлар һәр авылда бар!

*Ватаным Татарста-ан,*
*Ә нигә соң, Казагыста-ан,*
*Йөрәгемдә чыңлый моңнары-ың да,*
*Йөрәгемдә чыңлый моңнары-ың.*
*Ду-ду-ду-ду*
*Ду-ду-ду-ду,*
*Э-һе-һе-һе-һей!*

– дип дуылдатучы казакъ Бәхет җизни.

Кайсыдыр халыкның булдыклысы борча дагалаган. Ә МТСта эшләүче Әсхәт тумыштан ишетми дә, сөйләшми дә, ләкин трактор моторына кулын куеп тора да, кайда төзексезлек икәнен әйтә дә бирә! Сүтә, җыя. Борча дагалап вакытын әрәм итми, чөнки эше муеннан. Ул – чын татар. Яки, менә фронтовик Фәткулла абзый. Авиация берләшмәсе ясый алмаган тешле тимерне ясый да бирә...

“Сулыш” бәянын авылны урталай ярып аккан инеш сыман сер тота.

Волейбол уйнарга, кичке уенга ашкынган Рәкыйпнең тырмалар таккан тракторы Каркадил басуында бата, үсмер малай торба белән сугып уң аягын яралый. Туган ягына Учалыдан 400 чакрым юл үтеп, җигелгән ат белән кайтып йөрүче Хәллә бабай аягын шифалы үлән-яфраклар белән бәйли, авыл яшьләрен җибәреп тракторын чыгарта, тырмаларын теркәтеп тә куйдырта. Ә иртәгесен... Хәллә картның кайтмавы һәм авыл яшьләренең Рәкыйпкә булышмавы ачыклана...

Карлы-бозлы инешкә баткан егетне ниндидер өермә Кирәй карт бусагасына китерә, мотовоз астында калганда уң аягын

рельстан кемдер алып ата... Чөнки авыл ягына таба атлаган егет, авылы каршына җитсә дә борылмады, поезд кереп югалган кып-кызыл офыкта зур түгәрәк булып баеп барган кояшка таба атлады да атлады...

Хикмәт шунда: Рәкыйп гомере буе кояшка таба бара...

Рәкит Аллабирде төрле милләттән булган гади хезмәт кешеләрен якты җылылык белән сурәтли. Күр син аның ирле-хатынлы Кирәй бабай белән Җәннәт абыстаен, Бәхет җизнәсен! Алар – казакъ халкының горурлыгы бит. Тимерче Фәткулланы НКВД тырнагыннан коткарган урыс офицеры, дамаск корычыннан коелган кылычны әсир, тырыш татарга бүләк иткән немец фермеры, армиядәге тугры дусты, Мәскәү егете Николай Морозов, башкорт, Мораптал мәктәбе директоры Рәфыйк Шәрәфетдин улы Сыртланов, әрмән егете Сейран Арутюнян... Нәкъ менә әрмән егетеннән үрнәк алып, безнең Рәкыйп: “Юк инде. Болай булгач кыйналсам – кыйналам, үлсәм – үләм, әмма үзем генә булсам да, татар булып калам барыбер. “Менә татар нинди икән!” – дисеннәр”, – ди. Бу – аның кыйбласы.

Уфа военкоматында кыйналу, Совет армиясендә хезмәт иткәндәге кимсетелүләр, аннан кайткач күргән фаҗига да Рәкыйпнең кыйбласын үзгәртми. Ул татар булып яши.

Варшава килешүе илләре корабларына хәрби өйрәнү өчен китерелгән меңләгән тонналы сугыш боеприпаслары төялгән эшелонны шартлаудан коткарган өчен биреләсе “Адмирал Кузнецов” медале дә Рәкыйп Әбделмәновка 30 ел үткәч кенә тапшырыла...

Рейхстаг түбәсенә дөньяда беренче булып байрак кадаган Газетдин Заһитов искә төшә. Эшләгәндә, сугышканда, коткарганда татар кирәк. Ашаганда, бүлешкәндә, бүләкләгәндә – юк...

Бәян – мәхәббәт чәчәкләре чигелгән кулъяулык. Әти-әнигә, туган җиргә, аның кешеләренә, табигатенә, мәктәбенә табыну. Егетнең өй каршысындагы бакчасында җемелдәүче гөл булып Гөлчирәсе яши. Ул кыз шулай яшәргә һәм бирелергә лаек та:

“Ачык зәңгәр күктә, соңгы болытларны өркетеп-тартып, җилеп узган ак байтал сыны күренеп калгандай булды – гүя, кешелек дөньясында иң гүзәл байлык – эчкерсез сөюгә Каркадил иле, үзенең хәер-фатихасын җиткерүе иде бу... Дөньяда бер чәчкә!”

Рәкит Аллабирденең “Сулыш” бәянын укыгач, якташлары юкка гына еламый. Чөнки әсәр мәңгелеккә күчкән йөзләгән кешеләрне дөньялыкка кайтара, безнең белән янәшә атлата, аларга рәхмәт догасы укый. Без бит онытабыз: Гази Заһитовны, Гайшә апайны, Яүдәт, Фәтхулла, Әсхәт абыйларны, Каркадил басуын, Сазанлы буйларын, авылны мең давылдан саклап имгәнгән, картаепауган теге алып тал тирәкне дә...

Ә бу бәян – аларга изге һәйкәл...

Әсәрнең “Сулыш” дип исемләнүе дә уңышлы. Җандагы, тәндәге һәр күзәнәкне туендыручы туган җир һавасы җитми авылыннан киткәннәргә. Чөнки туган җирнең бар байлыгы, хозурлыгы белән тудырылган иҗат җимеше шул - адәм баласы. Туган җир сулышыннан киселдеңме, дөньяда торуың – инде тоташ йокы исереклеге, сырхаулык.

Һәр заманның үз авырлыклары. Батыршага, Тукайга тормыш җиңел булганмы? Мөхәммәт Мәһдиев, Салих Сәйдәшев ни кичергәннәр дә, Фәнис Яруллин һәм Рәкит Әбделманов ничек яшәгән һәм яши?! Татарга җиңел булган чор тарихта юк һәм булмаячак. Без һәр кыенлыктан җиңүче булып чыгарга тиеш. Бүтән юл юк!..

Бүген стажы юк дип эшкә алынмаган, хезмәт хакы алмаган, өйләнсә, кияүгә чыкса, кайда яшәрбез дип баш ватучы яшьләрнең кыенлыклары баштан ашкан. Ләкин болар үҗәт кеше хәл итмәслек бәла-каза түгел. Рухы сынмаган Рәкыйп образы аларга таяныч булыр.

Мин моңа ышанам. Безне Аллаһ ташламасын.

*13 март 2016 ел.*



***Рәкит Аллабирде остазы Рафаил Газиз белән***

Фаяз ДУНАЙ,
*язучы*

## СӨЕНЕЧ

“Урамда суык, юеш. Карлы-бозлы яңгыр ява...

Ә минем җанымда якты, шатлыклы хис тантана итә! Чөнки чын-чыннан сәнгать әсәрләре булган язмалар укыйм. Чаллы язучыларына күптән таныш булган, һәрдаим аларга булышып торучы миһербанлы ир-егет Рәкитнең әсәрләре алар. Язмаларда реаль тормышчан-табигый персонажлар – кешелекле, тере, үзенчәлекле, уйчан, хисле, кайгылы-хәсрәтле һәм шатлыклы...

Бу язмаларның һәрберсен мин матбугатка, халык хөкеменә тәкъдим итүдән тарсынмыйм...”

Әдәбиятыбызга яңа талант килә, уйлы-хисле, матур телле яңа әдип килә! Ак юллар телик аңа!

*1996 ел.*

Туфан МИҢНУЛЛИН,
*Татарстанның халык язучысы*

Син, энекәш, шәп язасың! Язуыңны берүк ташлама...

Кульъязмаларыңны җыеп, Казанга китер әле. Бик теләп, матбугатта да иҗатың турында бер-ике сүземне әйтер идем. Үзеңне драматургиядә дә сынап карарга кирәк...”

*2001 ел.*

Равил ФӘЙЗУЛЛИН,
*Татарстанның халык шагыйре*

Сиңа, энем, Ходай тарафыннан иҗат сыйфаты бирелгән. Ул ихласлыгы, сафлыгы белән күңел төпкелләренә барып җитә. Синең барлыгың авыр тормыш юлы үтәргә сарыф ителсә дә, иҗатың ташка тамырларын батырган имән кебек үсә - ныгый бара. Мин сине алдынгы, зур фикерле чын шагыйрь дип саныйм.

Айдар ХӘЛИМ,
*Татар язучысы, җәмәгать эшлеклесе*

...Рәкит Аллабирдене прозасы шигъри төс белән сугарылган. Гомумән, аның әсәрләре аерым бер үзенчәлектә - табигати-яшәеш рухлы, авызлыксыз-бәйсез аһәң булып яңгырый.

*2019 ел.*

Рафис СӘЛИМҖАН,
*фәйләсүф,*
*Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы*

...Рәкит Аллабирдедәге үз-үзенә, ил-халкына, сәнгать-теленә тугрылык, эчкерсез-ачык турылык әсәрләрендә яңгырап тора!

*2019 ел.*

Шаһинур МОСТАФИН,
*эзтабар-язучы, Татарстан Язучылар берлеге каршындагы «Хәтер яктысы» экспедиция җитәкчесе. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.*

Язучы, җәмәгать эшлеклесе Рәкит Аллабирдене заманга Ходай тәгалә бирде... Ул тудырган «Сулыш» һәм башка әсәрләрдән киләчәккә сулыш иңә. Көрәш һәм дөреслек, батырлык байрагы ул! Күркәм хәйрия, тагы: татар-башкорт рәхмәте. Мәңгелек очыш, якты-яхшы уңышлар! Яңа ачышлар тусын, дөньяга аһәң тулсын! Сине уку бер рәхәт! Миннән булсын мең рәхмәт!

Әнвәр ШӘРИПОВ,
*филология фәннәре докторы, профессор.*
*Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.*

## СӨЮ ТАҢЫ

Рәкит Аллабирденең “Җаным тама...” җыентыгында “Лачын” дигән шигырь бар. Лачынга эндәшеп, шагыйрь болай ди:

*И лачын, бул соңгы канатым,*
*Үткәндә мәңгелек арасын.*

Лачын образы безнең татар поэзиясендә – сирәк образ. Аңа бары тик көчле рухлы, чынбарлыкны фәлсәфи ноктадан торып чагылдыручы сирәк авторлар гына мөрәҗәгать итә. Шагыйрь әсәрне түбәндәге сүзләр белән тәмамлый:

*Кемнедер гөнаһтан аралап,*
*Озатып калырга дучар мин.*
*Һәм шунда, яңа җан каршылап –*
*Һавада әйләнеп очармын.*
*– Яратып, Җир шарын кочармын...*

Күренә ки, ике өзектә дә шагыйрь дөньякүләм образлар, бөтен кешелек дөньясы өчен әһәмиятле булган әхлакый төшенчәләр белән эш итә. Ул бөтен Җир шарын кочып, бөтен Җир шарына үз җанындагы бетмәс-төкәнмәс ярату, игелеклелек хисләрен сибеп-таратып яшәргә омтыла. Ә бу чиксез мәрхәмәтлелекне ул каян ала соң? Аның чыганагы – ихлас мәхәббәт! Юкка гына җыентыктагы бер бүлекне автор “Мәхәббәт кичешем – йөрәгем тибешем...” дип атамаган бит.

Әлеге бүлек авторның “Алиһәмә” дигән язмасы белән башланып китә. Анда шагыйрь үзенең мәхәббәтен “изге җанлы” дип атый: “Изге җанлы мәхәббәтем, аңлыйсым бар!” – ди. Һәм язмышның рәхимсез сынавына бил бирмәгән, сынмаган-сыгылмаган, көчле рухлы, батыр йөрәкле шагыйрь, язмышның бу сынавыннан соң күңеле белән “яңадан туып” (“Туган көн” шигыре), яңа омтылыш белән “Мин өр-яңадан аяз күккә үреләм... Исәнме, Кояш!” – ди.

...Ихлас күңелле хатын-кыз мәхәббәте!.. Аңардан да

сафрак-самимирәк, аңардан да яктырак, аңардан да тирәнрәк, аңардан да даимирәк һәм аңардан да көчлерәк-бөегрәк хис юктыр ул бу дөньяда! Әгәр берәр ир-атның язмышына шундый мәхәббәт язылган икән, ул – бәхетле кеше! Һәм нәкъ шундый бәхетле кеше генә “Исәнме, Кояш!” дип, бөтен дөньяга-галәмгә ишетелерлек итеп эндәшә ала. Хатын-кызның андый мәхәббәтеннән мәхрүм калган ир-ат бу бөек сүзнең мәгънәсенә дә төшенә алмый, аның ялкынын-көчен дә тоя алмый, бәясен дә белми; ул аның өчен коры, канатсыз сүзләр генә булып калырга мөмкин. Ә менә Рәкит Аллабирде дигән шагыйрьнең өлешенә язмыш алдан ук әнә шундый олы-бөек мәхәббәтне язып куйган. Шунысы куанычлы, аның бу мәхәббәте ниндидер абстракт, һавада очып йөри торган хис кенә түгел, ә ул дөньяви, реаль мәхәббәт. Аның исеме дә бар, ул – Гөлчирә! Фарсычадан алып тәрҗемә иткәндә, ул (“Гөлчирә”-“Гөлчәһрә”) чәчәк кебек нәфис йөзле дигән мәгънәне аңлата. Китаптагы мәхәббәт турындагы барлык шигырьләр дә нәкъ менә авторның тормыш юлдашы, хатыны Гөлчирәгә багышланган. Бу шигырьләре белән Рәкит Гөлчирәгә һәйкәл-памятник сала. Һәм Гөлчирә андый һәйкәлгә бер генә тапкыр түгел, ә йөзләрчә тапкыр лаек та! Бу шигырьләрне укыганда ирексездән Фәнис Яруллинның хатыны Нурсөя искә төшә. Гөлчирә нәкъ менә Нурсөяләр, үз гомерләрен Себергә сөрелгән ирләренә багышлап, алар белән бергә ерак юлга киткән һәм ирләренең сөрген газапларын үз язмышлары белән бүлешкән декабрист хатыннары токымыннан икән.

Шагыйрьнең иҗат чишмәсенең чыганагын аңлау өчен аның “Очу” дигән шигырен укырга кирәк. Әсәрнең исеменнән соң автор “Аяк түгел, хыялларым өзелгәндә, тулай торак бусагасында Гөлчирә пәйда булды...” дигән сүзләрне китерә. Аннан соң үз өлешенә тигән фаҗигане тасвирлый:

*...Кыеп алгач язмыш канатларым,*
*Өзгәләнгән йөрәк сүрелде...*
*Чарасызлык бәргәләгән тормыш*
*Дөм караңгы булып күренде.*

Һәм кинәт дөнья яктырып китә. Аның сәбәпчесе – Гөлчирә!

*...Кинәт шунда, йолдыз атылгандай,*

*Нур-чаткылар күккә сибелде.*

*Коендылар нурда канатларым,*

*Мәхәббәткә дөньям күмелде!..*

Рәкит Гөлчирәнең сабырлыгына дан җырлый; хатын-кызның матурлыгы аның сабырлыгында да икәнлеген искәртә:

*Еллар үткән саен, сабырлык –*

*Өсти сиңа чиксез матурлык!* – ди.

Рәкит Аллабирде шундый бөек вазифаны иңенә алган Гөлчирәне тасвирларлык сүзләр таба белә. “Чәчкә” дигән шигырьдә ул болай ди:

*Карап торам сиңа, һушым китеп, -*

*Фәрештәме бизи һәр көнем.*

*Ходай бүләгеме, могҗизамы –*

*Беренчедәй үтә һәр төнем!*

Шагыйрь үзенең бу хис-тойгыларының гомер буена сузылачагын әйтә:

*Айный алмам бугай гомерем буе,*

*Онытсам да шәраб исләрен.*

*Кичер мине, шашып сөйгән чакта*

*Ташып китсә әгәр хисләрем.*

Үзенең мәхәббәтен аңлату өчен шагыйрь “ут”, “су”, “җир” (елга яры) кебек мәңгелек төшенчәләрне дә куллана. “Сөю нуры” шигырендә ул сөйгән ярына болай дип мөрәҗәгать итә:

*Син курыкма тәүге мәхәббәттән,*

*Сөю хисе изге барысыннан.*

*Дөрләп янган уттан ул көчлерәк,*

*Суны буйсындырган яр сыман.*

Күрәбез, монда да шагыйрь гомумдөньяви төшенчәләр белән эш итә, үзенең глобаль фикерләвен дәвам иттерә.

“Сөю нуры” шигырен ул 1992 елда ук, яшьлекнең әле чәчәк ата башлаган чорында ук язган. Шуңа күрә автор сөйгән ярына, киләчәктә бергә булган очракта, үзендә кабынган көчле хис-тойгыларның мәңгелек булуын, еллар узу белән сүрелмәячәген белдерә:

*Мәхәббәтем – мәңге янар учак,*
*Безнең чәчләр бергә үрелсә.*
*Янар йолдыз мәңге ялкын өстәр,*
*Тәүге хисләр әгәр сүрелсә.* – ди.

Мондый теләген шагыйрь тагын 1996 елда да, “Аңлар идең. Гөлчирәгә” дигән шигырендә дә кабатлый. Үзенең һәрбер сулыш алуын үзенең сөекле Гөлчирәсенә багышлавын әйтә:

*Тойсаң иде – эссе кулларымда*
*Йөрәгемнең чыккан сагышын.*
*Шул вакытта изге бу җанымның*
*Багышлавын синә сулышын.*

Никадәр тирән мәгънә, никадәр көчле хис-тойгылар белән сугарылган бу юллар! Болай итеп бары тик үзенең сөеклесен фидакарьләрчә, чиксез яраткан кеше генә яза ала.

Гашыйк егетнең бу сүзләре коры сүзләр булып кына калмый. “Корабына миһербанлык төяп йөри-йөри” (“Хәйрия”, 2014), “үткән елларына җанын тамдырып калдыра-калдыра” (“Җаным тама”, 2016) еллар уза. Автор кичергән фаҗигадән соң:

*Язлар белән бергә, шаша-шаша*
*Кайта җиргә яшәү дәвамы.*

“Ташу үтә”

Еллар узса да яшьлек яши, мәңге сүнмәс сөю яши:

*Ташу үтә. Соңгы бозлар китә.*
*Кысып куя йөрәк чыдамый.*
*Аянычым – шушы ташкын кебек,*
*Ник яшьлектән күңел чыгалмый...*
– ди шагыйрь “Ташу үтә” шигырендә.

Чыннан да, Рәкит Аллабирде әле бүген дә “яшьлектән чыга алмый”; ул әле бүген дә мәңге сүнмәс мәхәббәте тәэсирендә, “моңнарын җырларына түгә-түгә” яши һәм иҗат итә:

*Минем таңнар әле үтмәгән, –*
*Моңнарым да ташлап китмәгән.*
*Күңелемдә туган җырларымны*
*Гармун көйләренә түкмәгән,*
– ди ул.

Һәм бу чын шагыйрь өчен гаҗәп нәрсә түгел; әнә бит сөекле Тукаебыз нәрсә ди:

*Еллар үтеп, бара торгач картайсам да,*
*Бөкрем чыгып бетсә дә, хәлдән тайсам да –*
*Күңлем минем япь-яшь калыр, һич картаймас;*
*Җаным көчле булып калыр, хәлдән таймас*

“Шагыйрь”

“Минем таңнар” шигырен Рәкит Аллабирде болай дип тәмамлый:

*Юк, юк!*
*Сөю таңы үтеп китмәгән.*
*Шуңа көзләр килеп җитмәгән.*

Әйе, без дә шагыйрьгә киләчәктә беркайчан да менә бүгенге көнге кебек оптимистлык рухын югалтмавын, сөю таңының да мәңгелек булуын, ул таңның беркайчан да үтеп китмәвен теләп калыйк!

*2016 ел.*



***Рәкит Аллабирде белән Әнвәр Шәрипов***

Клара БУЛАТОВА,
*шагыйрә, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе иясе.*

## ТӘКЪДИМ ХАТЫ

Тәкъдимнамә тууына саллы нигез булып Рәкит Аллабирденең соңгы вакытларда гына минем кулыма килеп кергән дүрт китабы тора: «Җаным тама», 2015; «Әтәч елы», 2017; «Яшьлегем тугае», 2017; «Сулыш», 2017.

Миңа аның, барыннан да бигрәк, "Яшьлегем тугае" җыентыгындагы шигъри повесте (хәзергечә бәяне инде) һәм Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан "Сулыш" әсәре охшады. Аларда безнең халыкның туган җиргә, аның табигатенә, теленә, диненә, гореф-гадәтләренә, чыгышына-токымына олы хөрмәт белән яши белгән ихлас җанлы эш кешеләре күрсәтелә. Дөресен әйткәндә, мин, мәсәлән, әдәбият укытучысы буларак та, шагыйрә буларак та, аның "Яшьлегем тугае"н бер тыннан йотылып укып чыктым да күңелемә яттан бикләп тә куйдым. Мин аларны бәяләп язып тормыйм. Ә менә авторның "Сулыш" бәянына бәяләмә биргән әдип-шагыйрь, прозаик, Ш.Маннур, Ф.Хөсни, Х.Андерсен исемендәге әдәби бүләкләр иясе Рафаил Газизовның "Әсәр мәңгелеккә күчкән йөзләгән кешеләрне дөньялыкка кайтара, безнең белән янәшә атлата", яки "Автор халык тормышын тулы канлы тасвирлый... Ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне тар кысаларда гына сурәтләп калмый, ул аларны авыл язмышы, Ил язмышы белән бәйли" – дигән сүзләренә чын ихластан кушылам.

Әдәбият төшенчәсенең әдәп-оят сүзеннән торуын аңлап кулына каләм алган ир-егетләр күбрәк килсен иде безнең сафка!



***Рәкит Аллабирде шагыйрә Клара Булатова белән***

Ризидә РӘХМӘТУЛЛИНА.

## “АРТКА ЮЛ ЮК”

*Шәһәр хакиме Илдар Халиков “Идел-Урал” хәйрия фонды учредителе Рәкит Әбделмановны күркәм юбилее белән тәбрик итте. Һәм озак еллар хәйриячелек эшчәнлеге алып барган, инвалидларны актив тормышка җәлеп иткән юбиляр “Чаллы шәһәре каршында күрсәткән хезмәтләре өчен” билгесе белән бүләкләнде. Мактаулы исемнән һәм күкрәк билгесеннән тыш Рәкит Әбделмановка хаким истәлекле бүләк – хәнҗәр тапшырды.*

Үзенең юбилей кичәсен Рәкит Әбделманов Сара Садыйкова исемендәге концерт залында билгеләп үтте. Кемнең-кемнең, әмма Рәкит Әбделмановның эшчәнлеге халыкка билгесез түгел. Ул учредительлек иткән “Идел-Урал” хәйрия фонды 15 ел эчендә Россия буйлап барлыгы 10 автосәфәр оештырды. 1997 елда инвалид спортчылар Чаллыда билгеле шәхес – Дени Абрамашвили ярдәме белән Кавказга кадәр барып җиттеләр. 2004 елда “Террорга – юк” дигән девиз астында 7 көн эчендә 2 мең километр юл узыл, Мәскәүне әйләнеп кайттылар. Юбиляр һәм аның эше турында сөйләгәндә, “Идел-Урал”-ның шахмат-шашка клубы белән актив хезмәттәшлек итүен дә (биредә инвалидлар арасында да турнирлар үткәрелә), инвалид спортчыларның Россиякүләм бәйгеләрдә актив катнашып килүен дә әйтеп узарга кирәк. Чаллыда инвалидлар Сабан туйлары оештыру да “Идел-Урал” хәйрия фонды инициативасы белән традициягә керде.

Рәкитнең инвалид спорчыларны берләштерүе исә очраклы түгел. Ул үзе дә спортчы. Армспорт буенча инвалидлар арасында узган Россиякүләм бәйгедә – III, республикакүләм фестивальдә шашка буенча – III, теннис буенча II урыннарны яулаган. Рәкит Әбделмановның 2009 елда “Алтын йөрәкле кеше” бәйгесендә җиңү яулавын һәм Татарстанда “Ел хәйриячесе” исеменә лаек дип табылуын да әйтеп узу урынлы булыр.

Кичәнең үзенчәлекле ягы шунда – Рәкит Әбделмановның ярдәмен тоеп яшәгән инвалидларны да, юбилярның хезмәтен

таныган дәрәҗәле кунакларны да үзенә җыйган иде. Күптән түгел "Идел-Урал" фонды Россиякүләм бәйгедә җиңү яулап, 10 миллион сумлык грант отты һәм шуның белән кризис шартларында эштән кыскартылганнарга ярдәм итү мөмкинлегенә ия булды. Шул уңайдан Россия Федерациясе милли хәйрия фондының региональ бүлеге җитәкчесе Юрий Остроумов юбилярга җиңүче таныклыгы тапшырды. Рәкит Әбделмановны ТР Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Чаллы идарәсе башлыгы Гөлнар Әхмәтова, шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Галина Каширина, шәһәрне яшелләндерү хуҗалыгы башлыгы Сәлим Хәбибуллин, "Камгэсэнергострой" ААҖ генераль директоры урынбасары Салихҗан Гайниевлар да тәбрикләде. Рәсми кунаклардан тыш сәхнәгә Галиәхмәт Шаһи, Роза Хәмидуллина кебек иҗат кешеләре дә (Рәкит үзе дә күп кенә шигырьләр, хикәяләр авторы), инвалид спортчылар да күтәрелде. Инвалидлар арасында шахмат буенча дөнья чемпионы Станислав Михеев инвалид спорчыларны оештырып, үз артыннан ияртә алганы өчен Рәкит Әбделмановка рәхмәт белдерде. Инвалид спортчылар юбилярның максатчан кеше булуын билгеләп үттеләр. "Рәкит оештырган чараларда бернинди өзеклек килеп чыкмый, - дип сөйләде Фәнис Нуретдинов, - "Назад хода нет!" – бу юбилярның яраткан сүзе".

Юбилярны тәбрикләргә аның якташлары – "Шоңкар" башкорт җәмгыяте каршында эшләп килүче "Гөлнәзирә" ансамбле дә килгән иде. Рәкит Әбделманов тумышы белән Башкортстанның Күмертау районыннан. Хатыны Гөлчирә белән алар Артур исемле егет тәрбияләп үстергәннәр...

Илле яшь ул әле күп түгел. Рәкит Җәүдәт улы кебек тынгысыз, актив кеше өчен – бигрәк тә. Бүген ул шәһәрдә инвалидлар өчен махсус спорт комплексы төзү идеясы белән йөри. Шәһәр җитәкчелеге тәкъдимне хуплаган, проект әзерләнә, инвесторлар белән сөйләшүләр алып барыла. Рәкит Әбделманов фикеренчә, бу инвалидлар спортын тагын да нәтиҗәлерәк үстерергә мөмкинлек бирәчәк. Юбилярның хыялы – инвалид спортчылар белән 2012 елда Лондонда узачак параолимпия уеннарында катнашу.

*2010 ел.*

Равил ЛОТФУЛЛИН,
*“Ләйсән” әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы,*
*журналист.*

## КОРЧАГИННАР ТОКЫМЫННАН

Әй, язмыш, язмыш!

Син безне һәр адым саен сыныйсың, бөтенләй көтелмәгән, әллә нинди бәлаләргә дучар итеп безнең ихтыяр көчебезне, түзем һәм чыдам булуыбызны, яшәүгә мәхәббәтебезне тикшереп карыйсың. Әйе, мондый бәхетсезлеккә дучар ителгән очракта кайберәүләр төшенкелеккә бирелә, үзенең яшьлек хыялларына хыянәт итә.

Ә менә 22 яшендә аварияга эләгеп, бер аягын югалткан Рәкит Әбделмәнов үзен-үзе бик тиз кулга ала, зур чыдамлык һәм нык ихтыяр көче күрсәтеп, матур яшәү һәм бәхетле тормыш өчен көрәшкә ташлана, бер-берартлы үзенең якты хыялларын һәм планнарын тормышка ашырырга омтыла.

Ул тиз арада сафка баса һәм җиң сызганып эшкә тотына. Кем белә, Рәкиткә тиз арада тормышның алгы сызыгына басарга бәлкем аның әдәбиятка, җырга һәм сәнгатькә булган көчле мәхәббәте ярдәм иткәндер. Һәрхәлдә, иң авыр вакытларда аның белән янәшә беренче мәхәббәте була, балачактан уйнап үскән тылсымлы гармун аның иң якын дустына һәм сердәшчесенә әверелә, ул аңа үзенең кайгы-хәсрәтен, борчу-шатлыкларын, эч серләрен сөйли.

Р. Әбделмәнов 1960 елда тугандаш Башкортстанның Күмертау районында туып үскән, шунда укып белем алган. Урта мәктәбне тәмамлагач, диңгез флотында хезмәт итә, элемтәче һәм механик һөнәрләрен үзләштерә. Зәйдәге көпчәк заводында слесарь булып эшли. 1984 елда иң якты хыяллар белән яшьлек һәм батырлык шәһәре Брежневка килә..

Мәктәптә укыган елларда ук әдәбият белән кызыксына, үзешчән сәнгатьтә катнашып, оста гармунчы булып танылa.

Әле шушы көннәрдә генә Рәкитнең язган шигырьләре

белән таныштым. Әсәрләрдә тормышка олы мәхәббәт, кеше булу һәм яшәү мәгънәсе турында җитди уйланулар ярылып ята, яшьлекнең тәүге һәм бик тә җылы, самими хисләре бөркелеп тора. Әйе, хыяллары якты, планнары матур Рәкитнең. Укучыларыбызга кайбер шигырьләрен тәкъдим итеп, аңа хыялларын тормышка ашыруда ак юл һәм уңышлар телибез.

*1987 ел.*

Дмитрий ПОВЫШЕВ,
*поэт*

**РАКИТУ ЯВДАТОВИЧУ АБДУЛЬМАНОВУ**

Не те богаты, кто имеют много,
А тот богат, кто много раздаёт.
И только щедрый богатеет в Боги,
А жадного богатство лишь гнетёт.

Ты щедро даришь сердцем и рукою,
Твой дар тому, кто слаб, забыт и стар.
Пусть будет ясным небо над тобою!
Пусть будет «миру-мир», а «дару-дар»!

Да – «дару-дар!» – так будем говорить –
В тебе есть дар – умеешь ты дарить!

*22 марта 2010 год.*

Зәбир ХӘЛИМОВ,
*ветеран укытучы*

## ӘБДЕЛМАНОВ РӘКИТ ҖӘҮДӘТ УЛЫНЫҢ ИКЕ “5” ЛЕ АЛУЫ УҢАЕННАН ОЕШТЫРЫЛГАН БӘЙРӘМГӘ

Аллабирде авылыннан
Җәүдәт абый улы ул.
Әткәсенең изге эшен
Дәвам итәр кулы ул.

Гади булып күренсә дә,
Эше белән олы ул.
Хисләр янган йөрәге дә
Шәфкать белән тулы шул!

Бабасыннан мирас алган –
“Яхшылыклар колы” ул.
Чаллы данын күтәрүче
Хәйрияләр юлы ул!

Атларда да чаба үзе,
Көрәштерә куллар да.
Чаңгы белән сала эзен,
Гомер буе юлларда...

Хәтердә озак сакланыр,
Изгелек эзләре бит!
Эшләрең, Рәкит, акланыр,
Син шәфкать күзләре бит!!!

*22 март 2015 ел.*

## КҮҢЕЛЕНДӘ АНЫҢ ҖЫЛЫ КОЯШ

Егерме икенче мартта ике "5" ле алу уңаеннан уздырылган бәйрәменә шулкадәр күп халык җыелыр дип уйламагандыр да Рәкит. Ә бит гомер чаба гына! Чаллы шәһәрендә эшли башлавына гына да 32 ел вакыт узып киткән. Шушы вакыт эчендә күпме каршылыклар үтелгән, күпме җиңүләр яуланган!

Йолдызларга очар хыяллар белән янганда, сөенеч-куанычлар тулы күңелен кара кайгыга батырырга теләгәндәй, бәхетсезлек ишек шакыган. Ләкин шигъри җанлы, тормышка баш-аягы белән гашыйк егет егылмый. Тикмәгә генә аны "татар Маресьевы" дип атамаганнар шул. Рәкит Әбделманов, үзе турында кайгырту урынына, башкаларга ярдәм итү хакында уйлый. Язмыш тарафыннан тез астына сугылганнарның тормышын җиңеләйтү өчен ал-ял белми эшли. Инвалид спортчыларга иганәчелек итүче "Идел-Урал" фондын төзи. Атларда, велосипедларда ерак араларга ничәмә-ничә сәяхәт ясала, инвалидлар өчен Сабантуйлар, кул көрәше ярышлары уздырыла, шахмат бәйгеләре оештырыла... Саный китсәң, башкарылган эшләрнең исәбе-саны, очы-кырые юк. Болар гынамы әле! Инвалидларга эш урыннары булдыру артыннан да чаба Рәкит. Киез итек басу цехы ачып җибәргәч, күңелендә нинди гөлләр чәчәк атканын ул үзе генә белә! Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, язучылар берлегенең шәрәфле әгъзасы Рубис абый Зарипов та Рәкит оештырган чараларда күп мәртәбәләр катнашкан икән. "Аның ихтыяр көченә нык гаҗәпләндем, оста оештыручы булуын күреп сокландым, бик тә саваплы эш башкаруына сәяхәтләр вакытында чын-чынлап инандым!" – диде ул. Рәкит Яүдәт улы Әбделманов хөрмәтенә оештырылган кичәне ямьләп, Рубис абый татар халык җыры "Әй гүзәлем!"не башкарды. Чаллы каласында гына түгел, бөтен Татарстан күләмендә зур ихтирам яулаган сүз остасы, милли кичәләрнең даими алып баручысы Гөлзада ханым Рзаеваның чыгышы йөрәкләрне чемердәтте. "Татарда "Итәгенә ут төшмәгән генә белми" дигән гыйбарә йөри, - диде ул. – "Кеше хәлен кеше белми, үз башына төшмәсә" дигәне дә бар. Үзем-

нең улым фаҗигага юлыккач, тагын да тирәнрәк тойдым инвалидларның никадәр көчле рухлы икәнен!...”.

Юбилярны котлап сүз әйтергә теләүчеләр бик күп булды. Әгәр барысына да сүз бирсәң, кичә тагын берничә сәгатькә сузылыр иде. Шәһәр хакимиятеннән, ветераннар советыннан, мәдәният бүлегеннән, физкультура-спорт идарәсеннән, сукырлар җәмгыятеннән, төрле уку йортларыннан, татар-башкорт дуслыгы оешмасыннан бер-бер артлы тәбрикләүчеләр күтәрелде. “Ләйсән” әдәби берләшмәсеннән Роза Хәмидуллина җитәкчелегендә Амур Фәләх, Айрат Суфиянов, Галиәхмәт Шаһи, Марс Яһудин, Айрат Шәйхетдинов, Фәнис Нуретдиновлар да иҗатташ дусларын котларга килгәннәр.

Күпчелек котлауларга музыкаль ноктаны да инвалид артистлар куйды. Ветераннар ансамбле вальс әйләнде. Регина Кузнецова башкаруындагы “Яшьлегем чишмәләре”, Рябков Александр башкарган «Птица счастья» (“Бәхет кошы”) җырларын тамашачы көчле алкышларга күмде. Журналистлар берлегенең Чалла бүлеге җитәкчесе,язучы Рахман Шәфигуллин, танылган язучы Ягъсуф Шәфиков, ТИСБИдән Рәис Нәҗиповларның җылы сүзләре дә Рәкит күңеленә май булып яткандыр. Башкорт халык ансамбле “Гөлнәзирә” матур җырлар бүләк итте, кичәне алып баручы Эльвира Һадиева өздереп шаян бию башкарды (Эльвираның яраткан укучыларымның берсе икәнен әйтеп тормыйм инде)...Гомумән, Рәкит үзенә генә түгел, барлык инвалидлар өчен дә бәйрәм ясады. Чын иганәче икәнсең, дустым!

*2015 ел.*



***Рәкит Аллабирденең 55 яшьлек юбилеенда. 2015 ел***

Амур ФӘЛӘХ,
*язучы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.*

## РӘКИТ АЛЛАБИРДЕ ИҖАТЫНА КАРАШЫМ

Рәкит Җәүдәт улы Әбделманов – киң җәмәгатьчелеккә таныш исем. Бүгенге болгавыр заманда тормыш-көнкүреш авырлыкларына тарган мохтаҗларга, физик мөмкинлекләре чикле кешеләргә һәрдаим рухи һәм матди ярдәм кулы сузучы буларак “Алтын йөрәкле кеше”, “Ел хәйриячесе” һәм башка мактаулы дәрәҗәләргә лаек булган шәхес! Егерме елдан артык “Идел-Урал” инвалид-спортчылар хәйрия фондын җитәкли.

Хәтерлим, моннан егерме еллап элек, Чаллы каласында чыгып килүче “Аргамак” журналында, Кадыйр Сибгатуллин, Хәниф Хөснуллин, Фаяз Дунай кебек ул чорның күренекле әдипләре белән аралашып, аларның иҗатыннан дәрт-дәрман алып үзе дә каләм тибрәтә башлаган Рәкит Әбделмановның татар шигъриятенә яңа сулыш өрердәй милли рухлы бер шигъри әсәре басылып чыкты. Профессионаллардан алган җылы бәяләмәләр егетне яңа иҗади адымнарга этәрде, күрәсең, - озак та үтми, “КАМАЗ” нәшрияты татар әдәбиятында яңа шәхес Рәкит Атласның (Әбделманов) “Аллабирде” (1996) дип исемләнгән әсәрләр җыентыгын бастырып чыгарды. Ә инде хәзер, саный китсәк, Рәкит Аллабирденең төрле басмаханәләрдә дөнья күргән китап-җыентыклары бер дистәгә якын.

Баштарак үз иҗат җимешләрен “Атлас” дип имзалаган Рәкит әдәби тәхәллүсен “Аллабирде” дип үзгәртте. Бу – аның һәр әсәрендә диярлек телгә алынган, дан җырланган туган нигезе, Башкортостанның Күмертау районына керүче Аллабирде авылы атамасы.

Нинди генә тема яктыртылмый Рәкит Аллабирде әсәрләрендә! Ә иң беренче нәүбәттә, әлбәттә, туган як табигате, якташлар, туган җир темасы. Күп кенә шигырьләрендә, хикәя-бәяннарында гади, аңлаешлы тел белән, туган җиренә хас табигать күренешләре эчке кичерешләр аша

үткәреп тасвирлана. Ләкин аларда абстракциягә корылган коры фәлсәфә түгел, ә яшәешнең матурлыгы, гомернең кадерле булуы һәм шәхеснең табигать алдында җаваплылыгы, нинди генә шартларда да табигать-анадан аерылгысыз икәнлеге чагыла.

Кешенең рухи халәте шулай корылган: барыбыз да шул балачакны, «караңгы авыл»ны сагынабыз, күңел белән шунда омтылабыз.

*...Җуя барган иң самими хисләр*
*Бу тугайда әле исәннәр.*
*Мине танып, шул ук шаян җилләр*
*Тансык кына сыйпап исәләр.*
*Рәхәтләнеп чалкан ята күңел,*
*Мәтрүшкәләр кочып үбәләр.*
*Күкләр белән бергә таллар, болын*
*Бала чакка агып китәләр...*

«Яшьлегем тугае»

Шагыйрь буларак, Рәкитне, әлбәттә, мәхәббәт җырчысы дип әйтергә мөмкин. «Аллабирде» (1996), «Җаным тама» (2016), «Әтәч елы» (2017) китапларында да бу темага багышланган шигъри әсәрләр шактый. Табигый ки, шигърияттә азмы-күпме каләм тибрәткән бер генә кеше дә сөю хисе турында язмый кала алмый. Бер караганда бик җиңел кебек бу тема, әмма шул ук вакытта иң авыры, иң кыены да.

*...Дулкын-дулкын чәчле кунак кызы*
*Җырлап үтә чишмә түренә.*
*Ап-ак күлмәк кигән сылу сыны,*
*Әллә суда гына күренә...*
*Мәхәббәттә туган яшьлек серен*
*Илаһи төн ала куенга.*
*Сөю тулган сихри моңнар гына*
*Өзелеп кала чишмә буенда...*

«Өзелмәс моң»

Сүз дә юк, Рәкитнең мәхәббәт лирикасы да үзенчәлекле. Ул монда да фәлсәфи тирәнлеккә омтыла. Хисләре бай, катлаулы. Тормыштагы кебек үк. Барлык шигырьләрендә дә лирик геройның саф хисләре ышандырырлык итеп сурәтләнә. Ул юлларны укыганда, үзең дә сизмәстән, шагыйрьнең сердәшенә әвереләсең.

Башка милләтләр хакында әйтә алмыйм, әмма татар шагыйрьләрен берләштерүче бер хакыйкать бар. Милли тематика. Татар халкының фаҗигале, гыйбрәтле язмышы Рәкитнең шигъриятендә дә саллы гына урын алып тора. Башкача мөмкин дә түгелдер, чөнки кыйблалар югалган, гореф-гадәтләргә төкереп кенә карый башлаган чорга ук килеп кердек; әхлак-вөҗдан дисәң, мыскыллы көлү генә ишетү дәрәҗәсенә барып җиттек. Ничәмә-ничә гасыр буена татарны татар итеп саклап килгән бу изге төшенчәләр урынында бушлык хасил булды. Билгеле, үзендә милли хис тоючы бер генә шагыйрь дә моңа битараф кала алмый. Рәкит тә үз әсәрләрендә көнкүрешнең бар өлкәләренә тамыр җәеп өлгергән битарафлыкны ярсып утка тота. Ләкин, шул ук вакытта, иҗтимагый тормыш белән якыннан таныш шагыйрь үзалдына сорау да куя:

*Каләм тотсам, халәтемдә сорау –*
*Хыялыймы шагыйрь, күрәзәме?*
*Акка тамган хиснең чынбарлыгы*
*Тик үземә генә сизеләме...*
*Төшемдәме, дөм караңгы төндә –*
*Яктылыклар табып саташуым.*
*Өнемдәге, бу хәерсез көндә –*
*Кешелекне аклап маташуым.*
*Төртеп куя шайтан вәсвәсәсе:*
*– Син язганга дөнья үзгәрәме?*
*Ярсу йөрәк китә! Гәмсез яши...*
*– Әллә язмый гына түзәргәме...*
*Мәңгелеккә ара өзәргәме?!*

«Җавап»

Иҗаты белән якыннан таныш кешеләр Рәкитне «халык шагыйре» дип атый. Рәсми рәвештә андый олуг исеме булмаса да, иҗаты белән таныш һәркем килешер дип уйлыйм: аның шигырьләрендә, чәчмә әсәрләрендә халык язмышы, шатлыгы, борчулары чагыла. Алар барысы да халыкчан, гади тел белән язылган.

Рәкитнең алга таба әдәби мохитта тагын да көчлерәк дөрләячәгенә ышанам. Чөнки аның бер карашка гади генә күренгән әсәрләре дә ниндидер яшерен моң, ачынулы сагыш белән сугарылган. Аның иҗат киләчәге өметле. Эзләнгән, газаплы ачыргалану белән, үҗәтләнә-үҗәтләнә үз кыйбласын табарга тырышкан шагыйрьдән күпне көтәргә мөмкин. Ул гына да түгел, Рәкитнең бик күп шигырьләренә композиторларыбыз көй язып, алар халкыбызның яраткан җырларына әвереләчәгенә дә шигем юк.

*...Безнең таңнар әле үтмәгән,*
*Яфракларда чыклар кипмәгән.*
*Язларымның тәүге чәчкәләрен*
*Җыеп кочагыңа илтмәгән...*

«Минем таңнар».



***Рәкит Аллабирде Амур Фәләх белән***
***«Әдәби ишегалды» чарасында***

Равиль АХМЕТЗЯНОВ,
*поэт,*
*руководитель литературного объединения*
*«Золотые россыпи»*

Знаю я давно Ракита:
У негол большое сердце.
Дверь всегда к нему открыта -
Заходи к нему погреться!
Напоит тебя он чаем
И подскажет что советом,
Свет добра он излучает,
Что так важно для поэта.

**РАКИТУ АБДУЛЬМАНОВУ,**
**ПОЭТУ, ПРЕДПРИНИМАТЕЛЮ**
**И ОБЩЕСТВЕННОМУ ДЕЯТЕЛЮ,**
**К 55-му ЮБИЛЕЮ**

Знакомы мы с тобой немало лет.
Нет, не друзья, не земляки и всё же,
Близки во многом: ты поэт,
Игры любитель шашечной; быть может

Ещё какие-то в нас сходства есть.
Конечно же, при этом есть различия,
Но мне приятно, что в тебе есть честь
И простота без всякого величия.

Что ты всегда в своём общении прост
И сердцем щедр, духом не калека,
Я поднимаю за тебя свой тост -
Всегда чтоб оставался человеком!

*2015 год.*

Дени АБРАМАШВИЛИ,
*руководитель ансамбля «Кавказ-Чаллы»*

## МОЕМУ ДРУГУ РАКИТУ

И вот проходят годы,
Как познакомились мы.
На веки дружить народам,
Сыновьям татар и грузин.

Ракит стал близким другом мне
Нас испытало время.
Дружба исчезнет тогда лишь,
Когда не будет меня.

Именно сегодня я сказал,
Когда есть повод.
День рожденья празднуешь,
Хотя еще ты молод.

Желаю долгой молодости
Счастья и здоровья!
Успехов в семье, радости
Тост поднимаю за тебя.

“Да пусть сверкает вам звезда,
Звезда мечты и надежд,
Да пусть поможет Вам Аллах
И оградит вас от всех бед!

*24.03.2001 г.*

Айрат ШӘЙХЕТДИН,
*шагыйрь,«Ләйсән» әдәби берләшмәсе әгъзасы*

## «ИДЕЛ-УРАЛ» ҖӘМГЫЯТЕ ҖИТӘКЧЕСЕ РӘКИТ ӘБДЕЛМАНОВКА

Туган көннәр бик тиз килә-китә,
Өстәп еллар үткән гомергә.
Яшәвеңнең биргән җимешләре
Артка карагачтын күренә.

Нык күперләр салдың упкыннарга,
Тоташтырып биек ярларын.
Җәмгыятьтә кылган эшең аша
Ихтирамны безнең яуладың.

Күпне күрдең, авырлыклар кичтең,
Тормыш белән күптән чыныккан.
Борылмадың барган юлларыңнан,
Ихтыярың булды корычтан.

Тормыш юлы биек текә таудай,
Без мәңгегә шул тау тоткыны.
Яныбызга синдәй кеше кирәк
Күперләргә тирән упкынны.

*2015 ел.*



***Рәкит Аллабирде иҗатташ дусты Айрат Шәйхетдин белән***

# ТӘБРИКНАМӘ

## Рәкыйт дус!

**Сине 50 яшьлек юбилеең уңаеннан ихлас күңелдән тәбрик итәбез! Сиңа һәм якыннарыңа күңел тынычлыгы, җан һәм тән сәламәтлеге, тормышыңда, катлаулы һәм җаваплы хезмәтеңдә зур иҗади уңышлар телибез.**




Рәкыйт дускай! Безнең горурлык син.
Дуслыкка син бер дә шик кертмә.
Ныклап таянырлык дуслар барда,
Булмас синең «кошың» читлектә...

Нәгыйм ШӘЙХИ.

Үз милләтең горурлыгы-
Чын татар һәм җанатар.
Синең кебек егетләргә
Диңгез билдән, дала тар.

Халкың күгендә кабынган
Йолдызың якты янсын.
Безгә үрнәк, терәк булып
Йөз яшь яшәргә язсын!

Фаил ИСЛАМ.

Җаваплылыгы чикләнмәгән Дуслар

Галиәхмәт Шаһи - Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь;
Нәгыйм Шәйхи - җырчы-композитор;
Фаил Ислам - рәссам-дизайнер:
Алмаз Ишморатов - Татарстанның атказанган артисты, җырчы;
Амур Фәләх, Россия журналистлар берлеге әгъзасы;
Маузир Гыйниятуллин, «Агыйдел» Татарстан-Башкортстан дуслыгы җәмгыяте рәисе.

Март, 2010 ел.

Равил МОСТАФИН,
*шагыйрь,*
*Шәйхи Маннур исемендәге әдәби бүләк иясе.*

## ШАГЫЙРЬ, ПРОЗАИК

Рәкит Аллабирде турындагы аз, ләкин йөрәк түремнән чыккан бу истәлек-язмамны, аны башкалардан аерып мактыйсы килү максатыннан түгел, аның чын-чынлап кеше шатлыгына шатланып, кеше кайгысына кайгыра белә торган кеше булганы өчен язарга булдым.

Рәкит Яүдәт улы Әбделманов (Рәкит Аллабирде) 1960 елның 22 мартында Башкортостанның Кумертау районы Яңа Аллабирде авылында дөньяга килә. Башлангыч белемне туган авылында ала, Яңа Мораптал урта мәктәбен тәмамлый.

1978-1981 елларда хәрби диңгез флотында хезмәт итә. 1982 елда Татарстанга, Яр Чаллы шәһәренә килә. КамАЗда эшли. 1982 елда фаҗигагә эләгеп, аягын югалта. Тәгәрмәчләр заводында, «Камгэсэнергострой» төзелеш берләшмәсендә эшли, Кама автомеханика техникумының кичке бүлеген тәмамлый.

1988 елдан «Ләйсән» әдәби берләшмәсе әгъзасе, Яр Чаллы язучылар оешмасы белән тыгыз элемтәдәге Рәкитнең шигырь һәм хикәяләре шәһәр, республика матбугатында даими басыла. «Аллабирде» (1996), «Хыял атым» (2011), «Влюбленные души» (2012), «Сулыш» (2015), «Җаным тама» (2016) дип исемләнгән повесть, хикәяләр, шигырьләр җыентыклары авторы.

1997 елдан «Идел-Урал» хәйрия фондын оештыручы һәм җитәкчесе. Физик мөмкинлекләре чикләнгән актив кешеләрне туплаган фонд Рәсәй төбәкләренә һәм БДБ илләренә сәяхәтләр оештыра, спорт, мәдәни, хәйрия чаралары үткәрә. Рәкит Әбделманов 2009 елда «Алтын йөрәкле кеше» һәм «Татарстан Республикасының ел хәйриячесе» исемнәренә лаек була.

Яр Чаллы шәһәрендә яши һәм иҗат итә.

Кайчакта бер төркем шагыйрьләр, язучылар Рәкит янына җыелабыз да үзебезнең язган шигырьләрне, хикәяләрне генә

анализлап калмыйбыз, нинди кешенең, кемнәрнең шәхес дип аталырга тиеш булуы турында да бәхәс куертып алабыз. «Син үзеңне шәхес дип уйлыйсыңмы?» соравын инде менә быел 2016 елның 16нчы апрельдә егерме еллык юбилеен каршылаган Идел-Урал хәйрия фондын җитәкләүче, йөз илледән артык мактау грамоталары-дипломнары, уннан артык орден һәм медальләр иясе, дүрт шигырь һәм бер повесть китабы авторы, ел саен Сабантуйлар, инвалид спортчылар белән төрле ярышлар, пенсионерларга матди ярдәм күрсәтү кебек эшләрне үз өстенә алучы Рәкит Әбделмановның үзенә дә бирәбез.

Инде егерме елдан артык дәрәҗәле эштә эшләсә дә, шәхес, бөек дигән сүзләрне әле дә булса үзенә якын кабул итә белмәүче, инде күптәннән зур шәхесләр рәтендә йөрүче Аллабирде, гади һәм тыйнак итеп: «Мин бернинди дә шәхес түгел!» – дип җавап бирде.

Аның бу сүзенә каршы ни дип әйтеп була? Бары шуны: гади гомере буе гади. Ул үзенең кемнән кем булуын үзе бәлагә тарган көннәрдән бирле раслап килә инде. «Мин» дип яши белмәгән кеше өчен үзен шәхес дип тору да килешми бит әле ул. Рәкит кебек гади кешеләр, үзләре турында затлы сүзләргә игътибар итмичә, эшләренә тугры калып, тыныч кына яши бирәләр.

Шигырь язуга – шигъриятькә килгәндә, аның кебек төптән, тирәннән уй-фикер йөртеп язучылар Татарстанда, гомумән, безнең татарда сирәк дисәм, ялгышмам.

Инде күптәннән бер очрашу вакытында язучы, шагыйрь, тәнкыйтьче Рәшит ага Бәшәр Р.Әбделмановның һәр шигырендә тирән эчтәлек барлыгы, олы язучыларга гына хас осталык белән язуы турында әйткән иде инде. Бу чынлап та шулай. Һәр шигырь сөйгән кеше Аллабирденең шигырь юлларын укуга ук аның чын шагыйрь икәнлегенә төшенер. Менә Туфан ага Мңнуллинга багышланган шигырендәге дүрт кенә юл:

*Ашыкмам тиз генә узарга*
*Җир белән мәңгелек арасын.*
*Эзләрмен җаныма төрергә*
*Кемнеңдер күңеле ярасын.*

Бу юллар Рәкитнең җан сулышын, дөньяда кешеләр өчен, кешеләр бәхете өчен яшәүче кеше икәнлеген ачып бирә.

Һәм Гөлзада Рзаевага багышланган шигырендә, кешеләр бәхете өчен багышлаган гомере белән үз эшенә тугрылыклы ант иткән кебек, бу юлларны да яза:

*Үткәннәрне мәңгелеккә илтеп*
*Кушу юлын эзлим.*
*Адашмыйча барып җитү кирәк:*
*Бәлки, соңгы эз мин.*

Чаллы язучылары арасында туры һәм тугры сөйләмен, ораторлыгын, төпле язуын Кадыйр Сибгатуллин һәм Фаяз Дунайлар белән тиңләрлек шәхес Рәкит Аллабирде дә бар.

Заманында аның иҗатына, Рәшит Бәшәр генә түгел, Туфан Миңнуллин да үзенең затлы бәһасен куйган иде инде. Иҗат эшендә кайбер тыйнаксызлар Туфан кадәр Туфан минем иҗатымны дәрәҗәле бәяләде дип, күкрәк киереп, инде күптән Татарстан язучылар берлегенә алуларын сорап, гариза язган булырлар иде. Юк шул, үзе никадәр туры сүзле булса да, кайчак һәр җөмләсенә басым ясап сөйләшергә яратса да, вакытлар ашыктырып җиңнәреннән тартса да, үзенә бәя биреп, бәһаләргә торган кешеләргә дә артык игътибар итмичә, сабыр гына, тирән-тирән мәгънәле хикәяләрен, шигырьләрен, җырларын иҗат иткән көннәре Рәкитнең.

Шигырьләр, җырлар, хикәяләр генәме соң. Ә узган 2015 елда Яр Чаллы җаваплылыгы чикле «Взаимная помощь» җәмгыятенең социаль типографиясендә ике мең тираж белән басылып чыккан «Сулыш» дигән романтик повестен, кыйссаларын, шигырьләрен, җырларын берләштергән китабы үзе ни тора!

Дөньяда Рәкит кебек инвалид калучы кешеләр күп. Арада бәла-каза шаукымыннан арына алмыйча үз-үзенә кул салучылар да юк түгел. Кайберәүләр эчкечелеккә бирелеп юлдан яза, кешелектән чыга. Ә Рәкит кебек түземлеләр, сабырлар, тырышларны тормыш үзе барлый. Аның кебек Алтын кешеләр белән башкалар кызыксына, алар турында уйлый, кайгырта.

Иң-иң бөек кешеләрнең дә бөеклеге, беренче чиратта, тү-

землектән, тырышлыктан, гадилектән башлана. Нинди дә булса, кемгә дә булса бераз файдалы эш эшләп, «мин» дип күкрәк киереп, борын чөеп йөргән кешеләрнең бөеклеген мин ташка үлчим. Андый «биектәге бөекләр» белән дөнья тулы.

Ә бар бит ул, биектә дә түгел, үзенең гадилеге, гаделлеге белән Бөекләр. Үзен таныту һәм танылуны максат итеп куймыйча, артык кубарланмыйча, саф, изге хезмәтләре белән халкын сөендерүчеләр. Шундый гади дә, галим дә булган кешеләрнең арасында Рәкит тә бар!

Төпле, акыллы берничә китап язган, үзенең нинди биеклектә икәнен яшьтән үк район, республика күләмендә танытырга да өлгергән икән, бу кешеләргә дан, хөрмәт уяна башлый.

Минем уйлавымча, ни өчен аларның урыны да олуг шәхесләр арасында булмаска тиеш?! Һәр кеше дә бит башта тыйнак кына атлап китә. Абына, егыла, торып басып янә ышанычлырак атлый, йөгереп китә. Олуг шәхесләр дә башта - башлап язучы, җырчы, артист, драматург һ.б. Гомумән, иҗат кешеләре үсеш дәвере башында артык биеккә күтәрелеп китә алмыйлар. Хезмәте, иҗаты чарланып, алга таба үсеш чорында өскә, биеккәрәк күтәрелгән саен Кеше, аннары Шәхес һәм Бөек Шәхес дәрәҗәсенә күтәреләләр.

Һәр иҗат эше дә үсеш таләп итә. Кайбер иҗат кешесе үзенә башкалардан өстен бәя биреп, «мин» дип, күкрәк киереп яшәүне кулай күрә. Иҗат кешеләре арасындагы бу буш горурлык, матур-матур чәчәкләр арасыннан үсеп чыккан чүп үләннәре кебек, саф күңел түрләрендә бетмәс тап тудыралар.

Ләкин, ни өчен мондый күкрәк киерүләр гадилеге, галилеге белән олуг зат булган Рәкиттә юк икән ул. Әллә кечкенәдән тормышның асыл мәгънәсенә төшенеп яшәүдәнме? Әллә язмыш аны, иң ачы сынавын биреп, аяксыз калдырып, яктылыгы сүрелеп бара торган дөньяга үзе яктылык өләшергә тиешле Кеше итеп тәрбияләгәнме?.. Зарлы да, яхшы да булган тормышта, иҗат кешеләренең кайбер борынлыларына Алла биргән Рәкит Аллабирдедән үрнәк алып яшисе иде. Гадилекнең, гаделлекнең ни икәненә, ни өчен кирәклегенә дә төшенерләр иде...

Айрат СУФИЯНОВ,
*шагыйрь, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.*

## ТӘКЪДИМНАМӘ

Урал тавының башлангычында туган, авырлыктан сынмаган замандашым Рәкит Җәүдәт улы Әбделманов кылган изге гамәлләре, иҗаты белән дә соклануга лаек Шәхес.

Рәкит Әбделманов – шагыйрь. Әйтергә кирәк, гаҗәеп үзенчәлекле, эзләнүчән, халкыбызның кыйбласына уйларын да, хисләрен дә, язмышын да юнәлдергән, тумыштан тирән тоемлау тылсымына ия булган, нарасыйларча беркатлылык белән дөньяны әйләндергән чыгыр, шигырь дип инанган шаһ ир. Сыкрап, әрнеп каккан йөрәгеннән ургылган, эчкерсез самими, милли моң илә сугарылган, күпсыйдырышлы чын тормышны гәүдәләндерергә омтылган шигырьләре моның бәхәссез дәлиле булып тора. Аның шигырьләрендә өммәтебезнең данлы үткәне белән горурлану да, кояшлы киләчәгенә өмет тә, туган ягына, кешеләргә мәхәббәт тә исән. Рәкит Әбделмановның 1996 елда иҗат ителгән, «Чиркәү нигезенә куелган кабер ташы авазы» дип аталган шигыре, озак еллар үтсә дә, кыйммәтен югалтмаган, халкыбызның бәгырь кылларын тетрәндерерлек көчле әсәр.

Үсешнең дә, камиллекнең дә чиге юк икәнен аңлап, ул эчке дөньясын тагын да киңәйтергә, тирәнәйтергә, баетырга, хикмәтле Сүз әйтергә талпына. Чөнки, шигъриятнең кан әйләнешен, җанның иң югары очышын тасвирлаучы кодрәт, хакыйкать, изге ниятле дога – Сүз иң әүвәле туганын Рәкит тирән төшенергә тырышкан тынгысыз зат.

Рәкит Җәүдәт улының иҗат чишмәсе саекмас, ул татар дөньясына кабатланмас әсәрләр бирер, күңелләрне яулап алыр. Аңа олы ышаныч белдереп, Татарстан язучылар берлеге әгъзасы булырга лаек дип исәплим.

*12 июль 2016 ел.*

## ҖАНЫМ ТАМА…

Татарстан җөмһүриятендә генә түгел, Рәсәй күләмендә, Кавказ таула¬рында, Азия киңлекләрендә билгеле шәхес. «Алтын йөрәкле кеше»(2009), «Зур йөрәкле кеше» бәйгесендә җиңүче(2013), 1996 елда инвалид-спортсменнар өчен үзе оештырган «Идел-Урал» хәйрия фондының алыштыргысыз җитәкчесе, гомеренең һәр сулышын ярдәмгә мохтаҗларның рухын саклауга, күтәрүгә багышлаган, һәркайсына ихлас, риясыз теләктәшлек, шәфкать, шәфәгать яудырган, алар ихтыяҗын кайгыртып янган, алар өчен борчылып җаны тамган, чын мәгънәсендә көчле, горур Кеше исеменә тугры калган, күпкырлы талант иясе, сокланырлык, вакыт багында кадерләп сакланырлык, үрнәк алырлык, олы, катлаулы, фаҗигале тормыш юлы узган, Урал тавының башлангычында туган, авырлыктан сынмаган, сыгылмаган якташым, замандашым Рәкит Әбделманов кылган изге гамәлләре белән дә, иҗаты белән дә татар дөньясына бәяләп бетергесез уңай йогынты ясый дисәм, дөреслеккә аз гына да хилаф итмәмдер…

Рәкит Әбделманов – Шагыйрь. Әйтергә кирәк, гаҗәеп үзенчәлекле, хаклык кыйбласына уйларын да, хисләрен дә, язмышын да фидаиләрчә юнәлдергән, тумыштан нечкә тоемлау тылсымына ия булган, нарасыйларча беркатлылык белән дөньяны әйләндергән чыгыр, шигырь дип инанган шаһ ир. Сыкрап, әрнеп каккан йөрәгеннән ургылган, эчкерсез, самими моң илә сугарылган, күпсыйдырышлы чын тормышны, заманны, кешеләрне бар каршылыгы белән чагылдырырга омтылган шигырьләре моның бәхәссез дәлиле булып гәүдәләнә.

*Белсәм дә мин баш имәгән – киселгәнне,*
*Гел сыгылып, билем бөгеп торалмадым.*
*Җилләр исеп куйган саен, яраклашып,*
*Җайлы гына тыныч тормыш коралмадым.*

Мондый юлларны бары үз-үзенә, инсан җанының илаһи бәйсезлегенә ышанган, Аллаһка, иманга таянган, корыч ихты-

ярлы, кешелеккә, халкына хезмәт итәргә алынган каләм әһеле генә тудыра алуы шикләнүсез...

Гомер буе балалар укыткан, сабыйлар арасында кайнаган, аларны тормышка, киләчәккә армый-талмый әзерләгән газиз әнисе Гәйшә дә, таңны кичкә, кичне таңга ялгап тир түккән, иген иккән, туган туфрагына мәхәббәт, бәрәкәт кояшының нурларын сеңдергән, хезмәткә хөрмәт уяткан әтисе Җәүдәт ага да, гомер буе Рәкиткә таяныч та, юатучы да булган, сөекле тормыш иптәше, чәчәкләр арасында үзе дә язгы чәчәккә охшап елмайган, рухи батырлыкка ия Гөлчирә дә, бердәнбер улы Артур, оныгы Әнсар да, Рәкитнең иҗатында лаеклы, җылы урын алып, искиткеч дәрәҗәдә чиксез ярату белән тасвирланган, җан өртелгән садә образлар. Димәк, Рәкитнең калебе туфрагына туган нигезендә алтын орлык салынган һәм шытып чыккан дияргә, миндә тулы мөмкинлек капусы ачыла.

«Оясында ни күрсә, очканында шул булыр», дип халык тикмәгә әйтмәгәндер.

*Ишетәм мин аваз: «Кавемем*
*Үз эзен сакласа һавада,*
*Җанымны һәркемгә бүлгәләп*
*Яшәрмен гел сезнең арада».*

Чынлап та шулай бит…Өммәтебез, динебез, телебез, гореф-гадәтләребез киләчәккә өметебез яшәгәндә, яшьнәгәндә, милли тамырлар яшәргәндә генә, очар канатларыбыз исән-сау сакланган очракта гына, бердәмлек байрагы астында без бер-беребезгә кирәклегебезне аңлап тупланырбыз, инде йокламаска уянып, куанырбыз, җиңелмәбез, эзсез гүргә иңмәбез кебек…

Рәкит белән күптән аралашып яшәгәнгә, мин аны кешелекле, кечелекле дә, ышанычлы дус миһербанлы, әмма үзен аямаган фидакяр дип уйлыйм... Аның язмышы, мохтаҗларга ярдәм кулы сузуга буйсындырылган. Рәкит ни хакында гына язса да, үз-үзенә таләпчәнлек кызуын сүрелдерми, киресенчә, ши-

гырьдән шигырьгә үсештә.

Үсешнең дә, камиллекнең дә чиге юк икәнен аңлап, ул эчке дөньясын тагын да киңәйтергә, баетырга, хикмәтле Сүзен әйтергә талпына, халкына. Чөнки, шигъриятнең кан әйләнеше – Сүз иң әүвәле булган... Фанилыкка сынау өчен озатылган, җанның иң-иң югары очыш-ачышы – Шигърият! Шигърият – изге ният. Ул шагыйрьне Аллаһка, Коръәнгә яктылыкка, яхшылыкка якынайткан, туфан баскан көндә, Нух көймәсе.

«Җәннәт әнкәйләрнең аяк астында» – дигән Пәйгамбәребез Мөхәммәт (с.г.в.с.).

*Уйларымны җырга салам, әнкәй*
*Сагыш барлый туган нигезне.*
*Йөз нурыңны сибеп авыр юлга*
*Үргә әйдәп яндың син безне.*

Син мине дип язмый шагыйрь, күплек санда гомум кешелек дөньясының аналарын күздә тотып безне ди... Билгеле, һәркемнең дә анасы үз баласының үрләр яулавын тели. Ата-анасының хәер-фатихасын алып, Рәкит миһербанлы-игелекле биеклеккә, бөеклеккә, Хәйрия сәфәренә чыккан зат. Шул сукмакта ул бәхетле.

*Гомер буе яктылыкка юллар салдым,*
*Тәкъдиремне җиңә-җиңә тау-таш ярдым.*
*Караңгыда нурлар күргәч, хәйран калып,*
*Бәхетемә дигән юлны таба алдым.*

Матдилекне алга куйган, асыл кыйммәтләрне читкә куган бүгенге заманда кешеләр мәнфәгатен санлау, аларның сөенечле күзләре көзгесендә үзе дә чагылганын күрү, Рәкит өчен бәхет-сәгадәт!

Сукырларга – күз, аяксызларга – аяк, кулсызларга – кул, маяксызларга – маяк булып яшәү сайланганнар гына күтәрерлек, саваплы җаваплылык.

*Бергә-бергә күтәреләм, таянышып.*
*Кирәк түгел дан һәм шөһрәт, мактау-рәхмәт.*
*Сукыр дусның иңнәрендә – җан җылысы,*
*Күңелемә үтеп керә. Тыныч, рәхәт...*

Ошбу юлларда бергәлек, бердәмлек, теләктәшлек-туганлык авазы да яңгрый. Шагыйрьнең әрнүле, бер-беребезне сакларга, якларга өндәгән кисәтүле йөрәк тибешен ишетеп, «Рәхмәт сиңа чордаш! – диясе, инде чал төшкән башны иясе килә...

Мактау-рәхмәт, дан һәм шөһрәт даулаганнар, теләнгәннәр арткан бу тимер гасырда, Рәкит кебек мөләем дә, сабыр да, түземле дә, үз сүзен ачы хакыйкатьнең күз яшенә, канына манып, куркудан арынып, гавамга юлларга теләүчеләр ничәү икән? Иншалла! Ишле булсын...

*Нур-очкыннан туган карашың*
*Сискәндерде йөрәк парәсен.*
*Шул мизгелдә, очу бәхет булып*
*Күңелемә иңгән, күрәсең...*

*Ямьле язны нәкъ уртага ярып,*
*Тәүге аваз килгән галәмдә:*
*«Гөлчирә» ул – чәчкә матурлыгы,*
*Аңлатмаслык шигъри каләм дә!*

Бу юллар – чәчкәле шигырь бәйләмнәре – хәләл җефетенә, бердәнбере – Гөлчирәсенә багышланган. Бу юллар күкләргә күтәргән мәхәббәткә илдәш вә аваздаш. Мең-мең рәхмәт якташ...

Рәкит Әбделмановның әле 1996 нчы елны язылган, «Чиркәү нигезенә куелган мәчет ташы авазы» бүген дә камил, бүген дә яңача күкрәп яңгыраган, халкыбызның бәгырь кылларын тетрәндерерлек әсәр…Ул милләтебезнең якты киләчәгенә мөстәкыйльлегенә ышаныч белән ашланган. Вакыт таганы Аллаһ боерса, безне дә өскә күтәрер, «Кәмал килер зәвал артыннан». Бөек Тукаебыз язганча:

*Без сугышта юлбарыстан көчлебез,*
*Без тынычта аттан артык эшлибез.*
*Шул халыкныңмы хокукка хакы юк? –*
*Хаккыбыз уртак ватанда шактый ук.*

Рәкитнең дә, сөекле шагыйребезгә багышлаган «Кушагач» дигән саллы шигыре бар:

*Яңгыр арты... Чистарынган күктә*
*Пар канатта җилә шигъри ат, –*
*Ап-ак булып кешелеккә иңә*
*«Тукай» – дигән гаҗәп шигърият!*

Шагыйрь – кайнап торган океан.

Шагыйрьне ачарга, күңел төпкеленә төшеп җитәргә теләсәң, мөгаен, Белинский кебек бөек тәнкыйтьче дә, тел галиме булу да, аздыр. Шагыйрьнең үзәгенә узып, аныңча фикерләп, аның үлчәнешендә газап тату фарыз, хәләл гамәлдер... Рәкит Аллабирде, тирес белән җимләнгән туфрак астыннан зурлык чәчеп, күпләребез кебек ялантәпи казлар саклап, печән җыеп, кырларда эшләп, кояшта каралып, киңлекләргә таралып күтәрелгән гади авыл баласы. Гадилек артына галилек тә яшеренүе ихтимал...Чөнки, ачынулы табышлар, юксынулы сагышлар иясе хәятның, тереклекнең үзе шикелле үк катлаулы булу мөмкинлеге дә бар.

*Этләр өргән җирдә күкрәп яшәү*
*Язмышларда, бәлки, сирәктер дә...*
*Караңгыга дагаларны бәреп,*
*Очкын чәчеп үтү кирәктер дә!*

Рәкитнең туган ягына арнаган иҗаты аерым игътибарга, аерым өйрәнүгә лаек.

*Ярсып чабам балачакка, туган якка –*
*Хыялларда, ак канатлы тулпар атта.*
*Җилеп узган, зил-зиләләр купкан якта*
*Мәшәкатьләр өерелеп кала артта.*

Кайсыбызның туган якка кайту кичерешеннән арынганы, кендек каны тамган туган ягын сагынмый, бишек моңына истәлекләрендә кагылмый, әнисененең күкрәгенә сарылмый яшәгәне бар?! Шагыйрьне дә, һәрбер аерым кешене дә гомер буена, гомер чишмәсенең башы – туган ягы тартып тора, туган ягы рухландыра, канатландыра.

Яшәеш дәвамы дип аталган шигырендә, Рәкит илһамланып, сөенеп оныгы Әнсар турында яза.

*Онык ул – тормышта*
*Үзе бер матур көй.*
*Шатланып көлгәндә,*
*Нурланып китә өй.*

Әмма, якыннарыңның түрләренә нурлар тулсын, иман тулсын өчен изге, тәкъва булып яшәү ләзем. Рәкит фанилыкны да, ахирәтне дә колачларга омтылган шәхес.

Гаять тә тәэсирле, китапның исемен билгеләгән, исеме җисеменә туры килгән «Җаным тама» шигыре таш бәгырьләрне дә эретерлек, ялкын сулап тудырылган. «Җаным тама» ди шагыйрь…Сүзнең кодрәте – үлемсез. Шушы ике сүзгә Рәкитнең кешеләрне якын иткән, хаклык көткән, бөтен гомере сыеп беткән… «Җаным тама» ди Шагыйрь, аңа ышанасың... Дымга зарыккан игеннәргә яңгыр булып тамамы җаны? Рәнҗетелеп киткәннәрнең күз яше булыпмы? Кешелек дөньясына, газиз кавеменә, туган бишегенә рәхмәт догасы булып тамамы? Туган җирен, әтисен, әнисен, таянычы, һәр сулышын сагалап, аяп торган Гөлчирәсе, улы Артур, оныгы Әнсарны ярату булып тамамы? «Җаным тама» ди, Шагыйрь…Күзләремдәге яшьне сөртеп, сихерләнгән кебек, кабатлыйм: «Җаным тама…»

*2 май 2016 ел.*

## СҮЗНЕҢ КОДРӘТЕ – ҮЛЕМСЕЗ!

Рәкит Әбделманов – Шагыйрь. Әйтергә кирәк, гаҗәеп үзенчәлекле, хаклык кыйбласына уйларын да, хисләрен дә, язмышын да фидаиләрчә юнәлдергән, тумыштан нечкә тоемлау тылсымына ия булган, нарасыйларча беркатлылык белән дөньяны әйләндергән чыгыр, шигырь дип инанган шаһир. Сыкрап, әрнеп каккан йөрәгеннән ургылган, эчкерсез, самими моң илә сугарылган, күпсыйдырышлы чын тормышны, заманны, кешеләрне бар каршылыгы белән чагылдырырга омтылган шигырьләре моның бәхәссез дәлиле булып гәүдәләнә.

*Белсәм дә мин баш имәгән – киселгәнне,*
*Гел сыгылып, билем бөгеп торалмадым.*
*Җилләр исеп куйган саен, яраклашып,*
*Җайлы гына тыныч тормыш коралмадым*.

Мондый юлларны бары үз-үзенә, инсан җанының илаһи бәйсезлегенә ышанган, Аллаһка, иманга таянган, корыч ихтыярлы, кешелеккә, халкына хезмәт итәргә алынган каләм әһеле генә тудыра алуы шикләнүсез...

Гомер буе балалар укыткан, сабыйлар арасында кайнаган, аларны тормышка, киләчәккә армый-талмый әзерләгән газиз әнисе Гәйшә дә, таңны кичкә, кичне таңга ялгап тир түккән, иген иккән, туган туфрагына мәхәббәт, бәрәкәт кояшының нурларын сеңдергән, хезмәткә хөрмәт уяткан әтисе Җәүдәт ага да, гомер буе Рәкиткә таяныч та, юатучы да булган, сөекле тормыш иптәше, чәчәкләр арасында үзе дә язгы чәчәккә охшап елмайган, рухи батырлыкка ия Гөлчирә дә, бердәнбер улы Артур, оныгы Әнсар да, Рәкитнең иҗатында лаеклы, җылы урын алып, искиткеч дәрәҗәдә чиксез ярату белән тасвирланган, җан өртелгән садә образлар. Димәк, Рәкитнең калебе туфрагына туган нигезендә алтын орлык салынган һәм шытып чыккан диярга, миндә тулы мөмкинлек капусы ачыла.

Гаять тә тәэсирле, китапның исемен билгеләгән исеме җисеменә туры килгән “Җаным тама” шигыре таш бәгырьләрне дә эретерлек, ялкын сулап тудырылган. “Җаным тама” ди Шагыйрь... Сүзнең кодрәте – үлемсез. Шушы ике сүзгә Рәкитнең кешеләрне якын иткән, хаклык көткән, бөтен гомере сыеп беткән...

“Җаным тама” ди Шагыйрь, аңа ышанасың... Дымга зарыккан игеннәргә яңгыр булып тамамы җаны? Рәнҗетелеп киткәннәрнең күз яше булыпмы? Кешелек дөньясына, газиз кавеменә, туган бишегенә рәхмәт догасы булып тамамы? Туган җирен, әтисен, әнисен, таянычы, һәр сулышын сагалап, аяп торган Гөлчирәсе, улы Артур, оныгы Әнсарны ярату булып тамамы? “Җаным тама” ди Шагыйрь... Күзләремдәге яшьне сөртеп сихерләнгән кебек, кабатлыйм: “Җаным тама...”.

*20 февраль 2017 ел.*



***Якташ шагыйрьләр Айрат Суфиянов белән Рәкит Аллабирде***

Зилә МӨБӘРӘКШИНА,
*журналист.*

## “ӘСӘРЛӘРЕМДӘ ТАТАРЛАРНЫҢ БАШКОРТЛАР БЕЛӘН ДУС ЯШӘГӘННӘРЕН ЧАГЫЛДЫРАМ”

*Татарстан китап нәшриятында язучы, шагыйрь Рәкит Аллабирденең (Әбделманов) “Сулыш” дип исемләнгән китабы басылып чыкты. Автор язучылык сәләте кайчан килгәнен, халыкның дүрт сәгать буенча алкышлап, күп итеп хатлар яудырганы турында сөйләп үтте.*

*Китапның тиражы – 2000 данә, ул киң катлау укучыларга тәкъдим ителә. “Сулыш” китабы авторның туган ягына, газиз халкына булган мәхәббәте, тугрылык, дуслык, сөю хисләре белән сугарылган.*

– Мин мәктәптә укыган вакытларда ук шигырьләр яза идем. Сыйныфташлар белән язган тексларны сәхнәләштергәнем хәтердә. Армиядән соң Яр Чаллы шәһәрендә эшкә урнаштым, һәлакәткә юлыктым, бер аягымны югалттым. Чын-чынлап иҗат итү әнә шул вакыйгадан соң башланды. Бу егерменче йөзнең туксанынчы еллар башы иде. Тора-бара Чаллы Язучылары белән аралаша башладым, шулар арасыннан Хәниф Хөснуллин, Кадыйр Сибгатуллин, Фаяз Дунайны атап үтәр идем. Беренче китабым 1996 елда чыкты. “Аллабирде” дип аталган ул җыентыкта туган авылыма багышланган хикәяләр һәм поэмалар урын алды. Аннан соң, “Ләйсән” әдәби иҗат берләшмәсе белән тыгыз элемтәдә тордым. Язучылар берлегенә керергә дип миңа шул вакытта ук тәкъдим иткәннәр иде, әмма вакытым булмады. Чөнки “Идер-Урал” хәйрия фондын оештырып җибәрдем. Хәзерге көндә дә әлеге фонд белән чит илләргә, республика буенча һәм чит районнарга дуслык сәяхәтләре оештырам. Соңгы җиде елда “Яңарыш” фонды белән дустанә мөнәсәбәттә торабыз. Әйтик, 45 районда булырга туры килде. Авыл халкы белән аралашып, концертлар куеп йөрдек, иҗтимагый һәм хәйрия оешмалары белән бергәләшеп ярышлар үткәрдек. Язуга килгәндә, бүгенгә минем җиде китабым

бар. Икенче һәм өченче китапларым шигъри форматта булды; “Влюбленные души”, “Хыял атым” дип атала. “Җаным тама” исемле китабым күбрәк хәйрия эшләренә багышланды. Әтәч елы темасына караган, “Әтәч елы” дигән шигырьләр, җырлар җыентыгы дөнья күрде.

“Сулыш” китабыма килгәндә, монда туган як, авыл табигате, авыл кешеләре, мәктәп, балачак сурәтләнгән. Бигрәк тә туган ягым – Башкортостан халкы бик хуплап каршы алды. Укытучы апалар елап та алдылар, чөнки мәктәп хәзер инде юк. “Китабыңны укып чыккач, тагын бер кат мәктәпне искә төшердек”, – диделәр.

Җәй көне Башкортостан якларына, авылыма Сабан туена кайтып килдем, шул вакыйгадан соң, хисләнеп, 150 куплетлы шигырь яздым! Шул кадәр тәэсирләндем ки, 150 дән дә артып китә иде, “бу юлга җитәр, озынга китәр, куеп торам каләмемне”, – дидем. “Яшьлегем тугае” дигән исем белән чыгардым.

Туган авылымда иҗади кичә дә булып узды. Анда минем шигырьләремне сөйләделәр, җырларым да яңгырады. Бөтен район халкы минем иҗатымны югары дәрәҗәдә зурлап, таралмыйча, дүрт сәгать буе алкышлады! Башкортостанның район газетасы аптырап язып чыкты инде моның турында. Үзебезнең авылда балаларның шигърият китабын чыгардым. 15ләп бала, татары да, башкорты да, шигырьләр язган. Татарныкын татар телендә, ә башкортларның башкорт телендә булды. Һәрбер шигырь язган балага сәхнәдә китапларны тапшырдым, үзләренең әсәрләрен җыентыкта күреп шатланганнарын күрсәгез!

Кайбер шагыйрьләр әйтәләр бит: “Минем шигырьләрем татар-башкорт халыклары дуслыгына багышланган”, – дип. Татар-башкорт дуслыгы... Моны бөтенесе күреп тора, шулай булгач, хакимиятнең дә мөнәсәбәте уңай иде, башкортлар да, татарлар да зур итеп каршы алды.

Мин татар-башкортны бергә куштым, аларны дуслаштырдым, шуның өчен бу хупланды да. Шуңа күрә мин әсәрләремдә күбрәк татар авыллары башкорт авыллары белән бергәләшеп дус-тату булып яшәгәннәрен чагылдырам. Алар яшиләр һәм

яшәячәкләр дә! Хәзерге көндә тел турында нәрсәләр барганын белеп торасыз.

Дәреслекләрне нинди телдә язарга баш ваталар. Миңа калса, татарлар татар телендә, ә башкортлар башкорт телендә язсын. Һәркем үзе өчен матур гына эшләп барырга тиеш. Шулай булса, безнең телебез бервакытта да югалмас.

Сүз уңаеннан, мине Язучылар берлегенә тәкъдим иттеләр.

*– Сезнең китапларны укып чыккан кешеләрнең Сезгә хатлар язганы бармы?*

– Хатлар язу гынамы соң! Китапларны халык бик сорый, бөтен авыл, район кешеләре, зур галимнәр, язучылар шалтырата. Бер мөхтәрәм укытучым: “Мондый зур үрләргә менгәнең өчен без шундый горурланабыз!”, – диде. Мин: “Апа, укучы бервакытта да укытучыдан югары менә алмый, чөнки укучының дәрәҗәсе үскән саен, мөгаллимнең дәрәҗәсе тагын да үсә бара”, – дидем. Абый-апалар шалтыратып, булган хәл-вакыйгаларны сөйләп бирәләр. Хәзер күбесенчә “зур кешеләр”не мактап яза башладылар бит, ә мин киресенчә, гади авыл тормышы турында бәян итәм. Шуның өчен дә, бәлки, халык мине аңлыйдыр. Мамадыш язучысы – Рафаил Газизов шалтыратты, әле беркөнне Клара апа Булатова шалтыраты, ул да китабымны тулысынча укып чыккан. Чаллының мөхтәрәм язучылары берәм-берәм күтәрелеп, минем шигърият, проза турында бик матур фикерләр әйтте.

*– Әсәрләр, гадәттә, ниндидер бер вакыйгадан соң языла. Кешеләр хикәядәге геройларга охшаш булуы турында әйткәне булдымы?*

– Әлбәттә! “Каян беләсең син аны?” – диләр алар. Шуны әйтәсем килә: Язучылар берлегендә 400ләп язучы бар. Шул 400 язучы төбәге турында язып, туган ягына кайтып, очрашулар үткәрсә һәм газета-журналларга яздырса, тагын әллә нинди зур эшләр башкарырга була!

*– Сезгә заказ буенча шигырь язарга кушканнары бармы?*

– Заказ буенча шигырь язмыйм. Әгәр дә мин үзем теләп берәр кешегә багышлап шигырь язам икән, бу минем генә теләк. Дүрт-биш кешегә шигырь язганым булгандыр. Кеше ку-

лына каләм алса, Габдулла Тукай турында яза башлый бит, ә мин дөнья, кеше турында язарга омтылдым. Мин узган елны беренче тапкыр Кырлайда булып кайттым, шуннан соң гына “Кушагач” дигән шигырь туды. Кырлайда, Тукай торган йорт артында кушагач үсеп утыра, аны Тукай яшәгән чорда утыртканнар дигән гыйбарә дә бар. Г. Тукай яшәгән җирләрне күрдем, шул мохиттә булдым. Шуның өчен дә тәгаен бу урыннарны белмичә торып, шигырь яза алмадым. Үзең тоеп караганда гына шигырь матур килеп чыга.

*– Сезнең әле бихисап шигырьләрегезгә көйләр дә язылган икән. Нинди композиторлар белән эшлисез? Шигырь кирәк дип мөрәҗәгать итәләрме?*

– Минем күп кенә шигырьләремә танылган композитор Ринат Гобәйдуллин көйләр иҗат итте. Шулай ук, Нәгыйм Шәйхи, Зөлфия Җиһан, оранжировкалар ясау остасы Илдус Низамовны да әйтеп үтәр идем. Равил Галиев һәм башка артистлар минем берничә җырымны башкара. “Менә минем җырларым бар бит әле”, дип үзем җырчыларга барып, ялынып йөргәнем юк.

*– Шигырьләр үзеннән-үзе туамы?*

– Миңа шигырь язарга газиз тормыш иптәшем – Гөлчирә ярдәм итә. Ул әле берничә китабымның мөхәррире дә. Бергә иҗат иткәндә генә шигырь барып чыга, чөнки кешедә бераз ялкаулык та булырга мөмкин. Гөлчирә белән бүгенге көндә дә бергәләп иҗат итүе күңелле дә!

*– Китаплар чыгару зур чыгымнар таләп итә. Бу мәсьәләдә ярдәм итүче бармы?*

– Татарстан Язучылар берлегенә, шәхсән Рәмис Аймәткә рәхмәтемне әйтәсем килә. Алар минем китапны укып, нәшриятка бастырырга тәкъдим иттеләр. Нәшриятның баш мөхәррире Ленар Шәех китабымны укыды. Илсөяр Кадыйрова редакторым булды, алар һәрберсе тырышып эшләделәр, рәхмәт! Беренче китапта вакыйга аяксыз калганым турында тукталып кала, икенче һәм өченче китапларны да чыгарырбыз дип уйлыйм. Аллабирса, вакыйганың дәвамын язып бетерермен! Халык инде бу әсәрнең дәвамы кая дип сорый башлады.

*– Киләчәккә планнарыгыз белән уртаклашсагыз иде.*

– Алла теләсә, "Сулыш" әсәре өстендә эшләячәкмен һәм, әлбәттә, шигърият. Шигърият минем өчен иң тәүге урында тора. Рәшит Бәшәр, Айдар Хәлим кебек язучылар: "Проза шигърият аһәңе белән язылса, чынлап та, ямь өстәлә икән, матур килеп чыккан" – диделәр. Шигърият өстендә эшлисем бар әле, камилләштерергә исәбем бар, чөнки мин шигырьне җиңел яза алмыйм. Кемдер әйтә бит: "Күктән төшә дә, язам да куям", – дип. Минем кабат-кабат утырып эшләгәндә генә шигырь матурая бара. Эшләнеп беткәннән соң гына, мин аны халыкка чыгарам. Кайда гына булсам да, шигырьләремне яттан сөйлим. Хәйрия эшләрен алга таба да алып барырга ниятем бар.

*Рәкит Җәүдәт улы Әбделманов 1960 елның 22 мартында Башкортстан Республикасының Күмертау районы Яңа Аллабирде авылында туган. 1983 елдан бирле Чаллы шәһәрендә яши. 1996 елдан бирле Чаллы Язучылар оешмасы каршында оешкан "Ләйсән" әдәби иҗат берләшмәсенә йөри. Рәкит Җәүдәт улының хикәяләр һәм тарихи эсселәр тупланган "Аллабирде" исеме астында беренче китабы 1996 елда дөнья күрде. «Идел-Урал» хәйрия фонды җитәкчесе. Бүгенге көндә Чаллы шәһәрендә яши.*

*2017 ел.*



***Чаллы шәһәре «Чишмә» халыклар дуслыгы йортында Башкортстанның Кумертау шәһәре мэры Б.Н.Беляев белән очрашу истәлеге. 2018 ел***

Роза ХӘМИДУЛЛИНА,
*Яр Чаллы шәһәренең М.Җәлил исемендәге*
*Үзәк китапханәсенең бүлек мөдире*

## «АК ЮЛЛАР ТЕЛӘП...»

**Рәкит Әбделманов**
**иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә**
*(өлкән сыйныф укучылары өчен)*

Талгын гына көй астында сәхнәгә ике алып баручы чыга.

1 нче алып баручы:
Яшәп булмый никтер салмак кына,
Хыял-атым һаман алдан йөри.
Тукталып бер каранасы итәм –
Язмыш әллә мине алдап йөри...

Каерылып тартам авызлыгын,
Кубарылып чапкан атым тыеп.
Тыпырчына атым, пошкырына –
Хәүф-хәтер янда барын тоеп.

2нче алып баручы:
Аерырга телим кара-акны,
Салкын җилләр гел дә каршы исә.
Караңгылык чорный тирә-якны,
Этләр өрү алда юлны кисә.

Томырыла атым, авызлыгын өзеп,
Мәңгелектән артта калмас кебек.
Суырылып чыгам тоткынлыктан –
Күңелләрем инде талмас кебек.

Этләр өргән җирдә, күкрәп яшәү,
Язмышларда бәлки сирәктер дә.

Караңгыга дагаларны бәреп,
Очкын чәчеп үтү кирәктер дә.

*«Хыял атым»*

2 нче алып баручы: Хәерле кич, исәнмесез! Без бүгенге кичәбезне «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе әгъзасы, Рәкит Җәүдәт улы Әбделманов (Рәкит Атлас, Рәкит Аллабирде) иҗатына багышлыйбыз.

1 нче алып баручы:Рәкит Җәүдәт улы Әбделманов 1960 елның 22 нче мартында Башкортстан Республикасы Күмертау районы Аллабирде авылында туа. Ул Яңа Мораптал урта мәктәбен тәмамлый. Автомеханика техникумында технолог һөнәре белгечлеге ала. Хәрби диңгез флотында хезмәт итә.

2 нче алып баручы: 1983 елдан бирле Чаллы шәһәрендә яши. Балачактан әдәбиятка гашыйк Рәкитнең, чын-чынлап әдәби иҗатка бирелүенең сәбәпчесе – тормыш юлдашы Гөлчирә. 1988 елдан «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенә йөргән Рәкитнең шигырь, хикәяләре республикабызда чыгып килүче вакытлы матбугат битләрендә күренә башлый. 1996 елда туган як хатирәләре, хикәя, шигырьләр тупланган «Аллабирде» дигән тәүге китабы дөнья күрә. Бүгенге көндә ул «Хыял атым» (2014), «Влюбленные души» (2014), «Сулыш» (2015), “Җаным тама” (2016), “Әтәч елы” (2017), “Сулыш” (2017), “Яшьлегем тугае” (2017), “Алиһә” (2018) дип исемләнгән китаплар авторы. Шушы урында Рәкит Әбделмановның шигырьләрен ишеттереп үтәсе килә.

1 нче алып баручы:
Туктагач йөрәгем, һаман да,
Җаннарның гозерен үтәрлек.
Вакыт бир калырга заманда,
Аһ-зарлар йомгагын сүтәрлек.

Ашыкмам тиз генә узарга
Җир белән күкләрнең арасын.

Эзләрмен җаныма урарга
Кемнеңдер күңеле ярасын.

2нче алып баручы:
Киталмый гөнаһлы тилмерсә,
Тагын бер очратып сүгәрмен.
Гәебен үземә күчерсә –
Ашсын ул күкләргә, түзәрмен.

Гаделлек юклыгын аңламый-
Эзләгән үзсүзле баландыр.
Шуңа да, тагын бер тыңламый
Гел җирдә, ахрысы, каламдыр...
*«Фанида»*

1 нче алып баручы: Рәкит Әбделмановның күп кенә шигырьләре композиторларыбыз: Ринат Гобәйдуллин, Зөлфия Җиһан, Рубис Зарипов, Нәгыйм Шәйхиләр тарафыннан көйгә салынган.

Җыр башкарыла.
Җыр:
Яшьлегемнең серен саклый,
Туган авыл кичләре.
Гармун чыңы һаваларда –
Тәүге сөю хисләре...

Кушымта:
Әйдә дуслар, бер әйләник,
Шул чактагы урамны.
Гармун моңы басар бәлки,
Күңелдәге буранны.

Кунак кызы көтә анда,
Көтә серле күзләре...
Төнге бакча буйларында,
Яңгырый сөю сүзләре.

Сагыш дәрте моңга тулып,
Урамнарга түгелә...
Яшьлегенә кайткан авыл,
Мәхәббәткә күмелә!
Кушымта.
«Яшьлек моңы»
*(Рәкит Әбделманов сүз., Рубис Зарипов көе)*

2 нче алып баручы: 1997 елдан Рәкит Әбделманов «Идел-Урал» хәйрия фонды җитәкчесе. 2009 ел нәтиҗәләре буенча, ул «Алтын йөрәкле кеше» һәм «Татарстан Республикасы хәйриячесе» дигән мактаулы исемнәргә лаек була. 2010 елда «Чаллы шәһәре каршындагы казанышлары өчен» медале белән бүләкләнә.

Укучылар чыгышы.

1 нче укучы:
Күз кыскалап җиргә серле генә,
Ай яктырта авыл янында.
Җылы тәэсирләрне тоеп кына
Кузгаламын нигез ягына.

Җанга якын үзең, эх Сазанлым,
Берүзең син нәни бер илкәй.
Киндереңне халкым кием иткән,
Балтырганың булган ипекәй.

2 нче укучы:
Тормыш белә безне –
Син дә танып
Аңлыйсыңдыр юллар иясен.
Мин дәвамлыйм гына түгелме икән
Ата – бабам династиясен?.

Юллар әйдәп,
Кабат ишек ачсам,
Күңелеңдә үпкә тоярсың.

Ә шулай да
Үзең сабыр гына –
«Кайтып йөре, иркәм» – диярсең.
«Хуш, авылым! »

Җыр башкарыла.

Җыр:
Алда Мораптал утлары –
Башкортстан ишеге.
Күңелемнән китә алмый
Туган ягым бишеге.
Кушымта:
Эх, Мораптал, Мораптал,
Кайда таллык, кайда тау!
Эх, Юшатыр сулары
Басармы ярсуларны!

Юлчылар туктап соклана
Сазанлы буйларына.
Кызлар җырлап печән җыя,
Кем икән уйларында?
Кушымта.

Хатирәләр алдан чаба,
Чик түгел еллар аңа.
Яшьлек белән кавыштыра
Тик шушы юллар гына.
Кушымта.
«Эх, Мораптал»
*(Рәкит Аллабирде сүз., Нәгыйм Шәйхи көе)*

1 нче алып баручы: Рәкит Җәүдәт улы хезмәте, башкарган эшләре, кылган гамәлләреннән күренгәнчә үз эшенең остасы. Ул күңеле кушканча яраткан эше белән шөгыльләнә. Кул көрәштерү буенча халыкара, Россия һәм Республика ярыш-

лары призёры. Ат спорты, өстәл теннисы, походлар оештыру аның иң яраткан шөгыльләре рәтендә.

2 нче алып баручы:
Язгы кич. Торналар чылбыры
Талпына шәфәкъкә үрелеп.
Әйтерсең биләүдә һәрбер кош
Тибрәнә бер моңга төренеп.

Бер урын буш калган төркемдә,–
Шуңамы җырлары аяныч?..
Кайдадыр баш салган, гаяр кош,
Табалмый чит җирдә таяныч...

1нче алып баручы:
Күңелем күзендә бу урын
Буш түгел – ап-ак эз күренә.
Нәселнең буынын тотышып
Кош җаны кайтамы иленә?!

Ишетәм мин аваз: «Кәвемем,
Үз эзен сакласа һавада,
Җанымны һәркемгә бүлгәләп
Яшәрмен гел сезнең арада».

*«Гаярьләр»*

2 нче алып баручы: Рәкит Әбделманов үзе турында болайрак сөйләргә ярата:

«...Кулыма каләмне сирәк алам. Шигырьләремне яттан сөйләргә яратам. Шулай миңа күңеллерәк, җайлырак. Каләмдәшләрем: «Ничек инде, барлык язган шигырьләрне истә калдырырга мөмкин түгел бит ул?» – диләр. Ничек истә калмасын ди инде? Күңелемнең иң нечкә зиһен кылларында яралып, җаным-тәнемнең һәр күзәнәгендә тулышып-ташып, шигырь юлларына ургылган хисләрем ич алар.

Кулыма каләм алам. Әмма... кайбер шаян уй-хисләрем,

матбугат кысаларындагы таләп-кагыйдәләргә буйсынырга теләмичә, карыша-киреләнә башлыйлар, аларны бернинди калыпларга да куып кертү мөмкин түгел кебек.

Мин, сөекле бунтарьләремә каршы бара алмыйча, каләмемне ташлыйм! Яңадан үз халәтемә, эчке шигъриятемә, җан кисәкләрем – шигырь юлларыма әйләнеп кайтам.

И-и сөеклеләрем, ак юл сезгә!», – ди.

1 нче алып баручы: Кичәбезне язучы Фаяз Дунай сүзләре белән тәмамлыйсы килә:

2 нче алып баручы: «...Урамда суык, юеш. Карлы-бозлы яңгыр ява...

Ә минем җанымда якты, шатлыклы хис тантана итә! Чөнки чын-чынлап сәнгать әсәрләре булган язмалар укыйм. Чаллы язучыларына күптән таныш булган, һәрдаим аларга булышып торучы миһербанлы ир-егет Рәкитнең әсәрләре алар. Язмаларда реаль тормышның реаль детальләре кычкырып тора, сюжети вакыйгалар тормышчан-табигый, персонажлар – кешелекле, тере, үзенчәлекле, уйчан, хисле, кайгылы-хәсрәтле һәм шатлыклы...

Әдәбиятыбызга яңа талант килә, уйлы-хисле, матур телле яңа әдип килә! Ак юллар телик аңа! Фаяз Дунай».

1 нче алып баручы: Фаяз Дунай юк-бар сөйли торган кеше түгел иде. Мөхтәрәм язучы аның иҗатына сөенә, аңа яңа үрләр тели. Нәкъ Фаяз Дунай әйткән кебек «Ак юллар телик Рәкиткә».

## РӘКИТ АЛЛАБИРДЕНЕҢ ШИГЪРИ БИЗӘКЛӘРЕ

## СТИХОТВОРЕНИЯ РАКИТА АЛЛАБИРДЕ



***...Миңа калса, тәмам иләсләнеп,***
***Айлы кичтә, рәхәт җиләсләнеп,***
***Тәмен тоеп, юри озаклашып,***
***Торам яшьлек белән... кочаклашып!***

**Көнләшү.**

## *Чәчкә*

*“Гөлчирә*” – чәчәк кебек нәфис йөзле*

Гөл-чәчәкләр серле күз атканда,
Күбәләкләр кунып наз ала.
Шатланасың шуңа, кул чәбәкләп,
Әйтерсең лә, һаман кыз-бала.

Карап торам синә, һушым китеп –
Фәрештәме бизи һәр көнем.
Ходай бүләгеме, могҗизамы –
Беренчедәй үтә һәр төнем!

Айный алмам бугай гомерем буе,
Онытсам да шәраб исләрен.
Кичер мине, шашып сөйгән чакта
Ташып китсә әгәр хисләрем.

Ямьле язны нәкъ уртага ярып,
Тәүге аваз килгән галәмдә:
“Гөлчирә” ул – чәчкә матурлыгы,
Аңлатмаслык шигъри каләм дә!

*27.06.2010 ел*



*Фарсычадан тәрҗемә

## *ХӘЗИНӘ*

*(Гөлчирәмә)*

Җәйләр җитсә кайтам авылыма
Яшьлек елларымны сагынып.
Туып үскән өйнең истәлеге –
Нигезенә алам кагылып...

Бакча башындагы көнбагышка
Таянган да кояш, батмаган.
Әткәй күзе кебек көтә-көтә
Авыл юлын нурга каплаган.

Нигез аша атлыйм, ни могҗиза!
Эй тылсымлы туган җир көче –
Күз алдымда кинәт пәйдә була
Бала чагым үткән өй эче...

Мич алдында, әни, хәстәрләнеп
Өеп куйган әнә чыралар.
Иртәгәсен безне уятканда
Пәрәмәчләр пешеп чыгарлар.

Тәмле исләр белән аралашыр
Балаларның чыр-чу килгәне.
Якасына ап-ак челтәр тегеп
Мәктәп киемнәрен кигәнем.

Җиз коршаулы сандык ачык калган.
Таныш миңа үзе, төсе дә.
Иренемә тамган күз яшемнең
Әче кебек тәме, төче дә...

Мин туганда бүрәнәләр ташып
Өй күтәргән тырыш әткәем.
Нарасыен йомычкага күмеп
Эшкә киткән газиз әнкәем.

Җиде бала, берәү кебек үстек.
Тоеп үстек алар җилкәсен.
Курыкмадык, чөнки белә идек –
Авырлыклар безне җиңмәсен.

Сизенгәндер әткәй, кыз баланың,
Очып киткәч ташлап оясын –
Олы юлда юксынулы еллар,
Җил-давыллар аша үтәсен.

Шуңа атның дилбегәсен биреп
Бу чыныксын әле дигәндер.
Нәни кулым аша йөрәгемә
Ышанычлык хисе иңгәндер.

Балачакның барлык хәтирәсе
Күңелемдә иң-иң кадердә.
Бу нигезнең иң зур хәзинәсе –
Игелеге сеңгән бәгырьгә!

***

Әткәй нигез салган яңа өй дә
Бәрәкәтне берүк сакласын.
Ә кызыгыз, сезгә сәләм биреп
Шакый торыр урам капкасын.

## ӘТИ ИҢЕ

*Улым белән оныгыма*

Кошлар оча, елга өстен сыйпап...
Җил шаяра, дулкын белән уйнап.
Әти иңен “иярләгән” бала
Кама буйлап гүя атта чаба!

Яр буенда чыпчык оя кора...
И, шатланып бала карап тора.
Иң зур бәхет бүген аның өчен –
Әтисендә сизә яшәү көчен!

Кош баласы күктә канат каксын...
Газиз бала җирдә юлын тапсын.
Әти иңен тоеп үскән бала
Гомер буе хисле булып калсын!

Вакыт-вакыт сабый булып алсын!



***Рәкит Аллабирденең улы Артур һәм оныгы Әнсәр***

## ***КӨНЛӘШҮ...***

Ишеттереп тибә икән йөрәк
“Син минеке, тик минеке генә!”.
Кочаклашу түгел, сүз башларга
Кыймый тору – егетлегем минә...
Кызык эзләп чыккан төнге җилләр
Кызның чәчен айкап, ачып үтә.
Яңа сауган сөттәй ап-ак муен
Караңгыны ярып, балкып китә.
Җилләр генә дисәм, әнә тагы
Ай күзәтә икән качып кына –
Мут нурларын сузып, үбеп куя
Төн пәрдәсен бераз ачып кына.
...Карасана, еллар үткән саен
Көнләшергә хәттә йөрәк әзер.
Караңгы төн, җилләр һәм тулган ай –
Сугышырга кайттым менә хәзер!
Сезне эзләп чыксам, бакча буе
Үзе килә әнә, түзәлмәгән.
Бөрлегәнгә сарган тәүге хисләр
Тыйнак кына көтә, үзгәрмәгән.
Сугышалмам инде. Мин бит шушы
Куаклардан үсеп чыккан малай.
Айлы төне белән миңа Ходай –
Хыялыйлык бүләк иткән бугай...
Иң-иң газиз тәүге хисләрне дә,
Ала алмам бугай аралап.
Тибрәнсеннәр алар тыныч кына,
Безнең сукмакларны сагалап.
...Миңа калса, тәмам иләсләнеп,
Айлы кичтә, рәхәт җиләсләнеп,
Тәмен тоеп, юри озаклашып,
Торам яшьлек белән... кочаклашып!

*6.02.2016 ел.*

***Менә кайтып башым иям сиңа, аңлап киңәш, кодрәт кирәген.***

***Колач җәеп каршы ала мине - чамадан тыш җылы йөрәгең!***

**«Сазанлым».**



***Рәкит Аллабирденең әтисе Яүдәт абый белән әнисе Гайшә апа***



***5 нче сыйныфта. 1972 ел***




***Рәкит Аллабирде туган авылында әнисе Гайшә апа, апасы Рәүзилә, җизнәсе Әхсән һәм Гөлчирәсе белән***



*Балтыйк диңгезендә хәрби хезмәттә. 1980 ел*



*Яр Чаллы язучылар оешмасында. 1987 ел*



*Яңа Мораптал урта мәктәбенең 1978 ел чыгарылышы. 10 «б» сыйныфы*

## ГАСЫР АША

***(Морапталда беренче мәктәп ачылуга багышлана)***

*Соңыннан бу агач бина безгә -*
*Аллабирде, Калта, Кызыл Маяк*
*авылларыннан җыелган балаларга*
*интернат вазифасын үтәде.*

Инкыйлаблар үткәч,
Яңа дәвер җиткәч,
Бүрәнәдән авыл мәктәп сала.
Искелекне сүтеп,
Иң тәүгеләр булып,
Яңа буын анда сабак ала.

Бусаганы атлап
Керүчегә мәктәп
Гасыр буе биргән күпме кадер!
Игелекләр белән
Биштәрләре тулган –
Олы юлда бара алар хәзер.

Максат куя кеше,
Зурдан булса эше.
Күңел кылы һаман нидер көтә...
Тәнәфесләр шавы,
Кышкы мәктәп тавы
Бала чакка аны алып китә.

Алда эшләр барлап,
Күңел белән парлап,
Тал-атларда чабып сабый үтә.
Шуңа күрә заман
Куып җитми һаман,
Ямен табып кына сабыр итә...

*23.06.2019 ел*

## ҖАНЫМ ТАМА...

Каләм тибрәтергә өйрәнмәдем
Толстойлар, Байрон үрнәгендә.
Мәртәбәле уку йортларының
Колонналы даһи түрләрендә.

Уй-хисләрем тыеп зиһенемдә
Күпме генә йөрәк чыдагандыр...
Сыешалмый җырлар җисемемә –
Сахраларга ташып чыгалардыр.

Тәүге тойгыларны күңел күзе
Яза манып рәшә чыкларына.
Рульгә түгел, әти йөрәгенә
Чат ябышып барган чакларыма.

Шәфәкъ утларына манып яза
Хисләр тама ялан-кырларыма.
Сагыш түккән торна эзе буйлап
Алып киткән яшьлек юлларыма.

Хәтер булып тама, яланаяк
Тилгән куып чабып үткәнемә.
Бакча почмагында кунак кызын
Хыялымда гына үпкәнемә.

Җаным тама үткән елларыма...

*24.03.2016 ел*

## БӘХЕТ

Гомер буе яктылыкка юллар салдым,
Тәкъдиремне җиңә-җиңә тау-таш ярдым.
Караңгыда нурлар күргәч, хәйран калып,
Бәхетемә дигән юлны таба алдым.

Бәхилләнеп бу дөньядан киткән чакта,
Минем эздән хозурланып калсын болын.
Шәригатьләп, матур итеп күмгән чакта,
Тәрбияләп, бер уч җирне салсын улым.

Сөйгән ярым гөл-чәчәкләр утыртканда,
Үз оныгым сулар ташып, сибеп торсын.
Сулкылдаган йөрәгендә бабам каны
Нәсел җебен тоташтырып тибеп торсын.

Кубарылып чыккан чакта минем җаным,
Исән булса сөйгән ярым, онык, балам,
Нурлар тулса түрләренә, тулса иман –
Мин сөенеп мәңгелеккә китә алам.

*6.02.2014 ел*

## ХӘЙРИЯ

Киселсәм дә, туфрагыма берекмичә
Кубарылдым ирешергә морадыма.
Игелеккә кабат сәфәр юллар өчен,
Миһербанлык төяп йөрим корабыма.

Авыр, ләкин изге йөгем аска басса,
Фәрештәләр күтәрешә җилкәмнәрдә.
Дулкын-дулкын каршылыклар ярыр өчен,
Уңай җилләр насыйп иткән җилкәннәргә.

Дөм караңгы язмышларга ак юл ярып,
Кораб килә аһ-зарлыга маяк булып.
Кул сузамын төпкелләргә, үргә әйдәп:
Күзсезгә – күз, аяксызга-аяк булып.

Бергә-бергә күтәреләм, таянышып.
Кирәк түгел дан һәм шөһрәт, мактау-рәхмәт.
Сукыр дусның иңнәрендә – җан җылысы,
Күңелемә үтеп керә. Тыныч, рәхәт...

*4.01.2014 ел*

## ТАШУ ҮТӘ

Су котыра. Дәртле ташу шавы –
Тантанага күмә һаваны.
Язлар белән бергә, шаша-шаша
Кайта җиргә яшәү дәвамы.

Тик кырыйда гына, боз кисәге,
Бик боега кебек нигәдер –
Сарылыплар газиз ярларына
Теләмичә генә чигәдер...

“Уф-уф” – диеп, кинәт су буенда
Иңрәп ала китү сагышы.
Суда туып, ныгып, шунда эрү –
Бозга насыйп тәкъдир агышы.

Ташу үтә. Соңгы бозлар китә.
Кысып куя йөрәк чыдамый.
Аянычым – шушы ташкын кебек,
Ник яшьлектән күңел чыгалмый...

*13.02.2016 ел*

## ГАЯРЬЛӘР

Язгы кич. Торналар чылбыры
Талпына шәфәкъкә үрелеп.
Әйтерсең, биләүдә һәрбер кош
Тибрәнә, бер моңга төренеп.

Бер урын буш калган төркемдә –
Шуңамы җырлары аяныч?..
Кайдадыр баш салган гаярь кош,
Табалмый чит җирдә таяныч...

Күңелем күзендә бу урын
Буш түгел – ап-ак эз күренә.

Нәселнең буынын тотышып,
Кош җаны кайтамы иленә?!

Ишетәм мин аваз: “Кавемем
Үз эзен сакласа һавада,
Җанымны һәркемгә бүлгәләп
Яшәрмен гел сезнең арада”.

*27.01.2011ел*

## ХЫЯЛ АТЫМ

*Этләр өрә, кәрван бара...*
**Әйтем**

Яшәп булмый никтер салмак кына...
Хыял-атым һаман алдан йөри.
Тукталып бер каранмакчы булам –
Язмыш әллә мине алдап йөри...

Каерылып тартам авызлыгын,
Кубарылып чапкан атым тыеп.
Тыпырчына атым, пошкырына –
Хәвеф-хәтәр янда барын тоеп.

Аерырга телим кара-акны,
Салкын җилләр нигә каршы исә?
Караңгылык чорный тирә-якны,
Этләр өрү алда юлны кисә...

...Томырыла атым, авызлыгын өзеп,
Мәңгелектән артта калмас кебек.
Суырылып чыгам тоткынлыктан –
Күңелләрем инде талмас кебек.

Этләр өргән җирдә күкрәп яшәү
Язмышларда, бәлки, сирәктер дә...
Караңгыга дагаларны бәреп,
Очкын чәчеп үтү кирәктер дә!

*13.08.2008 ел*

## КАЙДА ТӨШИМ

Белсәм дә мин, баш имәгән – киселгәнне,
Гел сыгылып, билем бөгеп торалмадым.
Җилләр исеп куйган саен, яраклашып,
Җайлы гына тыныч тормыш коралмадым.

Белсәм дә мин, шуышканнар – егылмасын,
Һава ярып очкан мәлдә төшәлмәдем.
Кемнәрнеңдер күңеленә шифа булып,
Җиргә сеңеп, хәтфә булып түшәлмәдем.

Һәр хужаны яклап-саклап, һау-һау өреп,
Тәлинкәдән арткан сыйны кабалмадым.
Бил бөккәннәр, шуышканнар арасыннан
Максатыма иярченнәр табалмадым.

Таяк сугып, чиләк кагып куган саен,
Мин, өскәрәк күтәрелеп, җиргә багам:
Кайда гына сыеныр соң, әйт син, гавәм,
Хәл җыярга төшсә әгәр җиргә балаң?

*9.01.2014 ел*

## ЛАЧЫН

Күкләрдә мин ачам күземне.
Авыр моң биләгән үземне:
Әйтерсең, бар зарын төянеп
Ияргән кешелек җисеме.
– Я Ходай, бирсәңче түземне...

Үрләргә атылып, бер лачын
Тәкъдирләр очына эз элә.
Тагы да югары, күпердә
Чылбырдай чиратлар тезелә.
– Һәм кинәт бер буын өзелә...

И лачын, бул соңгы канатым,
Үткәндә мәңгелек арасын.
Күңелем, зарыккан җаннарга
Тагын бер бәхилләп карасын.
– Кем белә, кем кая барасын...

Кемнедер гөнаһтан аралап,
Озатып калырга дучар мин.
Һәм шунда, яңа җан каршылап –
Һавада әйләнеп очармын.
– Яратып, Җир шарын кочармын...

*29.03.2015 ел*

## ФАНИДА

Туктагач йөрәгем, һаман да
Җаннарның гозерен үтәрлек,
Вакыт бир калырга заманда,
Аһ-зарлар йомгагын сүтәрлек.

Ашыкмам тиз генә узарга
Җир белән мәңгелек арасын.
Эзләрмен җаныма төрергә
Кемнеңдер күңеле ярасын.

Киталмый гөнаһлы тилмерсә,
Тагын бер очратып сүгәрмен.
Гаебен үземә күчерсә –
Ашсын ул күкләргә... Түзәрмен.

Гаделлек барлыкка инанып
Эзләнгән үзсүзле баландыр.
Шуңа да, тагын бер тыңламый,
Гел җирдә, ахрысы, каламдыр.

*15.10.2008 ел*

## ӘНКӘЙ

Уйларымны җырга салам, әнкәй,
Сагыш барлый туган нигезне.
Йөз нурыңны сибеп авыр юлга –
Үргә әйдәп яндың син безне.

...Күңел саклый, саклый карашыңда
Сөю тулган назлы моңнарың.
Тузган чәчем һаман сыйпый кебек
Җыерчыклы йомшак кулларың.

Карап үтәм синең мәктәбеңә,
Башлангыч дип аны йөртәләр.
Башлангычта дөнья таныганнар
Зур тормышка, алга илтәләр...

Ачы җилләр иртә өтсәләр дә,
Тәмен тоям ярсу елларның.
Туган нигез көч-дәрт биреп торса,
Адымы нык барыр улларның.



***Рәкит Аллабирденең әнисе***
***Гаишә апага - 95 яшь.***

***«Исән була күр, әнием!»***

## МОИ САЗАНЛЫ

Я не пойду сегодня по асфальту, -
Давай, душа, рванём-ка напрямик
Вдоль Сазанлы –
вдоль поля с родниками,
Чтоб молодости вспомнить
каждый миг.

Ещё хранят, наверное, тропинки
Следы шального детства моего:
Давай-ка, мы съедобную травинку
Найдём и вспомним
терпкий вкус его.

Вон ивы машут издали руками,
Озёра-камыши вновь шлют привет.
И рядом с ними
снова грусть-печали
Исчезнут, словно в мире горя нет.

Вон скирды предо мной
былинно встали,
Шагают копна сена на лугах.
И родники зазывно зазвенели,
Прохладою целебной на губах.

Поляны заиграли на курае:
Да, ворожея -
каждый здесь цветок.
Здесь, рядом с Сазанлы, я ощущаю
Вновь вдохновенный радости поток.

И хлеборобу, и косцу – родня ты:
Опорой и надеждой был всегда –
Хлеба здесь полновеснее намного,
А сено ароматно – хоть куда!

Пройдя дорог немало на чужбине,
Я видел и тайгу, и ширь степей,
Но предо мной
всё время миражили
Ивняк любимый, озеро, ручей!..

Вновь голову склоняю,
возвратившись,
Совета, вдохновенья здесь ища:
Вхожу в свои родимые просторы,
Вновь по-ребячьи сердцем трепеща!

## ОЗЕРО БОЛЬШОЕ

Здравствуй, дружище!
Ты такое ж, как прежде –
С грустным лицом,
с камышовой полянкой.
Ну, улыбнись же, вспомни подростка,
Что сенокосил здесь как-то непросто…

Жаркое лето.
Страда. Сенокос.
От духоты тщясь спасенья найти,
Стал я купаться. А конь вдруг понёс –
Видно, от слепней пытаясь спастись.

Сколько же плакал и сколько искал я
Эту пропажу меж ив и вдоль берега!
Ну а потом, помню, как ты ласкало
Рану волной, когда сел я под деревом.
Воспоминанья…
На них ты богато.
Ты даровало мне счастье навек –
Здесь, в царстве
солнечноoких кувшинок
Милым назвал меня мой человек!

Ты обмелело.
Да, жизнь-то проходит –
Тропинок-морщин уж поболе на лбу.
И стало здесь
чаще намного встречаться
Озёр новых - дочек твоих на лугу.

Но вот опять уж горизонт алеет.
Свиданию конец. Пора идти…
Ах, озеро, дружище,
новь грусть тлеет:
Прощаться трудно –
сердце, потерпи!..

## ПТИЦА

Вечер. Сумерки…
Волглый туман
Крылья мягко
над лугом простёр.
У дороги на иве седой
Птицы пенье – печали костёр…
Одинокая ива… А где же
Здесь шумевший когда-то ивняк?!
Потихонечку, полегонечку
Злые силы весь луг истребят?..

Мать-природа
В душе сокрушается:
«Будь же бдительным, человек!
Бессердечность весь мир иссушает
И к погибели тянет свой век…»

Что за горе тебя, птица мучает,
Всю округу тревогой объяв? –
Я твоё беспокойство чувствую,
Материнскую душу поняв…

«Отчего-то вот после полётов
Не вернулся сыночек домой.
Я боюсь – не разбился,
не сбился ли
Мой единственный,
родненький мой.
Может, мечется где-то вдали он
Безнадежно
средь сумрачных туч.
Не замёрз ли, не заблудился ли
На чужбине суровых круч?..»

Понимаю твоё беспокойство,
Твоей песни тревожной печаль:
Отчий дом рано сам я покинул
И немало потерь повстречал.

А сегодня, как видишь, вернулся
В дорогие края Сазанлы –
Так и птенчик твой оперившийся
Приспешит из чужой стороны!

## ДУМАЯ О КОНЯХ

На лужайке – костёр.
Рядом кони.
Чувства светлые – через край.
Скачки. Игры, рассказы ночные –
Детства неповторимый рай!

Травку щиплют усталые лошади.
Жеребёночки к мамам льнут:
Мамы гривами их обнимают,
И усладу вечерних зорь пьют…
У костра вновь встречает приветливо,
Как когда-то, наш дядя Накыйп:
«А я думаю, кто же так поздно, -

Говорит он, - собрался вдруг в путь!»

Он-то знает язык лошадиный.
Он всю жизнь –
справедлив ко всему.
Своим дружеским рукопожатьем
Он всех ближе сегодня к селу.

Он уехавших, нет, не ругает,
А лишь мудро заметит порой:
«Да, пусть учатся юноши,
трудятся –
Им же двигать вперёд новый строй!»

Строго спросит:
«Как там КАМАЗы?
Раскупаются ли за рубежом?
Вы нас в городе не подводите -
Новостей только радостных ждём!

Да, сегодня везде ускоренья,
«Перестройка» шагает вовсю!..
Но ведь кто-то коней тоже должен
Здесь пасти – сёл лелеять красу!..

Да, сегодня мы переживаем
За зверей исчезающий вид,
И за птиц, и за редких растений…
А коней кто от бед оградит?!

Ведь они, эти самые кони
Нас –да! – вывели в космос Вчера:
А сейчас к ним царит равнодушье –
Может вспомнить об этом пора!»

Да, вопрос мне задал он нелёгкий –
Здесь решенье не сразу найдёшь.

На глобальных сидим совещаньях,
А ведь где-то животных падёж…

Вот так часто в деревне экзамен
Я держу за судьбу, за дела,
И любовью к односельчанам
Моя жизнь городская полна.

## ПРОЩАНИЕ С ДЕРЕВНЕЙ

Здесь луна таинственно сияет,
В каждый дом стараясь заглянуть.
Я с любовью к Отчему порогу
Выхожу домой в неблизкий путь.

Как же ты прекрасна, как любима,
Сторона родная, Сазанлы –
Здесь и Кров,
                и Хлеб мы находили,
Сладок здесь Отечества и дым.

Ты когда-то в добрые объятья
Пред моими дедами раскрыв,
Нас трудолюбивыми растила,
В души заронив надежд ростки.

Я Тебя ничуть не забываю,
Даже проживая вдалеке:
С каждым дорогим
                воспоминаньем,
Будто бы цветок держу в руке.

Да, судьба давно со мной знакома –
Ты, наверно, тоже узнаёшь:
Я ведь продолжаю дело рода –
Сазанлы, Ты силы мне даёшь!

Да, конечно, будешь Ты в обиде
На меня, родная, если в путь
Завтра соберусь…
- Сыночек, снова, -
Скажешь Ты, прощаясь, -
Как-нибудь постарайся
возвратиться к дому…

*Перевёл с татарского*
*Мансур САФИН.*



***Рәкит Аллабирде авылдашы - балыкчы Сергей белән Юшатыр буенда***



***Ракит Аллабирде среди членов литературного объединения "Золотые россыпи", работающего под эгидой Русского культурного общества г.Набережные Челны.***

## ЯШЬЛЕК МОҢЫ

*(җыр)*

*Ринат Гобәйдуллин көе*

Яшьлегемнең серен саклый
Туган авыл кичләре.
Гармун чыңы һаваларда –
Тәүге сөю хисләре...

*Кушымта:*
Әйдә, дуслар, бер әйләник
Шул чактагы урамны.
Гармун моңы басар, бәлки,
Күңелдәге буранны.

Кунак кызы көтә анда,
Көтә серле күзләре...
Төнге бакча буйларына
Элгән сөю сүзләре.

*Кушымта.*

Сагыш дәртле моңга тулып
Урамнарга түгелә...
Яшьлегенә кайткан авыл
Мәхәббәткә күмелә!

*Кушымта.*

## КИЧЕРӘ КҮР МИНЕ, МӘХӘББӘТЕМ...

*(җыр)*

*Ринат Гобәйдуллин көе*

Бәхетемне яннарымда күрми,
Юанычлар эзләп тапмаганда...
Ничек түздең, чәчкән гөлләреңне
Хыянәтле җилләр таптаганда?!

*Кушымта:*
Кичерә күр мине, мәхәббәтем...
Ачылмаган серле син чәчәк!
Сөюләрем сине ачар өчен,
Якты таңнар алып киләчәк.

Мәрхәмәтле язмыш соңламаган
Аңлатырга тик син кирәгеңне.
Учларыма алып юатамын
Гел әрнүләр тулы йөрәгеңне.

*Кушымта.*

Мин тезләнеп чиксез мәхәббәткә
Үбәм хәзер яшьле күзләреңне.
Әйтче, бәгърем, әйтче кичералсаң,
“Сөям һаман” – дигән сүзләреңне.

*Кушымта.*



Сулдан уңга: ***Айрат Суфиянов, Галиәхмәт Шаһи, Рәкит Аллабирде, Ринат Гобәйдуллин***

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

## ИСПОЛЬЗОВАННАЯ ЛИТЕРАТУРА

Зарипов, Р. Җырлап ачыла күңел: җырлар / Р.Зарипов. – Яр Чаллы: ООО «Диамант», 2016. – Б. 79.

Аллабирде, Р. Сулыш: романтик повесть, кыйсса, шигырьләр, җырлар / Р. Аллабирде. – Яр Чаллы: «Взаимная помощь» җәмгыятенең социаль типографиясе, 2015. – 348 б.

## КҮРСӘТКЕЧТӘ КУЛЛАНГАН ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАР ИСЕМЛЕГЕ

## СПИСОК ГАЗЕТ И ЖУРНАЛОВ, ИСПОЛЬЗОВАННЫХ В УКАЗАТЕЛЕ

Аргамак (Яр Чаллы)
Безнең фикер (Яр Чаллы)
Ватаным Татарстан (Казан)
Казан утлары (Казан)
Кама таңнары (Чаллы)
Кызыл Таң (Уфа)
Тулпар (Уфа)
Көмеш кыңгырау (Яр Чаллы)
Нур (Яр Чаллы)
Мәйдан (Яр Чаллы)
Шәһри Чаллы (Яр Чаллы)
Юшатыр (Күмертау)
Светлый путь (Тукай)
Якты юл (Тукай)

# КУШЫМТА

# ПРИЛОЖЕНИЕ

## *Рәкит Аллабирденең шәхси архивыннан алынган фоторәсемнәр*

## *Фотоматериалы из личного архива Ракита Аллабирде*



# ЯЗУЧЫ РӘКИТ АЛЛАБИРДЕ КАЛӘМДӘШЛӘРЕ, ОСТАЗЛАРЫ АРАСЫНДА



***Яр Чаллыга Казаннан каләм осталары, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры йолдызлары килгәч***



***Яр Чаллы шәһәрендәге «Ләйсән» әдәби берләшмәсенең чишмә башында торган әдипләр***



***Редактор Йосыф Жимангулов белән «Шәһри Чаллы» газетасына«Идел-Урал» фондының беренче атлы сәяхәте турында язма әзерләгәндә***



***«Идел-Урал» инвалид-спортчылар хәйрия фондының беренче атлы-автомобильле сәяхәтенең маршрутын төзегәндә***



***Г.Х.Андерсен Халыкара әдәби премия иясе, язучы Рафаил Газиз исемендәге иҗади бүләк тапшыру тантанасында***



*Татарстан Язучылар берлегенең идарә утырышында*



*Каләмдәшләре Амур Фәләх һәм Факил Сафин белән*
*Г.Тукайның туган авылы Кушлавычта*



*Каләмдәше Амур Фәләх һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе, драматург Данил Салихов белән*



***Татарстан Язучылар берлегенең рәис урынбасары, шагыйрь Рәмис Аймәтнең 50 яшьлек юбилеенда***



***Каләмдәшләр - Нәҗибә Сафина һәм Марат Закир белән***



***Язучы Рахман Шәфигуллин һәм Татарстапнның халык шагыйре Разил Вәлиев белән Язучылар берлегендә***



*Каләмдәшләр, дуслар арасында. Казан, 2017 ел*



*Язучылар - Галимҗан Гыйльманов, Рафис Сәлимҗанов, Рафис Корбан белән*



*Күренекле шагыйрь Ринат Харис һәм атаклы журналист Риман Гыйлемханов белән Татарстан Язучылар берлеге ишегалдында. 2019 ел*



*«Ләйсән» әдәби берләшмәсенең чираттагы утырышыннан соң*



*Каләмдәшләр, инвалид-спортчылар белән Сабан туенда. Чаллы, 2019 ел*




*Рәкит Аллабирде Р.Корбан һәм Г.Гыйльманов иҗаты турында чыгыш ясый*

# МИЛЛИ ӘДӘБИ-МӘДӘНИ ЧАРАЛАРНЫҢ ИСТӘЛЕКЛЕ МИЗГЕЛЛӘРЕ












Сәскә
ҒУМЕРЕ








«ДОБРОЕ БРАТСТВО — ЛУЧШЕЕ БОГАТСТВО»


ВОЗЬМЕМСЯ
ЗА РУКИ
ДРУЗЬЯ!



# «ИДЕЛ-УРАЛ» ИНВАЛИД-СПОРТЧЫЛАР ХӨЙРИЯ ФОНДЫ ЭШЧӘНЛЕГЕН ЯКТЫРТУЧЫ ФОТОИСТӘЛЕКЛӘР



***«Идел-Урал» инвалид-спортчылар фонды Кавказ сәяхәтеннән кайткач***



***Чаллыда инвалидлар өчен беренче Сабан туе ачылышы***



***«Татарстан - Калмыкия» маршруты буенча сәяхәттән соң***



***Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында***



***ЯрЧаллы шәһәре хакиме Н.Г.Мәһдиев белән***





*Яр Чаллы шәһәре «Тулпар» ат спорты мәктәбе директоры Н.З. Гыйлаҗев белән*








ИДЕЛЬ-УРАЛ-КАВКАЗ


© Р.Бильданов


ТЕРРОРИЗМУ-НЕТ!
КАМАЗ
АВТОПРОБЕГ
НЕФАЗ
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ-МОСКВА
ВЕ 496 16


Гранд Авто















# «ИДЕЛ-УРАЛ» ИНВАЛИД-СПОРТЧЫЛАР ХӘЙРИЯ ФОНДЫНЫҢ БИШ ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕННАН ИСТӘЛЕКЛӘР







# РӘКИТ АЛЛАБИРДЕНЕҢ 55 ЯШЬЛЕК ЮБИЛЕЕ ТАНТАНАСЫННАН КҮРЕНЕШЛӘР









## «ОЛЫ ЙӨРӘКЛЕ КЕШЕ» ТАНТАНАСЫНДА













Р. Р. Муллахметов, Л. М. Фархутдинова, Р. Я. Абдульманов, Ф. М. Мухамадеев

# БӨЕК ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

























БОЛГАР






САБАНТУЙ

# САБА РАЙОНЫНА СӘЯХӘТ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ









DVD
VTB
ROSTAR




СЕТЬ АВТОЗАПРАВОЧНЫХ СТАНЦИЙ
АВТОДОРСТРОЙ
Международный детский
турнир по шахматам








DENNIS








2007
ГОД БЛАГОТВОРИТЕЛЬНОСТИ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СПЕШИТЕ
ТВОРИТЬ
ДОБРО!



РЕСПУБЛИКАНСКИЙ КОНКУРС
"БЛАГОТВОРИТЕЛЬ 2009 ГОДА"

ДИПЛОМ

НАГРАЖДАЕТСЯ

БЛАГОТВОРИТЕЛЬНЫЙ ФОНД
ИНВАЛИДОВ-СПОРТСМЕНОВ
«ИДЕЛЬ-УРАЛ»
Директор
Абдульманов
Ракит Явдатович

ПРЕДСЕДАТЕЛЬ
РЕСПУБЛИКАНСКОГО СОВЕТА
ПО ВОПРОСАМ БЛАГОТВОРИТЕЛЬНОЙ
ДЕЯТЕЛЬНОСТИ
ПРЕЗИДЕНТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН М.Ш. ШАЙМИЕВ

КАЗАНЬ



Университет управления «ТИСБИ»
Благотворительный фонд
«Милосердие в образовании»

РЕСПУБЛИКАНСКИЙ КОНКУРС
«Человек - большое сердце»
(С заботой о лицах с ограниченными
возможностями здоровья)

ДИПЛОМ

В номинации
«Общественная инициатива»
признан победителем:
Абдульманов
Ракит Явдатович,
учредитель благотворительного фонда
инвалидов-спортсменов "Идель-Урал"

Ректор, директор благотворительного
фонда, председатель жюри
республиканского конкурса Н.М.Прусс

Казань 2013



СЕВЕРНАЯ ОКРУЖНАЯ ОРГАНИЗАЦИЯ МОСКОВСКОЙ ГОРОДСКОЙ ОРГАНИЗАЦИИ
ОБЩЕРОССИЙСКОЙ ОБЩЕСТВЕННОЙ ОРГАНИЗАЦИИ «ВСЕРОССИЙСКОЕ ОБЩЕСТВО ИНВАЛИДОВ»

СЕРТИФИКАТ
выдан
руководителю агитационного автопробега,
учредителю благотворительного фонда инвалидов-спортсменов «Идель-Урал»
Абдульманову Ракиту Явдатовичу
участнику агитационного автопробега в поддержку кандидата
на должность президента В.В. Путина
протяженностью 2200 км по маршруту:
Набережные Челны – Казань – Чебоксары - Нижний Новгород – Владимир – Москва – Набережные Челны
с 5 по 12 марта 2018 года

Руководитель группы Р.Я. Абдульманов
Председатель СОО МГО ВОИ А.В. Бастрыкина

Москва 2018 год



Свидетельство

Победитель открытого конкурса,
проведенного в 2009 году
в соответствии с распоряжением
Президента Российской Федерации

Благотворительный фонд
инвалидов-спортсменов
«Идель-Урал»

Президент Национального благотворительного фонда А. Моляков

3 сентября 2009 года



Свидетельство

Абдульманов Ракит Явдатович
признан победителем Городского конкурса
«Человек – золотое сердце»
в номинации
«За волю к победе»

Мэр города
Набережные Челны И.Ш.Халиков

2009 год



МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА

За большую работу по адаптации и реабилитации средствами физической культуры и спорта людей с ограниченными физическими возможностями и в связи с 50-летием со дня рождения

НАГРАЖДАЕТСЯ

**Абдульманов Ракит Явдатович**

учредитель благотворительного фонда инвалидов-спортсменов
«Идель – Урал»

Министр　　　　А.Р.Шафигуллин



МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ МОЛОДЕЖИ И СПОРТУ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯШЬЛӘР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ

*Благодарственное письмо*

**АБДУЛЬМАНОВУ Р.Я.**

ОРГАНИЗАТОРУ БЛАГОТВОРИТЕЛЬНОГО ФОНДА
ИНВАЛИДОВ-СПОРТСМЕНОВ "ИДЕЛЬ-УРАЛ", г.Н.ЧЕЛНЫ

**УВАЖАЕМЫЙ РАКИТ ЯВДАТОВИЧ!**

Сердечно поздравляем с 20-летиемм со дня образования Благотворительного фонда инвалидов-спортсменов "ИДЕЛЬ-УРАЛ", г.Н.Челны и выражаем Вам благодарность за многолетнюю и активную работу по реабилитации и социальной интеграции инвалидов средствами физической культуры и спорта.
От всей души желаем Вам крепкого здоровья, счастья, оптимизма и успехов в благородном деле.

Министр　　　　В.А.Леонов

2016 г.

приказ№127/в 11.05.2016 год.



РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МЭР
ГОРОДА НАБЕРЕЖНЫЕ
ЧЕЛНЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

«22» марта 2010 г.　　　　№ 170

*Р.Җ. Әбделмановны
«Яр Чаллы шәһәре
каршындагы казанышлары өчен»
билгесе белән
бүләкләү турында*

*О награждении
Абдульманова Р.Я.
знаком отличия
«За заслуги перед городом
Набережные Челны»*

КАРАР БИРӘМ:

Актив хәйрия эшчәнлеге, физик мөмкинлекләре чикле кешеләрне физик культура һәм спорт чаралары белән адаптацияләү һәм реабилитацияләү буенча зур хезмәте өчен һәм 50 яшь тулу уңаеннан «Идел-Урал» инвалид-спортчыларның хәйрия фонды учредителе Әбделманов Рәкит Җәүдәт улын «Яр Чаллы шәһәре каршындагы казанышлары өчен» билгесе белән бүләкләргә.

ПОСТАНОВЛЯЮ:

За активную благотворительную деятельность, большую работу по адаптации и реабилитации средствами физической культуры и спорта людей с ограниченными физическими возможностями и в связи с 50-летием со дня рождения наградить знаком отличия «За заслуги перед городом Набережные Челны» Абдульманова Ракита Явдатовича, учредителя благотворительного фонда инвалидов-спортсменов «Идель - Урал».

Шәһәр Хакиме
Мэр города　　　　И.Ш. Халиков



За большую работу по адаптации и реабилитации
средствами физической культуры и спорта
людей с ограниченными физическими возможностями

**Абдульманов
Ракит Явдатович**

председатель
благотворительного фонда спортсменов-инвалидов
«Идель-Урал»

награждается
ПОЧЕТНОЙ ГРАМОТОЙ
МЭРА ГОРОДА НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ

Мэр города　　　　И.Ш.Халиков

март, 2008г.



Город Набережные Челны
Республики Татарстан

БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО

**Уважаемый Ракит Явдатович Абдульманов!**

*Сердечно благодарю Вас за многолетний плодотворный труд и активное участие в общественной жизни города*

*Вы ведете большую работу по решению вопросов жизнедеятельности людей с ограниченными возможностями и, активно сотрудничая с предприятиями и учреждениями города совместно с Исполнительным комитетом, вносите весомый вклад в создание доступной среды для них. Создав благотворительный фонд инвалидов-спортсменов «Идель-Урал», Вы ведете большую работу по привлечению к занятиям физической культурой и спортом инвалидов, организуете многодневные походы – конные, автомобильные, веломобильные. Неоценима Ваша деятельность и по реализации программ социальной реабилитации инвалидов, по их профориентации и трудоустройству.*

*Выражая искреннее уважение, самые добрые и теплые слова признательности, от всей души желаю Вам энергии и оптимизма, здоровья и бодрости духа.*

*С уважением,*
*Мэр города Набережные Челны* *В.Г.Шайхразиев*
*ноябрь 2011г.*



БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО

***Общественная благотворительная организация «Герои Татарстана» выражает***

***БЛАГОДАРНОСТЬ***

***АБДУЛЬМАНОВУ РАКИТУ ЯВДАТОВИЧУ***
***члену Совета организации ветеранов г. Набережные Челны, учредителю благотворительного фонда ИС «Идель-Урал» за за большой вклад в патриотическое воспитание молодежи***

***Председатель***
***ОО «Герои Татарстана»*** ***И. Ш. Мостюков***



БЛАГОДАРНОСТЬ

***Российская Ассоциация Армспорта***
***БЛАГОДАРИТ***
*Директора благотворительного фонда*
*"Идель-Урал"*
*Абдульманова Ракита Явдатовича*
***За большой вклад в развитие армспорта России, постоянную заботу о подрастающем поколении спортсменов и постоянную финансовую поддержку армспорта.***

***Президент РАА*** ***Филимонов А.А.***



ГРАМОТА
за спортивные достижения

*НАГРАЖДАЕТСЯ*
***АБДУЛЬМАНОВ***
***Ракит Явдатович,***
*Учредитель Благотворительного фонда инвалидов-спортсменов «Идель-Урал» за огромную работу в развитии интеллектуальных видов спорта в среде спортсменов с ограниченными возможностями здоровья, организацию системы стимулирования шахматистов и шашистов, а также в связи с 50-летним юбилеем.*

Директор В.И.Гончаров
МАОУ ДОД «ДЮСШ «Этюд»
г.Набережные Челны,
Вице-президент
Федерации шахмат Поволжья,
Член Наблюдательного совета
Российской Шахматной Федерации

***г.Набережные Челны*** ***«22» марта 2010г.***



***Безгә гадәттән тыш вакыйганың — меңьеллыклар алмашынуның шаһитлары булырга язган.***

***Узган гасыр белән саубуллашканда, үткән тормышыбызга бәя биргәндә, без һәр кешенең үз язмышы, үз сынаулары һәм үз шатлыклары булуына тагын бер кат ышанабыз. Ә бит аның табигатьтән бирелгән төп вазыйфасы — теләсә нинди шартларда да яхшылык, игелеклелек, гаделлек һәм шәфкатьлелек идеалларына ирү, аларны алга сөрү. Сезнең беркайчан да бирешмәскә, тормышның бары тик уңай якларын гына күреп яшәргә омтылуыгыз шәхси батырлыкның күркәм мисалы түгелмени?***

***Дөньяны тагын да яхшырак, матуррак һәм мәрхәмәтлерәк итү теләге безнең барыбызны да алга таба да берләштерсен һәм бердәм итсен иде.***

***Сезне чын күңелемнән Яңа ел, Яңа гасыр, Яңа меңьеллык белән тәбрик итәм!***

***Сезгә һәм Сезнең якыннарыгызга рухи ныклык, үзара аңлашу, иминлек, җан җылысы һәм тынычлык теләп калам!***

***Татарстан Республикасы Президенты*** ***М. Ш. Шәймиев***

2001

***От всей души поздравляю Вас с Новым годом, с Новым веком, с Новым тысячелетием!***

***Желаю Вам и Вашим близким крепости духа, оптимизма, взаимопонимания, благополучия, тепла и мира!***

***Президент Республики Татарстан*** ***М. Ш. Шаймиев***

2001

# РӘКИТ АЛЛАБИРДЕНЕҢ БҮЛӘКЛӘРЕ

# НАГРАДЫ РАКИТА АЛЛАБИРДЕ

Медаль «За заслуги перед городом Набережные Челны».
Медаль «60 лет победы в Великой Отечественной войне».
Медаль «65 лет победы в Великой Отечественной войне».
Медаль «90 лет ВЛКСМ».
Медаль «100 лет Красной Армии».
Почётный орден «100 лет Ленинскому Комсомолу».
Медаль «Адмирал Советского Союза Кузнецов».
Медаль «10 лет Федерации физической культуры и спорта инвалидов г.Москвы».
Медаль «За мужество и гуманизм».
Медаль «За милосердие и гуманизм».
Медаль «Столетие подводных сил».
Памятная медаль имени Виктора Ивановича Гончарова.




































## ЭЧТӘЛЕК

**Укучыга**......................................................................5
**К читателю**...................................................................5
**Роза Хәмидуллина.** Уңышлар юлдаш булсын..........................6
Рәкит Аллабирдененң кыскача биографиясе...........................10
Краткая биография Ракита Аллабирде....................................13
Рәкит Аллабирдененң басылып чыккан китаплары.................17
Изданные книги Ракита Аллабирде.........................................17
Әдәби җыентыкларда басылган әсәрләре.............................18
Произведения, напечатанные в сборниках.............................18
Газета-журналларда басылган әсәрләре...............................19
Произведения, изданные на страницах газет и журналов.......19
Иҗат һәм тормыш биографиясе турында...............................24
**Рәкит Аллабирдененң иҗат үрнәкләре**
«Очыгыз ирекккә...».............................................................27
Алиһәмә...........................................................................28
Аһәң.................................................................................29
Күчтәнәч...........................................................................31
**Иҗади эшчәнлеге турында каләмдәшләре**
**Отзывы о творчестве писателя**
*Рафаил Газизов.* Рекомендация.............................................34
Мин аңа ышанам..................................................................35
*Фаяз Дунай.* Сөенеч...............................................................39
*Туфан Миңнуллин.*...................................................................39
*Равил Фәйзуллин.*...................................................................39
*Айдар Хәлим*..........................................................................40
*Рафис Сәлимҗанов*.................................................................40
*Шаһинур Мостафин*.................................................................40
*Әнвәр Шәрипов.* Сөю таңы.......................................................41
*Клара Булатова.* Тәкъдим хаты..............................................46
*Ризидә Рәхмәтуллина.* «Артка юл юк»......................................47
*Равил Лотфуллин.* Корчагиннар токымыннан..........................49
*Дмитрий Повышев.* Ракиту Явдатовичу Абдульманову........50
*Зәбир Хәлимов.* Бәйрәмгә.......................................................51
*Зәбир Хәлимов.* Күңелендә аның җылы кояш..........................52
*Амур Фәләх.* Рәкит Аллабирде иҗатына карашым.................54

*Равиль Ахметзянов.* Ракиту Абдульманову..............................58
*Дени Абрамашвили.* Моему другу Ракиту..................................59
*Айрат Шәйхетдин.* «Идел-Урал»... ........................................60
Тәбрикнамә.........................................................................61
*Равил Мостафин*. Шагыйрь-прозаик.......................................62
*Айрат Суфиянов.* Тәкъдимнамә.............................................66
*Айрат Суфиянов.* Җаным тама... ...........................................67
*Айрат Суфиянов.* Сүзнең кодрәте - үлемсез!..........................73
*Зилә Мөбәрәкшина.* «Әсәрләремдә татарларның башкортлар белән дус яшәгәннәрен чагылдырам......................................75
*Роза Хәмидуллина*. «Ак юл теләп...».......................................80
**Рәкит Аллабирденең шигъри бизәкләре**
**Стихотворения Ракита Аллабирде**
Чәчкә..................................................................................88
Хәзинә.................................................................................89
Әти иңе...............................................................................91
Көнләшү... ..........................................................................92
Гасыр аша...........................................................................95
Җаным тама........................................................................96
Бәхет...................................................................................96
Хәйрия.................................................................................97
Ташу үтә..............................................................................98
Гаярьләр..............................................................................98
Хыял атым...........................................................................99
Кайда төшим.....................................................................100
Лачын................................................................................100
Фанида..............................................................................101
Әнкәй................................................................................102
Мои Сазанлы.....................................................................103
Яшьлек моңы.....................................................................110
Кичерә күр мине, мәхәббәтем..............................................110
**Файдаланылган әдәбият.**...................................................112
**Кушымта**...........................................................................113

Әзер оригинал-макеттан җаваплылыгы чикле «Взаимная помощь» җәмгыяте типографиясендә басылды.
423815, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре,
Автозавод пр., 13 йорт (29/10).